# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2020 4(28)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ХӘМИДОВА Ч.И.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Рыжикова Т.Р.* Бараба татарларындагы [о] сузыгының артикулятор характеристикалары (чагыштырма аспект) . . . . . . 7
*Сәфәров Р.Т.* Тел культурасы турында мәгълүмат чыганагы буларак актив сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
*Шәйдуллин Р.В.* XX гасырның беренче чирегендә татар халкының тел мәнфәгатьләре *(Татарстан материаллары буенча)* . . 20
*Сөләйманов Җ.Ш., Гатиатуллин А.Р., Әюпов М.М.* «Төрки морфема» интернет-порталы: лингвистик базаларны тутыруны автоматлаштыру чаралары . . . . . . . . . . . . . . 31
*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр иске татар язма истәлекләрендә ‘үлем’ төшенчәсенең бирелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Гарипова Л.Ш., Миңнуллина Ф.Х.* Ханбикә – сәхнәдә: беренче тәҗрибәләр, ялгышлар, уңышлар... . . . . . . . . . . . . . 46
*Гыйлемшин Ф.Ф.* Гарәп әкиятләрендә хатын-кыз образларының сурәтләнеше *(«Мең дә бер кичә» әкиятләре мисалында)* . . . . . . 55
*Төхфәтова Г.Ф.* «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» җыентыгының басылу тарихы, төзелеше һәм шагыйрьнең иҗат лабораториясе мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . 61
*Җиһан Чакмак.* Татарларның көчле каләме – Фатих Кәрими . . . 72
*Габидуллина Ф.И.* Зөлфәт иҗатында рухи азатлык идеясе *(«Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы мисалында)* . . . . . . . . 82
*Надыршина Л.Р.* Рәмис Аймәтнең иҗат дөньясы . . . . . . . . . 89

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Себердә татар фольклоры . . . . . . . . 96
*Батталова А.Д.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы басма чыганакларында Чистай төбәгенә бәйле тарихи мәгълүматлар һәм фольклор материаллары *(В.А. Казаринов, Е.А. Малов, С.Е. Малов хезмәтләре мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . 105

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Мирдиянова Г.Р.* Математика буенча 1917 елга кадәр кулланылышта булган татарча дәреслекләр . . . . . . . . . . . . 112
*Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В.* Туган (татар) тел дәресләрендә сайлап алу ситуациясенең актуальлеге . . . . . . . . . . . . . . . 119

## СӘНГАТЬ

*Юнысова Г.Ф.* Җәүдәт Фәйзинең тормышы һәм иҗаты *(композиторның тууына 110 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . 130

*Мусина Н.Д.* Татар биюе этнохореологиясе барлыкка килү: фольклористиканы үстерү контекстында Гай Таһиров тикшеренүләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ

*Мустафаев Намазали.* Борынгылыкны саклаган фәнгә багышланган гомер *(академик Мамедага Ширалиев истәлегенә багышлана)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Хуҗин Ф.Ш.* Болгар-татарлар тарихы турында яңа китап: Георги Владимиров. Великата България на Волга през средните векове (София: Просвета, 2019) . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

*Яхин Ф.З.* Б.К. Миңнуллинның «XX гасыр башы татар газетасының жанр һәм стиль дифференциясе» (Казан, 2019) монографиясе турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

*Абдуллина Д.М.* А.Ф. Ганиеваның «XX гасырның икенче яртысы татар прозасы («кеше һәм табигать» мәсьәләсе)» (Казан, 2019) монографиясенә рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Галимова Э.М.* Татар халкының милли музыкаль мирасы формалашу чорында Мәхмүт Нигъмәтҗанов фәнни эшчәнлегенең әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Рыжикова Т.Р.* Артикуляторные характеристики барабинско-татарского гласного [о] (сопоставительный аспект) . . . . . . . . 7
*Сафаров Р.Т.* Активный словарь как источник информации о культуре языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
*Шайдуллин Р.В.* Языковые интересы татарского народа в первой четверти XX в. *(по материалам Татарстана)* . . . . . . 20
*Сулейманов Дж.Ш., Гатиатуллин А.Р., Аюпов М.М.* Интернет-портал «Тюркская морфема»: средства автоматизации заполнения лингвистических баз данных . . . . . . . . . . . . . . 31
*Валиева М.З.* Выражение понятия ‘смерть’ в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков . . . . . . . . . . . . . . 41

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Гарипова Л.Ш., Миннуллина Ф.Х.* Постановка литературных произведений о Сююмбике: первые пробы, ошибки и успехи... . . 46
*Гилемшин Ф.Ф.* Изображение женских образов в арабских сказках *(на примере сказок «Тысяча и одна ночь» )* . . . . . . . . . . 55
*Тухватова Г.Ф.* «Сборник произведений Габдуллы Тукая» 1914 года: история публикации, содержание и вопросы творческой лаборатории поэта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
*Чакмак Дж.* Издательская и творческая деятельность Фатиха Карими . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
*Габидуллина Ф.И.* Отражения идеи духовной свободы в творчестве Зульфата *(на примере поэмы «В сердцах бессмертный дастан»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
*Надыршина Л.Р.* Творчество Рамиса Аймета . . . . . . . . . . . . 89

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский фольклор в Сибири . . . . . . . 96
*Батталова А.Д.* Фольклорные, народоведческие и исторические материалы о Чистопольском крае в письменных источниках конца XIX – начала XX в. *(на примере трудов В.А. Казаринова, Е.А. Малова, С.Е. Малова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Мирдиянова Г.Р.* Учебники математики на татарском языке до 1917 г. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
*Гилазева Л.Г., Хадиева Г.В.* Актуальность использования и проектирования «ситуации выбора» на уроках родного (татарского) языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125

## ИСКУССТВО

*Юнусова Г.Ф.* Творчество Дж. Файзи сквозь призму жизненных событий *(к 110-летию со дня рождения композитора)* . . . . . . 130

*Мусина Н.Д.* Возникновение этнохореологии татарского танца: Исследования Гая Тагирова в контексте развития фольклористики . . 145

## НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ

*Мустафаев Намазали.* Жизнь, посвященная науке о живой старине... *(посвящается памяти академика Мамедага Ширалиева)* . 159

## НОВЫЕ КНИГИ

*Хузин Ф.Ш.* Новая книга о булгарах-татарах: Георги Владимиров. Великата България на Волга през средните векове (София: Просвета, 2019) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

*Яхин Ф.З.* О монографии Б.К. Миннуллина «Жанрово-стилистическая дифференциация татарской газеты начала XX века» (Казань, 2019) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

*Абдуллина Д.М.* Рецензия на монографию А.Ф. Ганиевой «XX гасырның икенче яртысы татар прозасы («кеше һәм табигать» мәсьәләсе)» (Казань, 2019) . . . . . . . . . . . . . . 178

## ПЕРСОНАЛИИ

*Галимова Э.М.* Значимость научной деятельности Махмуда Нигмедзянова в период формирования национального музыкального наследия татарского народа . . . . . . . . . . . . . . 181

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.19

*Т.Р. Рыжикова*

# БАРАБА ТАТАРЛАРЫНДАГЫ [О] СУЗЫГЫНЫҢ АРТИКУЛЯТОР ХАРАКТЕРИСТИКАЛАРЫ (чагыштырма аспект)

В статье описываются артикуляторные особенности барабинско-татарского гласного «о» по данным магнитно-резонансной томографии. Томограммы были получены от четырех дикторов и описаны по методике, принятой в Лаборатории экспериментально-фонетических исследований Института филологии Сибирского отделения Российской академии наук. Рассматриваемый гласный характеризуется вариативностью произнесения (главным образом – по подъему), а также имеет ряд специфических характеристик (наличие эйективности и факультативной фарингализованности настройки). Сопоставление, проведенное с другими языками, выявило сильное сходство с сагайским диалектом хакасского языка, сибирским диалектом татарского языка и башкирским языком. Дальнейшее изучение вокальной системы языка барабинских татар позволит выявить общее и специфичное в их артикуляторно-акустической базе.

**Ключевые слова:** экспериментальная фонетика, артикуляция, МРТ, язык барабинских татар, вокализм.

The article describes the articulatory features of the Baraba-Tatar vowel «o» according to the magnetic resonance imaging data. The tomograms were obtained from four speakers and described according to the method adopted in the Laboratory of Experimental Phonetic Research, Institute of Philology, Siberian Branch of the Russian Academy of Sciences. The vowel under consideration is characterized by a variation in articulation (mainly – by rise), and also has a number of specific characteristics (ejectivity and facultative pharyngealization). Comparison with other related languages has revealed similarities with the Sagai dialect of the Khakass language, the Siberiantatar and Bashkir languages. Further investigation of the vocal system of the Baraba-Tatars' language will aid in determining the general and specific traits in their articulatory-acoustic base.

**Key words**: experimental phonetics, articulation, MRI, Baraba-Tatars' language, vocalism.

Әлеге мәкалә Бараба татарларындагы [о] авазының артикулятор үзенчәлекләрен башка кардәш себер телләрендәге шундый ук артикуляцияләр белән чагыштыруга багышлана. Бараба татарлары – Новосибирск өлкәсенең миноритар төп төрки телле халкы. Әлеге тел язусыз телләр рәтенә керә, һәм бу телгә юкка чыгу куркынычы яный, бу исә төрле лингвистик аспектларны, шул исәптән фонетиканы тикшерүне актуальләштерә һәм ашыктыра.

Тикшеренү материалы булып бараба-татар телендә сөйләшүче дүрт кешедән алынган [о] авазы томограммалары тора. Эксперимент Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Халыкара Томография

Үзәгендә Philips Achieva Nova Dual 1.5 T томографында, Head/Neck synergy SENSE (Philips medical systems; Eindhoven, Netherlands) катушкасында үткәрелде. Яздыру берничә проекциядә башкарылды, әмма саггиталь яссылыктагы сурәтләр генә анализланды. Томографияләү программасына инициаль һәм консонантара позициядә әлеге аваз кергән алты бараба сүзе кертелде: *от* ‘огонь’, *оты* ‘огонь=его’, *йол* ‘дорога’, *қол* ‘рука’, *қорт* ‘червяк’, *қой* ‘овца’. Барлыгы 18 томограмма алынды һәм тасвирланды.

Инструменталь анализ нәтиҗәләре [о] авазының барлык әйтелешләрен /ʊ/ фонемасына җыярга мөмкинлек бирде. Бу фонема – үзәк арткы рәт, икенче төп (факультатив рәвештә беренче нык ачылып бетмәгән, читтә торуның дүртенче төп) дәрәҗәсендәге, яссы иренләшкән, эйектив, (факультатив рәвештә увулярлашкан, глоттальләшкән, борынлашкан) сузык аваз. [у] авазы белән артикулятор охшашлык булуга карамастан, карала торган фонема акустик яктан [о] дип кабул ителә.

Барлык көйләнешләрне ике төргә бүлүгә ирештек: 1) тел очы аскы алгы тешләргә килеп терәлгән (бу очракта авыз резонаторының күләме кими); 2) тел очы тешләргә тими (алгы резонатор зурая, шул ук вакытта арткы, йоткылык өлеше тагын да ныграк кечерәя) (1–2 нче рәсемне кара). Моннан тыш, барлык очракларда да ларинксның актив эшләве теркәлгән: ул тел төбенә таба нык күтәрелә һәм йоткылык резонаторының күләмен киметә. Кайбер очракларда бер үк вакытта көйләүнең фарингальләшүе һәм эйективлыгы күзәтелә.

Себер (кет) телләрен тасвирлаганда эйективлык / инъективлык терминнарын беренчеләрдән булып Б.Б. Феер куллана: барлык типик[1] сузыклар көйләнеше да нейтраль хәлдә тора кебек, ә бугазны күтәрү, ягъни, эйективлык, аларны тарайта һәм алга этәрә һәм югары яңгыраш эффекты тудыра, шул ук вакытта бугазның төшүе, инъективлык, аларны киңәйтә һәм артка этәрә һәм түбән яңгыраш эффекты тудыра [Феер, с. 109]. Бараба татарлары телендәге [о] өчен йоткылык резонаторының күләме бик кечкенә булу хас, шул ук вакытта йомшак аңкау, һава чыгу юлын тарайтып һәм өстәмә киртә тудырып, тел сыртына таба салына, кайбер очракларда өске тешләр аскы иренгә якыная, бу шулай ук үпкәләрдән килүче һава агымына үтәргә комачаулый, аваз киеренкелегенең махсус акустик эффектын тудыра.

Сузыкның иренләшүе аның конститутив-дифференциаль билгесе булып тора, аның буенча барабалыларның [о] сузыгын яссы иренләшкән дип интерпретацияләргә мөмкин, өстәвенә кайбер очракларда иреннәрне алга чыгаруга капма-каршы иреннәрне эчкә «суыру» процессы күзәтелә (3 нче рәсем).

[1] «Типик сузыклар көйләнеше» дигән термин идеальләштерелгән, фарингальләшүгә, киеренкелеккә, ачыклык / ябыклыкка, алга чыгу / артка тартылуга һәм югары / түбән яңгырашка нейтраль артикуляцияләр өчен В.М. Наделяев тарафыннан тәкъдим ителә [Феер, с. 108].



1 нче рәсем. Бараба татарларының *йол* ‘дорога’ сүзформасында [о] сузыгы томограммасы в б.-т. (д. ЧГГ)



2 нче рәсем. Бараба татарларының *қол* ‘рука’ сүзформасында [о] сузыгы томограммасы (д. ЧГГ)



3 нче рәсем. Бараба татарларының *йол* ‘дорога’ сүзформасында [о] сузыгы томограммасы (д. УРР)

Бараба татарларындагы [о] ның тагын бер характеристикасы – аның «ябыклыгы»: барлык көйләнешләр да шактый тар – читтә торуның беренче нык ачылып бетмәгән, өченче ябылып бетмәгән дәрәҗәсендә (д. ЧГГ артикуляцияләре чыгарылма булып тора), анда алар шактый ачык – читтә торуның 3–4 дәрәҗәсе).

Алтай теленең онгудай диалектында [оо] сузыгы рентгенографиясе мәгълүматлары буенча, барлык көйләнешләр дә – шактый дәрәҗәдә арткы, тел үзе артка тартылган, тел очы аскы алгы тешләрдән ерак урнаша, ә бугаз нейтраль хәлдә. Соматик мәгълүматлар җыелмасы буенча [оо] сузыгы – үзәк арткы рәт, нык алга чыкмаган яисә читтә торуның дүртенче төп дәрәҗәсендәге, яссы иренләшкән, борынлашмаган [Шалданова, с. 99]. Алтай әдәби телендә [о] – читтә торуның дүртенче дәрәҗәсендәге үзәк рәт авазы, теленгит диалектында – читтә торуның дүртенче дәрәҗәсендәге, үзәк арткы рәт нык алга чыккан аваз [Шалданова, с. 150].

Тубаларлар телендә (Алтай теленең төньяк диалекты) /ȯь/ һәм / ȯьл/ фонемалары: фарингальләшү булу-булмау белән бер-берсенә каршы куела, шул ук вакытта аларның артикуляция ягыннан төп көйләнеше аерылмый: алар икесе дә катнаш, үзәк арткы рәт / арткы рәт, ябылып бетмәгән, читтә торуның өченче дәрәҗәсендәге, борынлашмаган, яссы иренләшкән авазлар буларак характерлана [Сарбашева, с. 87]. Әмма фарингальләшкән фонемада тел төбенең дә эше дә билгеләп үтелә.

Икенче бер төньяк – куманды диалектында [оо] сузыгы үзәк арткы рәт, нык алга чыкмаган, читтә торуның алтынчы дәрәҗәсендәге, яссы иренләшкән аваз буларак билгеләнә. Рентген схемасында телнең бик нык артка тартылганлыгы, бугазның нейтраль хәлдә булуы күренә. Иреннәр бик нык алга сузылган, иреннәр белән тешләр арасы шактый зур булса да, артикуляцияне яссы иренләшкән дип интерпретацияләргә мөмкин [Селютина, с. 63].

Хакас теленең сагай диалектында «о» сузыгының көйләнеше бараба татарлары теленә охшаган: тел очы аскы тешләр янында урнашкан, тел сыртының алгы һәм урта өлешләре чигендә аркылы бөгелү күзәтелә, аркауар өлеше каты һәм йомшак аңкаулар арасына күтәрелә, бугаз да бераз күтәрелә, тешләр һәм иреннәр арасы да бик кечкенә. Рентгенография мәгълүматлары буенча, йөкләнеш үзәк арткы рәт, читтә торуның өченче төп дәрәҗәсендәге, иренләшкән, борынлашмаган аваз буларак характерлана [Кыштымова, с. 42].

Кача диалектында [о] сузыгының артикуляциясе – арткы рәт, нык алга чыккан, читтә торуның алтынчы дәрәҗәсендәге, иренләшкән, борынлашмаган аваз дип билгеләнә [Кыштымова, с. 59].

Тува теленең каа-хем сөйләшендә фарингальләшү / фарингальләшмәү һәм озынлык / кыскалык буенча сузыкларны капма-каршы кую бар, шул рәвешле «о» тибындагы өч сузык аерылып чыга: [оъ], [оо], [о]. Алар рәт буенча бер-берсеннән аерыла. Рентген схемаларында фарингальләшкән *оъ*ның көйләнеше бертөрлерәк: соматик мәгълүматлар буенча, /оъ/ фонемасы фарингальләшкән үзәк арткы рәт, нык алга чыккан, читтә торуның бишенче дәрәҗәсендәге, яссы иренләшкән, борынлашмаган аваз буларак характерлана. Сөйләмдә түбәндәгечә билгеләнә ала: катнаш үзәк арткы рәт, үтә нык алга чыккан / арткы рәт, читтә торуның өченче дәрәҗәсендәге аваз. Фарингальләшмәгән [оо] һәм [о] сузыклары бердәй көйләнешле: үзәк арткы рәт, нык алга чыккан, читтә торуның өченче-дүртенче дәрәҗәсендәге, яссы иренләшкән, борынлашмаган [Дамбыра, с. 193].

МРТ мәгълүматлары буенча, Себер татарлары телендә «о» сузыгы үзәк арткы рәт, читтә торуның өченче нык ябылып бетмәгән дәрәҗәсендәге, иренләшкән, киеренке, фарингальләшмәгән, борынлашкан аваз буларак билгеләнә [Летягин и др., с. 15–16; Уртегешев, Ганенко, с. 190]. Томограммада тел төбенең фаринксның арткы стенасына таба тартылуы күзәтелсә дә, авазны көчле, ләкин фарингальләшмәгән дип бәяләргә мөмкин. Ларинксның күтәренке хәлдә булуы күзәтелә. Иреннәр арасы бик кечкенә, тешләр арасы кебек үк. Иреннәр тешкә терәлгән.

МРТ нәтиҗәләре буенча, башкорт теленең көнчыгыш диалектында, «о» сузыгы үзәк арткы рәт, нык алга чыккан, читтә торуның өченче дәрәҗәсендәге, иренләшкән, фарингальләшмәгән, факультатив рәвештә борынлашкан, увулярлашкан [Уртегешев, с. 50–51]. Себер татарлары телендәге кебек үк тел төбе бик нык артка тартылган, әмма көйләнешне фарингальләшкән дип булмый. Иреннәр белән тешләр арасы бик кечкенә. Ларинкс тел төбенә таба күтәрелгән.

Әгәр дә төрки телләр буенча китерелгән мәгълүматларны анализласак, артикулятор рәт буенча [о] сузыгы үзәк арткы рәт, катнаш үзәк арткы рәт / арткы рәт һәм арткы рәт авазы гына булырга мөмкин. Теленең аңкаудан читтә торуы буенча [о] сузыгы арттагы өченчедән алып алтынчы дәрәҗәгә кадәр үзгәреп тора, өстәвенә Бараба татарлары те-

лендә ул бик тар булырга мөмкин (читтә торуның беренче ачылып бетмәгән дәрәҗәсендә).

Иреннәр эше буенча [о] авазының барлык әйтелешләре яссы иренләшкән, бу – мөгаен, Себер һәм Идел-Урал төбәкләрендәге төрки телләргә хас күренештер.

[о] сузыгының конститутив-дифференциаль билгесе буларак фарингальләшүе бары тик тува һәм тубалар сөйләшләрендә генә очрый, барабалылар телендә – төсмергә ия билге, башка телләрдә һәм диалектларда – теркәлмәгән.

Төрле телләрдә сузыкларның борынлашуы күзәтелә, ләкин бу – позицион-комбинатор шартлар, дикторның әйтелеш үзенчәлекләре, эксперимент барышында артикуляциянең көчсезләнүе белән бәйле факультатив параметр булырга охшый.

Әгәр барлык санап үтелгән характеристикаларны бергә җыеп карасаң, Бараба татарлары телендәге [о] сузыгының артикулятор көйләнешләре хакас теленең сагай диалекты, Себер татарлары һәм башкорт телләрендәгегә бик нык охшаган. Бараба телендәге эйективлык башка телләрдә махсус ассызыкланмады, әмма рентген һәм томограммаларны анализлау аның шулай ук себер татарлары һәм башкорт телләрендә дә булуын раслый. Карала торган дүрт идиомада да иреннәр арасы бик кечкенә.

Моннан тыш, Х.Х. Сәлимов билгеләп үткәнчә, барабалылар телендә бер аваз тибының фонетик вариантлары бар, чөнки аның аваз системасы көчеш хәлендә, ә вокализм өлкәсендә тар сузыкларның өзеклеге күзәтелә [Салимов, с. 18–22]. Сузыкларның шундый ук үзгәреше хакас, себер татарлары һәм башкорт телләре өчен дә (шулай ук, мәсәлән, куманды теле өчен дә) хас.

Алга таба да Бараба татарлары теленең аваз системасын тасвирлау буенча эшне дәвам итү әлеге телнең үсеш һәм яшәеш закончалыкларын яхшырак аңларга һәм тикшерергә, шулай ук Россиянең лингвистик ландшафты формалашу юлларын ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

### Әдәбият

*Дамбыра И. Д.* Вокализм каа-хемского говора в сопоставлении с другими говорами и диалектами тувинского языка. Новосибирск: ИД Сова, 2005. 224 с.

*Кыштымова Г. В.* Состав и системы гласных фонем сагайского и качинского диалектов хакасского языка. Экспериментально-фонетическое исследование. Новосибирск: Сибирский хронограф, 2001. 152 с.

*Летягин А. Ю., Ганенко Ю. А., Уртегешев Н. С.* Анатомо-функциональные мышечные механизмы формирования голосового тракта при произнесении аутентичных гласных сибирско-татарского языка по данным магнитно-резонансной томографии // Бюллетень Сибирского Отделения Российской Академии Медицинских Наук. Том: 33, № 5, 2013. С. 10–17.

*Салимов Х. Х.* Вокализм барабинского диалекта татарского языка (экспериментально-фонетическое наблюдение) // Исследования звуковых систем языков Сибири. Новосибирск, 1984. С. 17–22.

*Сарбашева С. Б.* Фонологическая система туба-диалекта алтайского языка (в сопоставительном аспекте). Новосибирск: Сибирский хронограф, 2004. 244 с.

*Селютина И.Я.* Кумандинский вокализм. Экспериментально-фонетическое исследование. Новосибирск: Сибирский хронограф, 1998. 185 с.

*Уртегешев Н.С.*, *Ганенко Ю.А.* Сибирскотатарский язык: артикуляционные настройки гласных по данным МРТ // Сибирский филологический журнал. 2013. № 3. С. 187–191.

*Феер Б. Б.* Акустические характеристики гласных кетского языка: (пакулихинский говор). Новосибирск: Изд-во СО РАН, 1998. 134 с.

*Шалданова А.А.* Вокализм диалекта алтай-кижи в сопоставительном аспекте. Новосибирск: Сова, 2007. 280 с.

*Уртегешев Н.С.* О-образные гласные восточного диалекта башкирского языка: по данным МРТ // Научное обозрение Саяно-Алтая, № 3(27), 2020. С. 47–51.

***Рыжикова Татьяна Раисовна,***
*филология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Филология институтының Себер халыклары телләре секторы өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145; 81`374

***Р.Т. Сәфәров***

# ТЕЛ КУЛЬТУРАСЫ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК АКТИВ СҮЗЛЕК

У лексикографов было и есть большое желание составить такой словарь, который отвечал бы на все запросы пользователей. В начале XXI века на фоне активного развития мировой лексикографии стали появляться новые типы лексикографических источников, которые приближают нас к некому идеальному словарю. В данной статье мы попытались показать специфику одного из таких лексиконов, названного в русской лексикографии активным словарем, проиллюстрировав его примером из татарского языка (словом сугыш ‘война’). В краткой форме была описана зональная структура, наиболее важные составляющие предполагаемого словаря. На наш взгляд, такой труд актуален для татарского языка и для тех, кто хочет правильно на нем говорить.

**Ключевые слова:** лексикография, татарский язык, типология словарей, активный словарь, пассивный словарь.

The lexicographers had and still have a great desire to compile a dictionary that would answer all user requests. At the beginning of the XXI century, against the background of the active development of world lexicography, new types of lexicographic sources began to appear, which bring us closer to a certain ideal dictionary. In this article, we tried to show the specifics of one of these lexicons, called an active dictionary in Russian lexicography, illustrating it with an example from the Tatar language (the word сугыш is ‘war’). We described a zonal structure, the most important components of the proposed vocabulary in short form. In our opinion, such a work is relevant for the Tatar language and for those who want to speak it correctly.

**Key words:** lexicography, Tatar language, typology of dictionaries, active dictionary, passive dictionary.

Тел белемендә *лексикографик компетенция* дигән төшенчә бар. Бу төшенчә танып белү һәм коммуникатив мәсьәләләрне чишү өчен сүзлеккә мөрәҗәгать итү кирәклеген аңлау, сүзлекнең төрен һәм жанрын исәпкә алып, кирәкле лексикографик басманы сайлый белү, сүзлек текстын кабул итә һәм аннан сүз турында кирәкле мәгълүматны ала, төрле сүзлекләрне чагыштыра белүне белдерә [Козырев, Черняк, б. 12–13].

Мондый компетенциянең булмавы (яки бик түбән булуы) сүзлектән тиешле дәрәҗәдә файдаланырга мөмкинлек бирми, сүзлекне укудан интеллектуаль канәгатьлек алу турында сүз дә бара алмый. Без бүген татарлар арасында лексикографик культура үсешен шактый түбән дип бәялибез. Һәрхәлдә, ниндидер сүзнең мәгънәсен, әйтелешен яки башка үзенчәлеген карау өчен сүзлеккә мөрәҗәгать итү

гадәти күренеш диюе кыенрак. Ә менә Роберт Илсонның мәгълүматларына караганда, инглиз гаиләләренең 90%ында ким дигәндә (!) бер аңлатмалы сүзлек бар икән; Британиядә сүзлекләр рецепт китапларына (гаиләләрнең 70 %да бар) һәм хәтта Библиягә (гаиләләрнең 80%да бар) караганда популяррак булып чыккан [Ilson, б. 1]. Болар – инглизләрнең үз телләренә, аны дөрес кулланырга тырышуларына, яңа яки билгесез сүзләрнең мәгънәләрен белүгә нинди зур әһәмият бирүен күрсәтә торган саннар.

Без, ни кызганыч, мондый саннар белән мактана алмыйбыз. Югыйсә татар материалында да аңлатмалы сүзлекләр дә, тәрҗемәле сүзлекләр дә төзелеп, нәшер ителеп тора. Мондый типтагы һәм башка төрле сүзлекләр турында библиографик күрсәткечләргә карап кына да фикер йөртергә була. Аларның иң тулылары – Г.К. Якупованың «Библиография по татарскому языкознанию (1778–1980)» (1988), Ф.С. Хәкимҗанов һәм Т.Х. Хәйретдиноваларның «Татар теле белеме библиографиясе (1981–1997)» (1998), К.М. Миңнуллин һәм Р.Н. Вәлиуллинарның «Татарский язык в словарях: библиографический указатель (1801–1998)» (1998), Р.Н. Кәримуллина, К.Р. Галиуллин һәм Г.Н. Кәримуллиналарның «Государственные языки Республики Татарстан в словарях: аннотированный библиографический указатель (1951–2015)» (2017).

Бу мәкаләдә югарыдагы күрсәткечләрнең берсендә дә булмаган сүзлек тибына тукталып үтмәкче булабыз. Рус лексикографиясендә Ю.Д. Апресян аны *актив сүзлек* дип атый [Активный словарь..., т. 1, б. 5]. Галим фикеренчә, «актив сүзлек» дию пассив сүзлекләрнең булуын да танырга мәҗбүр итә. Шуңа күрә дә бу терминнарның берникадәр шартлы булганлыгын да әйтеп үтә. Чыннан да, сүзлекләрнең типологиясен тасвирлаган фәнни хезмәтләрдә без актив һәм пассив сүзлекләрнең булуы турында мәгълүмат тапмадык [Козырев, Черняк, б. 64–72]. Әмма Ю.Д. Апресян тәкъдим иткән терминнардан файдаланып, аларның нindилекләрен, аермалары нәрсәдә булуын күрсәтеп үтмәкче булабыз.

*Пассив сүзлекләр* кемнәрнең дә булса билгеле бер телдә язылган текстларын аңлау өчен төзелә. Бу максатка сүзләрнең формалары һәм мәгънәләре турында иң гади мәгълүматны җиткерү белән ирешелә, еш кына ул сүзләрнең кулланылыш үрнәкләре дә бирелми. Пассив сүзлектә бик күп сүзләр булырга тиеш, югыйсә кулланучы нинди дә булса ирекле текстны аңлау өчен кирәкле чаралар белән тәэмин ителмәгән була.

Татар телен чагылдырган иң тулы пассив сүзлекләр буларак 1966 елда басылган «Татарча-русча сүзлек» (38 000 баш сүз), 1977–1981 елларда дөнья күргән өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (32 880 баш сүз, 14 010 тезмә сүз һәм фразеологик берәмлек), 2005 елда чыккан бер томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (52 000 баш сүз, 6 000гә якын фразеологизм), 2007 елгы ике томлы «Татарча-русча сүзлек» (56 000 баш сүз, 7 400 фразеологизм), 2015–

2021 елларда нәшер ителгән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (чама белән 70 000гә якын баш сүз, 10 000нән артык фразеологизм, төгәл саны әлегә билгеле түгел, алтынчы том төзелү процессында) күрсәтергә мөмкин. Бу сүзлекләр ярдәмендә татарча тексттагы аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен яки русчага тәрҗемәләрен ачыклап була. Болар татар теленең иң тулы сүзлекләре, шулай да сүз саны ягыннан башка телләрнең күпкә күләмлерәк лексикографик чыганаклары бар. Чагыштыру өчен, инглиз теленең 2004 елда нәшер ителгән сүзлегендә лөгатьлекне 350 000 сүз тәшкил итә.

Югарыда телгә алынган алты томлы сүзлектән, пассив сүзлектәге бер үрнәк буларак, ‘сугыш’ мәкаләсенә тукталыйк.

**СУГЫШ** *и.* 1) Сугу (*1 мәгъ.*) хәрәкәте; сугу рәвеше. *Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың.* А. Шамов

2) Бер-береңә сугу, кыйнаш. *Урамнарда гауга, сугыш, кеше кыйнаш кебек күренешләргә тап булмадым.* Р. Батулла. *Берәрсенең борыны яки ияге дә җимерелсә тагын, театр да килми торган авылыбыз өчен ай буе көлә-көлә сөйләрлек, күңел ачарлык тамаша итеп кабул иткән булыр идек ул сугышны.* Ф. Баттал

3) Төрле дәүләтләр, илләр, армияләр һ.б.ш. арасындагы кораллы көрәш. *Сугыш беткәнгә өч-дүрт ел узган булса да, рәтле тормыш күргән юк әле безнең.* Р. Сәгъди

4) Шул көрәшнең аерым бер бәрелеше. *Кичә каты сугыш булды. Немецларны тозлап-борычлап пешердек.* Г. Кутуй. *Әмма Рига өчен сугышта немец шулчаклы нык каршылык күрсәтте, хәтта күпне күргән сугышчыларның да моңа исләре китте.* Х. Камалов [Татар теленең..., б. 221].

Мәкаләнең күләмен берникадәр чикләү өчен, фразеология өлешенә кермәскә булдык.

*Актив сүзлекләр*, беренче чиратта, потенциаль кулланучыны билгеле бер телдә үз текстларын дөрес төзү өчен кирәк булган бар нәрсә белән дә тәэмин итү өчен эшләнә. Бу ноктадан караганда, сүзлектәге сүзләр саны күпкә азрак та булырга мөмкин. Шул ук вакытта һәр сүз турында мәгълүмат мөмкин кадәр тулы булырга тиеш. Сөйләмдә сүзләрне дөрес һәм урынлы куллану өчен, аларның грамматик формаларын һәм мәгънәләрен генә белү җитми. Болар белән бергә сүзнең төрле мәгънәләренең стилистик, синтаксик һәм башка сүзләр белән бәйләнеш үзлекләре, просодик кагыйдәләре, кулланышларының прагматик шартлары, синонимнары, антонимнары, конверсивлары, дериватлары һәм аналоглары, лексик дөньясы һ.б. үзләштерелергә тиеш. Әлеге категорияләрне чагылдыру өчен, югарыда телгә алынган ‘сугыш’ лексемасын алып карыйк. Сүзлек мәкаләсен төзү үрнәге булып «Рус теленең актив сүзлеге» хезмәт итте. Шуны да искәртергә кирәк: күләмне берникадәр чикләү максаты белән, без биредә ‘сугыш’ сүзенең аңлатмалы сүзлектәге 3 нче мәгънәсен генә алдык.

**СУГЫ́Ш**, *и.*; тарт. *-ы*; юн. *-ка*; чыг. *-тан*

*Сугыш вакытында ул эвакуацияләнә. Сугыш чоры балалары. Сугышка ул үзе теләп китте. Бөтендөнья сугышлары.*

МӘГЪНӘ. *А3 өчен А1 белән А2 арасындагы сугыш* 'А3 максатына ирешү өчен, А1 һәм А2 дәүләтләре, халыклары яки зур төркемнәре арасындагы кораллы көрәш'.

БАШКАРЫЛЫШ.

А1▪ юн. *каршы*: *Япониягә каршы сугыш*

▪ нинди: *бактериологик сугыш*

А2▪ баш. *белән*: *илбасарлар белән сугыш*

▪ нинди: *дәһшәтле сугыш*

А1 + А2 ▪ баш. *белән* баш. *арасында(гы)*: *Көньяк белән Төньяк арасындагы сугыш*

▪ күпл. баш. *арасында*: *күрше дәүләтләр арасында сугыш*

А3▪ баш. *өчен*: *ватан өчен сугыш*[1]

📌 А1 ролендә, илләр, халыклар, кабиләләр исемнәре белән беррәттән, императорлар, патшалар яки гаскәрбашлар исемнәре дә кулланыла ала: *Аксак Тимер сугышлары*.

ЯРАШУ. *Дәһшәтле <авыр, каты, канкойгыч, рәхимсез, зур> сугыш; игълан ителмәгән <игълан ителгән> сугыш; бактериалогик сугыш; локаль <региональ> сугыш; 1812 елгы сугыш; сугыш вакыты <чоры, еллары>; сугыш кыры <мәйданы>; сугыш хәрәкәтләре; сугыш кирәк-яраклары; һөҗүм <саклану, оборона> сугышы, азатлык сугышы, атом <төш> сугышы, партизан[нар] сугышы; гражданнар <ватандашлар> сугышы; Кырым <Әфган> сугышы; Бөек Ватан сугышы; Беренче <Икенче> бөтендөнья сугышы; август сугышы, егерменче гасыр сугышы; диңгездә <коры җирдә> сугыш; азатлык өчен сугыш; сугыш ветераны <инвалиды>; сугыш корал[лар]ы; сугыш башлану <бетү, тәмамлану>; сугыш чыгу; сугыш башлау; сугыш игълан итү; сугыш алып бару, сугышта җиңү <җиңелү>; сугышка китү; сугышта һәлак булу <үлү, шәһид китү>; сугыштан кайту; сугыш бару; сугышка кадәр <хәтле>, сугыш алдыннан, сугыштан соң, сугыш вакытында, сугыш турында <хакында>.*

🕮 *Күңелне әллә нинди кара шом баса, гүя кайдадыр канлы сугыш башланган да шуның шәүләсе монда төшкән* (Г. Әпсәләмов). *Сугыш бәетләре (француз сугышы, төрек сугышы, япон сугышы, герман сугышы, гражданнар сугышы турындагы бәетләр)* (Гали Рәхим). *Шуңа күрә дә без тыныч тормышның кадерен белергә, яңа сугышны булдырмаска тиешбез* (Р. Миңнуллин)

СИН: *хәрби хәрәкәт, хәрби конфликт, кораллы конфликт,* иск. *орыш, яу*; ДЕР: *сугышчы, сугышташ, сугышчан.*

[1] Башкарылыш зонасының материалы лексеманың семантик актантлары белән бәйле. Үрнәк итеп бирелгән схемалар аңлатмадагы барлык актантларны тасвирламый, алар зонаның нindилеген күрсәтү өчен җитәрлек санда гына бирелде.

Күренгәнчә, шартлы актив сүзлектә ‘сугыш’ сүзенең дүрт лексемасыннан берсе турында гына бирелә торган мәгълүмат шартлы пассив сүзлектә күрсәтелгән бөтен сүз турындагы мәгълүматка караганда бермә-бер күбрәк.

Сүз төркеменә, куллану ешлыгына, фразеологизмнар ясавына һ.б. билгеләренә карап, актив сүзлектәге баш сүз турындагы мәгълүматны тәшкил иткән мәкалә төрле зоналарга бүленә. «Рус теленең актив сүзлеге»ндә сүзлек зоналарының саны 13 кә кадәр җитәргә мөмкин:

1. Грамматик һәм стилистик мәгълүматы бирелгән вокабула исеме (баш сүз). Гадәттә, рус теле сүзлекләрендә грамматик категорияләрдән сүз төркеме, грамматик җенес, сүзнең иялек килешендәге формасы, төрләнүдә кыенлык тудырган башка формалар бирелә.

2. Синопсис, яки сүзлек мәкаләсенең кыскартылган формасы (күпмәгънәле сүзләр өчен, чөнки мондыйларның тасвирлау күләме бик зур була ала).

3. Лексема бирелеше (әгәр сүз күпмәгънәле булса), шулай ук грамматик һәм стилистик мәгълүматы белән.

4. Сүз яки лексеманың кулланышына мисаллар. Бу очракта барлык мисаллар да лексикографлар тарафыннан тәкъдим ителә һәм, гадәттә, сүзтезмәләр итеп бирелә.

5. Сүз яки лексеманың мәгънәсен аңлату. Зона билгесе – МӘГЪНӘ. Мәгънә башта субъект яки субъектлар һәм объект яки объектлар санынча шартлы схема рәвешендә, шуннан соң аңлатмалы сүзлекләрдәге кебек дефиниция формасында бирелә.

6. Аңлатмага комментарийлар. Зона билгесе – 📌. Сүзлектәге лексеманың аңлатмасы, билгеле, бөтен нечкәлекләрне исәпкә алып бетерә алмый. Менә комментарийларда шул нечкәлекләр күрсәтелә.

7. Башкарылыш моделе (предикатлы лексемалар өчен). Зона билгесе – БАШКАРЫЛЫШ. Биредә анализлана торган сүзнең башка сүзләр белән нинди чаралар ярдәмендә бәйләнешкә керүе күрсәтелә.

8. Башкарылыш моделенә комментарийлар. Зона билгесе – 📌.

9. Сүз яки лексемага хас актант булмаган синтаксик конструкцияләр. Зона билгесе – КОНСТРУКЦИЯЛӘР.

10. Лексик-семантик ярашу. Зона билгесе – ЯРАШУ. Бу зонада лексеманың һәр сүз төркеменнән нинди сүзләр белән яраша, бәйләнешкә керә алуы күрсәтелә. Зона шактый күләмле булырга мөмкин, чөнки лексемага мөмкин кадәр киң контекст бирелә.

11. Иллюстрацияләр. Зона билгесе – 🕮. Бу зонада, гадәти аңлатмалы сүзлектәге кебек, лексеманың телдә кулланылуын исбатлау максаты белән, матур әдәбияттан, публицистикадан җөмләләр китерелә. Башлыча, хәзерге сүзлекләрдә мондый мисаллар һәр телнең милли корпусыннан алына.

12. Сүз яки лексемаларның лексик дөньясы. «Лексик дөнья» дип шартлы рәвештә сүзлектә баш сүз белән бәйле булган зур гына катлам лексик берәмлекләр аталган. Боларга синонимнар, аналоглар, конверсивлар, антонимнар һәм дериватлар керә. Моннан тыш, баш сүзнең

яки лексеманың синонимы (антонимы һ.б.) буларак башка лексемалар гына түгел, сүзтезмәләр һәм хәтта фразеологизмнар да карала.

13. Бөтен сүзгә караган фразеология. Зона билгесе – ♦. Фразеология бирелеше үзе аерым җентекле тасвирлауны таләп иткәнгә, ул өлешкә без аерым туктап тормадык.

Шулай итеп, мондый төр сүзлек лөгатьлегендәге сүз һәм аның аерым мәгънәләре (лексемалары) турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат бирүне күздә тота. Анда сүзнең грамматик билгеләре һәм просодиясеннән алып, семантик, синтаксик, фразеологик, контекстуаль үзенчәлекләренә кадәр башка бер сүзлектә дә бу рәвештә бирелми торган тулы мәгълүмат урын ала.

Безне кызыксындырган мәгънәдә актив лексикографиянең туган елы буларак 1910 ел каралырга тиештер. Нәкъ шул елда Альбрехт Ройм тарафыннан төзелгән «Petit dictionnaire de style à l'usage des Allemands» француз сүзлегенең Лейпцигта беренче басмасы дөнья күрә. 20 еллап вакыт үткәч (1931 елда), шул ук авторның «A Dictionary of English Style» инглиз сүзлегенең беренче басмасы нәшер ителә. Ике сүзлеккә дә якынча алты мең чамасы сүз кертелгән, исемнәр һәм фигыльләр генә диярлек, ләкин һәр сүз турындагы мәгълүмат шактый күләмле һәм аерым милли телнең тулы аңлатмалы сүзлеге белән чагыштырыла ала. Илленче еллар башында ике сүзлек тә ул вакыттагы ГДРда кабат басылып чыга. Шулай булуга карамастан, узган гасырның кырыгынчы еллары ахырында төрле Европа илләрендә актив типтагы сүзлекләр туплангач, бу жанр асылда дәвам ителмәде, яңадан ачылды, дип саный белгечләр [Апресян, б. 120].

Хәзерге актив сүзлекләрнең берьюлы берничә максаты бар. Беренчедән, алар ана телләрендә сөйләшкән кешеләрнең тел культурасын үстерү өчен эшләнә. Икенчедән, алар телне чит тел буларак өйрәнүчеләрнең ихтыяҗларына хезмәт итәләр. Өченчедән, алар билгеле бер телдә сөйләшүче халыкның бөтен тел культурасы ачкычы ролен уйныйлар, һәм шул рәвешчә бу культураны дөньяда таныту өчен үтә әһәмиятле функция үтиләр.

«Рус теленең актив сүзлеге» РФА Рус теле институтында 2006 елда төзелә башлый. 2014 елда аның беренче (А–Б хәрефләре), икенче (В–Г хәрефләре), 2017 елда өченче (Д–З хәрефләре) томнары дөнья күрде [Активный словарь..., т. 1, 2, 3]. Сүзлек өстендә эш дәвам итә.

Бу фонда татар лексикографиясенең калышуы күзәтелә. Гәрчә татар материалында актив типтагы сүзлек төзү өчен җитәрлек нигез чыганаклар бар. Монда, беренче чиратта, алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н һәм Татар теленең язма корпусы (https://www.corpus.tatar), Татар матур әдәбияты корпусы (http://litcorpus.antat.ru/), «Туган тел» татар гомумтел корпусы (http://www.tugantel.tatar/) кебек ресурсларны күз уңында тотабыз. Болардан тыш, актив сүзлекнең төрле зоналарын эшләгәндә ярдәмче чыганак булырлык хезмәтләр, мәсәлән, И.Ф. Зарипованың «Татар телендә сүзләр бәйләнеше

сүзлеге» (Уфа, 2012, 2013), Ш.С. Ханбикова белән Ф.С. Сафиуллинаның «Татар теленең синонимнар сүзлеге» (Казан, 2014) һ.б., һәм иң мөһиме, бу эшне башкарырлык тәҗрибәле практик лексикографлар бар. Хәзергә татар теленең актив типтагы сүзлеген төзү бурычы, һичьюгы исемнәр яки сыйфатлар өчен булса да, актуаль эш юнәлеше булып кала бирә.

**Әдәбият**

Активный словарь русского языка / В.Ю. Апресян, Ю.Д. Апресян, Е.Э. Бабаева и др.; отв. ред. Ю.Д. Апресян. М.: Языки славянской культуры, 2014. Т. 1. 408 с.

Активный словарь русского языка / В.Ю. Апресян, Ю.Д. Апресян, Е.Э. Бабаева и др.; отв. ред. Ю.Д. Апресян. М.: Языки славянской культуры, 2014. Т. 2. 736 с.

Активный словарь русского языка / В.Ю. Апресян, Ю.Д. Апресян, Е.Э. Бабаева и др.; отв. ред. Ю.Д. Апресян. М.; СПб.: Нестор-история, 2017. Т. 3. 768 с.

*Апресян Ю.Д.* О проекте активного словаря русского языка // Вестник Российского гуманитарного научного фонда. М., 2009. № 3 (56). С. 118–130.

*Козырев В.А., Черняк В.Д.* Лексикография русского языка: век нынешний и век минувший: монография. 2-е изд., испр. и доп. СПб.: Изд-во РГПУ им. А.И. Герцена, 2015. 631 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V том: С–Т / төз. Э.И. Сафина, И.И. Сабитова, О.Н. Галимова һ.б.; фәнни ред. Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров. – Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

Ilson R. Introduction // Dictionaries, Lexicography and Language Learning / Robert Ilson. London: Pergamon Press Ltd. and The British Council, 1985. 136 s.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире*

УДК 81-11

***Р.В. Шәйдуллин***

# XX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРЕГЕНДӘ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТЕЛ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ (Татарстан материаллары буенча)

В статье в контексте современных этноязыковых проблем татарского народа и остальных коренных народов Татарстана поэтапно рассматривается процесс формирования и развития языковых интересов татар в многоэтничном российском обществе в первой четверти XX в. В ней объектами исторического анализа являются дореволюционный, нэповский и современный (путинский) периоды развития консолидирующей функции татарского языка: При этом в статье особое внимание уделяется изучению процесса формирования среднего диалекта татарского языка как основы для создания татарского литературного языка и формирования сугубо этнического лексического словаря, а также предварительных результатов реализации татарского языка в государственных органах власти.

**Ключевые слова:** Татарстан, татары, русские, языковые интересы народов, консолидирующая функция татарского языка, татарская орфография («иске имля», «урта имля», «янга имля»), русификация, этнонигилизм, реализация татарского языка, коренизация.

In the article, in the context of modern ethno-linguistic problems of the Tatar people and other indigenous peoples of Tatarstan, the process of formation and development of the linguistic interests of the Tatars in a multi-ethnic Russian society in the first quarter of the 20th century is considered step by step. In it, the objects of historical analysis are the pre-revolutionary, NEP and modern (Putin) periods of the development of the consolidating function of the Tatar language. At the same time, the article pays special attention to the study of the process of formation of the middle dialect of the Tatar language as the basis for the creation of the Tatar literary language and the formation of a purely ethnic lexical dictionary, as well as preliminary results of the implementation of the Tatar language in state authorities.

**Keywords:** Tatarstan, Tatars, Russians, linguistic interests of peoples, consolidating function of the Tatar language, Tatar spelling («iske imlya», «urta imlya», «yanga imlya»), russification, ethnonihilism, implementation of the Tatar language, indigenousization.

Татарстанда хәзерге этнолингвистик вазгыять күп кенә иҗтимагыйсәяси һәм этномәдәни факторлар йогынтысында формалаша, әлеге факторларның иң мөһиме – республика халкының күпмилләтле составы, төп этносларның аның белән бәйле милли мәнфәгатьләре. Бүгенге көндә күпләп яши торган милләтләр – татарлар, руслар, удмуртлар, марилар, чувашлар, мордвалар, аларның һәркайсының үз этномәдәни традицияләре, әдәби телләре һәм диалектлары бар. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Татарстан Республикасы җитәкчелеге төрле этнослардан торган җәмгыятьтә тел мәсьәләсе

буенча үзара аңлашу һәм татулыкны ныгыту юнәлешендә мөмкин булганның барысын да эшләде. Татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре дип игълан ителде – дәүләт органнары һәм учреждениеләре эшчәнлекләрен, нигездә, шул телләрдә алып баралар, алар билгеле бер дәрәҗәдә гомуми белем бирү мәктәпләрендә дә өйрәнелә [Закон...]. Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү сәясәтенең төп принциплары телләрнең үзара гармонияле бәйләнешын, республиканың күпмилләтле халкының милли һәм тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклауны күздә тота. Нәтиҗәдә Татарстан Республикасында җирле халыкларның мәдәниятен, язу традицияләрен һәм асылын саклап калу, аларның мәдәни һәм тел ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен уңай шартлар тудырылды. Шул ук вакытта республикада халыкларның этник телләренең гамәли кулланылыш даирәләре, шул исәптән аларның гаиләдә һәм көнкүрештә кулланылыш чикләре дә тарая бара. Татарстанның төрле этник составлы шәһәрләренең һәм муниципаль районнарының гомуми һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә татар телен өйрәнүнең торышы да мактанырлык түгел, республиканың башка җирле халык телләре хакында әйтәсе дә юк. Мәсәлән, 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында «рус телен русларның 99,9 проценты һәм татарларның 95,5 проценты, шул ук вакытта татар телен татарларның 92,4 проценты һәм русларның нибары 3,6 проценты белә» [Татарскому...]. Шунысы да әһәмияткә ия, татар телен Татарстанда яшәүче чувашларның 14,1 проценты, удмуртларның – 35, мордваларның – 4,4, марийларның – 29,8, украиннарның – 3,6, башкортларның 65,7 проценты белә [Об изучении...].

Хәзерге вакытта Татарстанда барлык өлкәләрдә дә татар һәм рус телләренең тигез хокуклылыгына ирешү икеле. Моңа билгеле бер дәрәҗәдә хокукый факторлар да тискәре йогынты ясый. Мәсәлән, 2018 елның 3 августындагы 317-ФЗ Федераль законы тарафыннан 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ Федераль законына кертелгән үзгәрешләр нигезендә «Башлангыч гомуми һәм төп гомуми мәгариф программалары буенча дәүләт аккредитациясенә ия учреждениеләргә мәктәпкәчә мәгариф программалары нигезендә укырга кабул иткәндә (башка уку урынына күчергәндә), белем алу теле буларак РФ халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен, РФ республикалары дәүләт телләрен ирекле сайлау, балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла» [Об изучении...].

Бу үз чиратында «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасына сизелерлек үзгәрешләр кертергә мәҗбүр итте. Программаның яңа редакциясеннән күренгәнчә, балалар бакчаларында татар балаларын укыту һәм тәрбияләү буенча

планнар 11,6 процентка (64 проценттан 52,4 процентка кадәр) киметелде [Государственная...; Об изучении...]. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен мәҗбүри өйрәнүне гамәлдән чыгарганнан соң, мәктәпкәчә учреждениеләрдә дә аңа ихтыяҗ калмады. Программаның яңа редакциясендә шулай ук гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телендә белем алучы татар балалары өлешен киметү күздә тотыла [Об изучении...]. «Гомуми белем бирү оешмаларында татар милләтендәге балаларны туган телдә укыту өлеше 40 процент дәрәҗәсендә саклаunion», диелә [шунда ук]. Шул ук вакытта дәүләт программасының элекке редакциясендә әлеге күрсәткечне 43,6 процентка җиткерү бурычы куелган иде [Государственная...].

Үз вакытында «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы 2013 ел ахырында «республикада яшәүче халыкларның милли-тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклау», шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигез хокуклылыгы»на ирешү өчен кабул ителгән иде [Государственная...]. Шул сәбәпле программага кертелгән барлык төзәтмәләр татар зыялыларының күпчелеге тарафыннан фәкать татарларның тел мәнфәгатьләрен кысрыклау, татар теленең функциональ ролен чикләү буларак кабул ителде.

1990 елларда Татарстанда мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирү системасына татар телен тигез хокуклы фән буларак кертү рус телле халыкны татарлаштыру максаты белән түгел, ә күпмилләтле республикада уңай этносара мохит булдыру һәм тел толерантлыгын үстерү өчен шартлар тудыру белән бәйле иде. Ихтимал, рус телле, өлешчә татар телле җәмгыятьтә дә татар теленә карата тискәре этнолингвистик караш тууның сәбәбе аны күпмилләтле шәһәр мәктәпләрендә укыту алымнарында һәм формаларында югары квалификацияле укытучы кадрлар җитенкерәмәү, сыйфатлы программалар, уку-укыту әсбаплары, методик ярдәмлекләр булмау белән бәйле җитешсезлекләрдән һәм кимчелекләрдән гыйбарәт. Әмма болар – хәл ителерлек проблемалар һәм ул кимчелекләрне системалы күренешкә әверелдереп, татар телен мәктәпләрдә мәҗбүри фән буларак укытуга карата чикләү чаралары күрергә кирәк булды микән?

Гомумән, халык (ата-аналар) ихтыярының ихласлыгы һәм татар теленең төрле өлкәләрдә кулланылуының этномәдәни мөмкинлекләрен бәяләү хакында сүз барганда, игътибарны әлеге мәсьәләнең тотрыксыз асылы җәлеп итә. Ул, беренчедән, 2007 елның 7 июнендә имзаланган «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» ике яклы шартнамәнең озайтылмавына бәйле рәвештә,Татарстанда урнашкан иҗтимагый-сәяси вазгыять; икенче яктан, татар җәмгыятенең аерым даирәләрендә хөкем сөргән этнонигилизм (үз халкының этномәдәни кыйммәтләрен кире кагу, этник феномен белән бәйле барлык нәр-

сәләрдән ирекле булуны игълан итү) белән бәйле. Бу факторлар Татарстан гомуми белем бирү мәктәбенә, бигрәк тә татар теленең статусына һәм сакланышына зур зыян китерде.

Россиядә титуллы халыкларның телләренә карата тормышка ашырыла торган сәясәтнең тамырлары тарих төпкелләренә барып тоташа. Рус дәүләте тарафыннан татар ханлыклары яулануга ук, татарлар рус этносәяси даирәсенә тартыла башлый. Татар ханлыклары бетерелгәннән соң беренче ике йөз ел эчендә әлеге процесс, башлыча, татар аксөякләре язмышына кагыла, аларның күбесе этник тел, этномәдәни һәм дини үзлекләрен югалтып, рус җәмгыятенә кушыла. Аксөякләрнең рус телле сәяси мохиткә җәлеп ителгән бер өлеше генә үзләренең нәсел фамилияләрен саклап кала ала. XVII–XVIII гасырларда руслаштыру Идел буе һәм Урал буе татарларын көч кулланып христианлаштыру рәвешендә алып барыла һәм ул татар җәмгыятенең барлык катлауларына да кагыла. Алга таба Россиядә, буржуаз мөнәсәбәтләр үсеше барышында, татарларның рус җәмгыятенә ирексезләп интеграцияләнүе формаларын рус-татар мәктәпләре һәм әҗнәбиләрнең Н.И. Ильминский системасы буенча укытулы миссионерлык мәктәпләре оештырылу юлы белән башкарылган этномәдәни руслаштыру сәясәте алыштыра.

Буржуаз мөнәсәбәтләр татар җәмгыятен этник изоляциядән әкренләп чыгаралар, яңа җәдитчелек идеологиясе аның этномәдәни яшәешенең патриархаль нигезләрен этномилли җәһәттә тикшерүгә булышлык итә. Әлеге системалы үзгәрешләр татарларның мәгариф системасына гына түгел, аларның тел мәнфәгатьләре өлкәсенә дә кагыла. Нәтиҗәдә, XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында төрки-татар тел берләшүе мәсьәләләре буенча татар иҗтимагый фикерендә ике агым барлыкка килә. Аларның беренчесенә җәдитчелек идеологиясенә нигез салучыларның берсе – Кырым татары Исмәгыйль Гаспринский башлангыч бирә. Ул үзенең 1873 елдан Бакчасарай шәһәрендә «бердәм» төрки-татар телендә нәшер ителгән «Тәрҗеман» газетасы сәхифәләрендә төрки халыкларның этномәдәни бердәмлеге һәм алар өчен гомумтөрки әдәби тел (үзенчәлекле «төрки-татар эсперанто»сы) булдыру идеясен алга сөрә. Әлеге агым идеологиясе нигезендә берничә этник бергәлекнең стихияле рәвештә кушылуы һәм тагын да зуррак этник берәмлекләр формалашу процессында телне интеграцияләшүнең төп чараларыннан берсе буларак куллану, шул процесста бергәлекләрнең берсе теленең башка бергәлекләр тарафыннан үзләштерелүе ята. Биредә берләштерүче этник берәмлек теленең таралышы өчен ерәләнүче бергәлек этносларның барысыннан да өстен уртак төрки-татар мәдәни һәм тел нигезләренең булуы зарури шарт булып тора. Бу агым Госманлылар Төркиясенең көчле этносәяси йогынтысында була.

Идел-Урал җәдитчелеге җирлегендә барлыкка килгән икенче бер этномәдәни агымның нигезе татар халкының телен, әдәбиятын, мәгариф һәм тәрбия системасын дөньяви яктан яңарту юнәлешеннән

гыйбарәт. Аңа Шиһабетдин Мәрҗани башлангыч бирә, ул татар халкы килеп чыгышының милли концепциясен тәкъдим итә. Татарларның этник тарихы үсеше юнәлешен тикшереп, галим традиционализмның кайбер тарафдарларының гадәттән тыш җаһиллек аркасында «үз кабиләләреннән никадәр патшалар һәм бөек дәүләт эшлеклеләре булу турында хәбәрдар түгелләр. Хәтта бу өлкәдә читтән тыш наданлыклары аркасында, Мавәраәннәһерда яшәүче сарт халкына ияреп хакыйкатькә каршы килеп, хаклыкка каршы килеп үзләренә "нугай" исемен алып, үз араларындагы сөйләшү-утырышларда шул исемне йөртеп һәм үзләрен шул халыктан дип санасалар да, рус халкының аларны кимсетү, хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән кайберләре татар булуны бер кимчелек санап, ул исеменнән чирканып, без татар түгел, без "мөселман" дип, тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар», дип ассызыклый [Мәрҗани, б. 43]. Мәрҗани үз милләттәшләренә мөрәҗәгать итеп, алардан: «Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың?», – дип сорый [Мәрҗани, б. 44].

Татар милләтчелеге идеологиясе ералу татарларның милли үзаңы формалашу процессын тизләтә, бу исә үз чиратында милли тарих, мәдәният, әдәбият һәм тел белән кызыксынуны көчәйтә. Татар фәнни һәм иҗади зыялылары Ш. Мәрҗани, Г. Әхмәров, Р. Фәхретдин, К. Насыйри, Һ. Атласи, Г. Баттал, М. Бигиев, Х. Габәши, Ә. Вәлиди, Җ. Вәлиди, Г. Исхакый [Атласов, 1911; 1914; Баттал, 1912; Бигиев, 1916; 1917; Вәлиди Ә., 1912; Вәлиди Җ., 1912; 1914; Габәши, 1897; 1899; 1909; Исхакый, 1906] һәм аларның эшен дәвам итүчеләрнең күпсанлы хезмәтләре татар халкының этник тарихын, аның дәүләти берләшмәләрен, халык традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен, шулай ук мөселман дөньясының татар җәмгыятенең эволюцион үсеше процессына йогынтысын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр.

Әлбәттә, инкыйлабка кадәрге татар интеллектуаль җәмәгатьчелеге тарафыннан алга сөрелгән концепция төрки-татар этник бергәлекләренең стихияле кушылуы һәм Госманлылар Төркиясе канаты астында зуррак этник берәмлек булдыру идеясенә каршы килеп кенә калмады, ә гомумтатар әдәби телен, дөньяви әдәбиятын, яңа ысуллы мәгариф системасын булдыру контекстында Россия империясендәге төрки-татар халкының таркау төркемнәрен берләштерүнең үзенчәлекле, милли формасын сайлауга да булышлык итте. Өстәвенә, күп кенә татар зыялылары Исмәгыйль Гаспринскийның барлык төркиләр өчен дә тел бердәмлеге турындагы идеяләрен кире какмады, шул ук вакытта алар татар язуын яңарту һәм гадиләштерү өчен мөмкин булганның барысын да эшләделәр, чөнки төп максат – Коръән һәм дини әдәбият укуны тәэмин итү татар дөньяви җәмгыятенең милли язу һәм гомумтөрки бәйләнышлар булдыру ихтыяҗларына җавап бирми иде инде. Нәкъ менә XX гасыр башында татар язуының тарихи формасын – «иске имля»ны үзгәртеп кору һәм шуның нигезендә татар сүзләре әйтелешен билгеләү өчен, күбрәк язу детальләрен өстәүче

«урта имля»ны булдыру юнәлешендә тәүге омтылышлар ясала. Тел белгечләре күпгасырлык гарәп йогынтысын инкяр итүче һәм гамәлдән чыгаручы саф татар язуы булдыруга омтылмыйлар, аларның төп максаты, татар халкының киң катлауларын агарту өчен, язуның гади культурасын тудырудан һәм «иске имля»ның мәдәни-тел системасына керү чикләрен киметүдән гыйбарәт була, чөнки гарәп-фарсы мәдәниятенә шактый тирән үтеп кергән кеше укымышлы санала алган. Шул ук вакытта татар теленең лексик нигезен гарәп, фарсы һәм төрек алынмаларыннан арындыру бара, алар татар теленең күпсанлы сөйләм диалектларыннан алынган сүзләр, өлешчә төрки тамырлар җирлегендә уйлап чыгарылган яңа терминнар һәм төшенчәләр белән алмаштырыла. Бу процесс татар телен үзгәртеп кору һәм Казан диалектын этнолингвистик инструмент буларак раслау, татар җәмгыятен этномәдәни үзәкләштерү һәм берләштерүнең башлангыч этабы була.

XX гасыр башында татар этнолингвистик фикерендә татар язуын гарәп имлясыннан латин имлясына күчерү идеясе туа. Әлеге идея татар әдибе, журналист һәм тәрҗемәче Сәгыйть Рәмиевнең 1911–1912 елларда «Идел» газетасында басылган мәкаләләрендә, шулай ук 1907–1908 елларда дусларына латин хәрефләре белән язылган хатларында чагылыш таба. С. Рәмиев латинлаштырылган татар язуында «калын сузыклар» диграфларын (ea, eu, eo,ei) кулланырга тәкъдим итә [Закиев, 2005].

1920 елда Татарстан АССР төзелгәннән соң, дәүләт белән идарә итү системасын камилләштерү һәм сәясәткә татар халкының киң катлауларын җәлеп итү республиканың барлык территориясендә дә бертөрле кулланылышка ия аңлаешлы рәсми әдәби телдән башка мөмкин түгел иде. Нәтиҗәдә, татар теленең Казан диалекты Татарстанда татар халкының милли мәнфәгатьләрен тормышка ашыру сәясәтенең үзәгендә урын ала. Шулай итеп, бердәм әдәби тел җирлегендә мәгарифне стандартлаштыру татар халкының милли үзаңын үстерү процессында мөһим фактор булып тора. Ачык прагматик ниятләрдән чыгып, Татарстан җитәкчелеге республикада көн күргән татарлар арасында аралашуны мөмкин кадәр гадиләштергән милли әдәби телне сайлап ала. Шул рәвешле, ул милләт рухы буларак тәгаенләгән тел мәнфәгатьләрен сәяси көчкә әверелдерә.

Бу сәясәт нигезендә, хакимият, РСФСР һәм ТАССР арасында вәкаләтләрне бүлешүдән бигрәк, татар теленең сәяси һәм этномәдәни статусы белән бәйле көнүзәк мәсьәләләр ята. Өстәвенә, ул чорда тел милләтчелеге татар җәмгыятенең нәкъ менә мәнфәгатьләре дөньяви әдәби телне рәсми куллану белән бәйле көчләрендә зур кызыксыну уята. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 1920 ел ахырында ук ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1920 ел 19 декабрь Декреты белән татар телендә гарәп язуын куллану төгәлләштерелә һәм гадиләштерелә – алфавиттан кайбер күпфункцияле тартык авазлар хәрефләре һәм билгеләре алына, алты сузык авазлар хәрефләре һәм

авазның йомшаклыгын һәм ныклыгын күрсәтүче бер билге өстәлә. Яңа татар язуы «яңа имля» дип атала. 1925 елның ноябрендә ТАССР Мәгариф халык комиссариатының Академик үзәге «яңа имля»ның барлык совет учреждениеләрендә, мәктәпләрдә һәм татар матбугатында кулланылуы мәҗбүрилеге хакында карар чыгара. Асылда, «яңа имля»ны эшләүчеләр күпгасырлык гарәп йогынтысын инкяр итүче һәм гамәлдән чыгаручы татар язуын булдырырга омтылмыйлар, алар гомуми белем бирү, урта һөнәри һәм югары уку йортлары системасында укучы татарлар өйрәнсенгә, шулай ук Татарстанда документлар әйләнешендә куллану өчен гарәп имлясын һәм язу культурасын гадиләштерергә тырышалар.

Татар алфавитын камилләштерү белән беррәттән татар халкының кулъязма һәм басма китап мирасын җыю буенча актив эш алып барыла, аның барышында көнчыгыш һәм төрки-татар кулъязмаларын өйрәнүгә генә түгел, татар теленең сүзлек запасын тулыландыруга да зур игътибар бирелә. Татар авыллары буйлап оештырылган археографик сәфәрләр вакытында С. Вахиди тарафыннан 3 меңнән артык Урта гасырлар һәм соңрак чорлар кулъязмалары, Җ. Вәлиди тарафыннан 1 меңнән артык кулъязма китап, шулай ук татар диалектологиясе буенча бай материал туплана. Татарстан галимнәренең нәтиҗәле археографик эшчәнлеге киләчәктә орфография, диалектология һәм лексикология өлкәләрендә тикшеренүләр уздыру өчен кирәкле китап-кулъязма мирасханәсе оешуга этәргеч бирә. Җыелган археографик материалның зур өлеше Җ. Вәлиди әзерләгән «Татар теленең тулы сүзлеге» (1927–1929, 1–2 нче кисәкләр) лексикасы нигезенә салына [Вәлиди, 1927]. Галим тарафыннан, филология профессоры В.Х. Хаков мәгълүматлары буенча, 1927 елга кадәр татар теленең сүзлек запасына 15 меңнән артык термин һәм төшенчә кертелә [Габдрафикова].

Шул ук вакытта мәгънәләре буенча совет чынбарлыгына туры килгән яңа терминнарга һәм төшенчәләргә ихтыяҗ даими рәвештә арта бара. Әлбәттә, Көнбатыш Европа һәм рус телләрендәге сүзләрне әйләнешкә кертү телне гадиләштерә һәм аны өйрәнүне җиңеләйтә. Әмма Европа телләреннән, бигрәк тә рус теленнән алынмалар фонетика җәһәтендә җайлаштырылмыйча гына кулланыла, бу исә татар теленең гомуми яңгырашын үзгәртә.

Татар сәяси элитасының икенче бер мөһим этнолингвистик акциясе – рус теле белән беррәттән татар теленә дәүләт теле статусы бирелү. Әлеге мәсьәлә тәүге мәртәбә 1921 елның 14 февралендә ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы утырышында карала һәм озакка сузылган бәхәсләрдән соң татар телен Татарстанның барлык партия һәм дәүләт органнарында эш кәгазьләрен алып баруга кертү хакында карар кабул ителә. Бер үк вакытта бу мәсьәлә РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретариаты утырышында тикшерелә [Климов, с. 8]. 1921 елның 17 февралендә милли азчылыклар секцияләре секретарьлары утырышы булып уза, анда ТАССР

Үзәк Башкарма Комитеты каршында милли азчылыклар бүлеге оештыру турындагы мәсьәлә карала. Әлеге утырышларның нәтиҗәсе ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты каршында милли азчылыклар бүлеге оештыру һәм чувашлар, керәшен татарлар, марилар, яһүдләр һәм поляклар секцияләре составына тәҗрибәле партия хезмәткәрләрен тәкъдим итү хакында карар кабул ителүдән гыйбарәт була [Климов, б. 8]. 1921 елның 25 июнендә Татарстан җитәкчелеге татар телен Татарстанда дәүләт теле буларак гамәлгә ашыру хакында Декрет кабул итүгә ирешә, бу исә татарларның этник теленә дәүләт теле статусы бирә һәм татарлар күпчелекне тәшкил иткән совет учреждениеләрендә һәм предприятиеләрдә эш кәгазьләрен татар телендә алып баруга күчү өчен шартлар тудыра [Кириллова, б. 10].

Шул ук вакытта, билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан АССР оешу көнендә кабул ителгән Декрет декларатив характерда иде. Әлеге закон акты барыннан да бигрәк татар җәмәгатьчелеген тынычландыру һәм аны Татарстандагы икътисади җимерeклеккә каршы көрәшкә туплау өчен кабул ителә. Моннан тыш, бер яктан, татар халкының тел мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру сәясәте һәм аның белән бәйле Татарстан дәүләт аппаратын этник яктан тамырландыру (коренизация) барса, икенче яктан, татар халкының элеккеге патша администрациясе дәүләт структурасына аз җәлеп ителүе – болар барысы да республиканың административ берәмлекләрендәге халыкның күпмилләтле составы белән катлауланды. Бу җәлеп ителәсе кадрларның татар телен һәм язуын гына түгел, рус телен дә яхшы белүләрен, аларның тиешле профессиональ белемнәргә һәм идарә итү күнекмәләренә ия булуларын таләп итте. Өстәвенә, Декретны тулысынча гамәлгә ашыру өчен гаять зур финанс чыгымнары сорала иде. Сәнәгатьтә һәм авыл хуҗалыгында хөкем сөргән икътисади җимерeклек (1921–1922 еллардагы корылык), шулай ук халыкның ачлык кичерүе шартларында әлеге чараны уздыру кыенлаша.

Нәтиҗәдә, Татарстанның дәүләт һәм иҗтимагый учреждениеләрендә татар телен гамәлгә ашыру эше башлыча законнар чыгаруга кайтып кала. Мәсәлән, 1922 ел дәвамында татар телен гамәлгә ашыру программасының агымдагы мәсьәләләре буенча Татарстан республикасы хакимиятенең 3 закон акты кабул ителә, алар арасында әлеге өлкәдә эшнең гамәли һәм конкрет юлларын билгеләүче төп акт – «ТССР дәүләт учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә татар телен гамәлгә ашыру буенча инструкция» [Татарстан..., б. 14]. Инструкциядә шактый ук конкрет дәрәҗәдәге бурычлар куела, рус һәм татар телләренең гамәли тигез хокуклылыгына ирешү юллары билгеләнә. Анда, татар телендә эш башкаруны гамәлгә кую белән беррәттән, дәүләт учреждениеләрендә рус һәм татар телләрен ирекле куллану өчен шартлар булдыру кирәклеге аеруча ассызыклана. Документта шулай ук совет аппаратына татар милләте вәкилләрен җәлеп итү, төп милләт вәкилләреннән кадрлар әзерләү, рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү буенча конкрет чаралар күрсәтелә.

Алга таба, 1923–1925 еллар дәвамында, татар телен гамәлгә кертү өлкәсендә тагын берничә яңа карар кабул ителә. Аларда күпчелекне татарлар тәшкил иткән халыкка хезмәт күрсәтүче барлык учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә татар телендә актив эш алып бару карала. Моннан тыш, Татарстанда яшәүче азчылыкларга карата аерым чаралар күздә тотыла – аларга норматив рәвештә туган телләрендә аралашу, шулай ук ике дәүләт теленең уңайлы булганында язмача аралашу тәэмин ителә [За 5 лет, с. 42]. Бу карарлар барысы да Татарстанда татар телен гамәлгә ашыру буенча элек кабул ителгән норматив актларның аерым нигезләмәләрен, әлеге өлкәдә «республикада ике тел – татар һәм рус телләре бер үк төрле хокукта дәүләт телләре булып тора» принципларында корылган гамәли эшчәнлекне конкретлаштыруга булышлык итә [Татарстан..., б. 14].

Әлеге чорда Татарстанда татар халкының тел мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруда билгеле бер уңышлар да күзәтелә. Бу хакта статистик күрсәткечләр шаһитлек итә: 1921 елда Татарстанда татар авыл советларының 20 процентында, 1923 елда – 50, 1924 елда – 80, 1925 елда 85 процентында эш башкару татар телендә алып барыла [Климов, с. 26].

1924 елда, эш башкаруны төп халыкларның милли телләренә күчерүне тизләтү максатында, Татарстанда беренче тапкыр волостьларны милләтләрнең санына карап төзиләр. Нәтиҗәдә күпчелегә бер милләтле волостьларның саны 2,5 мәртәбә (22 дән 55 кә кадәр) арта [Климов, б. 27]. Реформадан соң татар халкы тупланып яшәгән волостьлар шактый күбәя. Аерым алганда, 1925 елның 1 февраленә татарлар 125 волостьның 81 ендә күпчелекне, 20 волостьта, киресенчә, алар азчылыкны тәшкил итә [Татарстан..., б. 16]. Әмма татарларның тупланып яшәве белән волостьларда документлар әйләнешенең татар теленә күчерелүе җиңел генә тәэмин ителми. Әйтик, татарлар күпчелек булган 80 волостьның нибары 43 ендә генә (53,7 процент) – тулысынча, 18 волостьта (26,6 процент) – яртылаш, 12 волостьта (10,5 процент) өлешчә эш татар телендә башкарыла. Татар халкы өстенлек иткән 7 волостьта (9,2 процент) эш башкару рус телендә бара [Климов, с. 27].

Шул ук вакытта Татарстанның барлык кантон учреждениеләрендә дә эш башкару рус телендә алып барыла. Өстәвенә, 12 кантонның 7 сендә татар халкы 55 тән 75 процентка кадәр, 5 кантонда 32 дән 48 процентка кадәр тәшкил итә [Татарстан..., б. 17]. Бу исә кантоннарның административ үзәкләре башлыча күпчелекне рус халкы тәшкил иткән шәһәрләрдә урнашу белән аңлатыла, шуңа күрә кантон учреждениеләрендә эш башкаруны татар теленә күчерү катлаулана.

1920 елларда да, безнең көннәрдәге кебек үк, Татарстанда рус халкы арасында татар телен өйрәнүгә, дәүләти һәм иҗтимагый учреждениеләрдә эш башкаруны республика халыкларының милли телләрендә оештыруга аерым тартылу булмады. 1923 елгы мәгълүматлар буенча, Казанда учреждениеләрдәге җаваплы рус хезмәткәрләре

арасында аларның нибары 6,2 проценты һәм техник белгечләрнең 2,1 проценты гына татар телен белгән [Габдрафикова]. Әлеге статистик мәгълүматларга караганда, Татарстанда ике дәүләт теле арасында телләрнең тигез хокуклылыгына ирешү сәясәте әлләни уңай нәтиҗәләр бирмәгән: рус телле халык татар телен һәм башка халыкларның телләрен өйрәнүгә, шулай ук аларны эш башкаруда куллануга битарафлык күрсәткән.

Гарәп графикасы нигезендә татар язуын камилләштерү, татар халкының тел мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, дәүләт, иҗтимагый һәм җитештерү учреждениеләре аппаратын тамырландыру буенча милли сәясәт РКП–ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетының көчле контролендә уздырыла. Әлбәттә, моның аерым сәяси нигезе була – өлкә комитетының һәм аның структураларының бөтен тырышлыгы Татарстанда барлык милләтләрне хезмәт ияләрен икътисади һәм этносәяси төзелешнең иң мөһим дәүләт мәсьәләләре тирәсендә интернациональ нигездә берләштерүгә юнәлтелгән иде. Һичшиксез, милли тел мәнфәгатьләрен хәл итү Татарстанда яшәүче халыклар, бигрәк тә татарлар һәм руслар арасындагы мөнәсәбәтләрнең кирәкле формаларын эзләү белән бәйле булды. Әмма әлеге сәясәттә югалтулар үзләрен аермачык сиздерде – революциягә кадәрге төрки-татар этномәдәни мирасы белән татар мәдәнияте һәм теленең совет варианты арасындагы аерма күзгә күренеп зурайды.

**Әдәбият**

*Атласов Һ.* Казан ханлыгы. Казан, 1914.

*Атласов Һ.* Себер тарихы. Казан, 1911.

*Атласов Һ.* Яңа низам вә гыйлемләремез. Оренбург, 1914.

*Баттал Г.* Татар тарихы. Казан, 1912.

*Бигиев М.* Ислахат әсәсләре. Пг., 1916.

*Бигиев М.* Шәригать әсәсләре. Пг., 1917.

*Вәлиди Ә.* Кыскача төрек-татар тарихы. Казан, 1912.

*Вәлиди Җ.* Милләт вә миллият. Оренбург, 1914.

*Вәлиди Җ.* Татар әдәбияты барышы. Оренбург, 1912.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең тулы сүзлеге. Казан, 1927. 352 б.

*Габдрафикова Л.Р.* Татарский язык в 1920-е годы: приобретения и потери [Электрон ресурс]. URL: https://zen.yandex.ru/media/ (файдаланылды: 24.10.2020).

*Габәши Х.* Мохтасар тарих кавеме төрек. Казан, 1899.

*Габәши Х.* Мөфассал тарих кавеме төрек. Казан, 1909.

*Габәши* Х. Төрек ыруглары. Казан, 1897.

Государственная программа «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 годы» [Электрон ресурс]. URL:https://tatmsk.tatarstan.ru/docs.htm?pub_id=1524369 (файдаланылды: 19.10.2020).

За 5 лет. К V годовщине провозглашения Татарской Социалистической Советской Республики. Казань: Изд-во ТЦИК, 1925. 208 с.

*Закиев М.З.* Тюрко-татарское письмо (история, состояние и перспективы). М.: Инсан, 2005. 248 с.

Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» (в ред. Законов РТ от 28.07.2004 № 44-ЗРТ, от 03.12.2009 № 54-ЗРТ, от 03.03.2012 № 16-ЗРТ, от 12.06.2014 № 53-ЗРТ, с изм., внесенными Законом РТ от 27.04.2017 № 27-ЗРТ) [Электрон ресурс]. URL: https://kitaphane.tatarstan.ru/legal_info/zrt/lang.htm (файдаланылды: 18.10.2020).

*Исхакый Г.* Безнең аслымыбыз вә милләт // Таң йолдызы. 1906. 29 май.

*Исхакый Г.* Дәүләт вә халык // Таң йолдызы. 1906. 26 май.

*Исхакый Г.* Татарлар вә инкыйлаб // Таң йолдызы. 1906. 30 июнь.

*Кириллова З.* Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар). Казан: Мастер-Лайн, 2000. 208 б.

*Климов И.М.* Национальные моменты в государственном и партийном строительстве Татарии в восстановительный период: доклад на «Краеведческих чтениях»; Гос. музей Татар. АССР. Казань: [б. и.], 1957. 50 с.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. 415 б.

Об изучении родных языков в школах – поправки в закон об образовании в Российской Федерации [Электрон ресурс]. URL: https: //eduinspector.ru/2018/08/06/ob-izuchenii-rodnyh-yazykov-v-shkolah-popravki-v-zakon-ob-obrazovanii-v-rf/ (файдаланылды: 18.10.2020).

Татарскому прибавят громкость. Государственному языку республики готовят более широкое применение // Коммерсантъ. 2013. 6 нояб. (№ 203).

Татарстан Республикасы дәүләт архивы. Ф. П-15. Тасв. 1. Сакл. бер. 1333.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 3.5.4 чарасы кысаларында нәшер ителә.*

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәге мөдире*

УДК 81’33

***Җ.Ш. Сөләйманов,***
***А.Р. Гатиатуллин,***
***М.М. Әюпов***

# «ТӨРКИ МОРФЕМА» ИНТЕРНЕТ-ПОРТАЛЫ: ЛИНГВИСТИК БАЗАЛАРНЫ ТУТЫРУНЫ АВТОМАТЛАШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ

В статье описывается архитектура и функционал интернет-портала «Тюркская морфема», предствляющего собой совокупность взаимосвязанных лингвистичских баз данных и программный инструментарий, который позволяет автоматизировать заполнение и модификацию данных, а также производить исследования с учетом особенностей тюркских языков и в соответствии с требованиями к научно-исследовательской деятельности в области компьютерной лингвистики, лингвистической типологии.

Портал создан на базе структурно-параметрической функциональной модели тюркской морфемы и содержит специальные лингвистические базы данных, описывающие языковые единицы тюркских языков на разных лингвистических уровнях: морфологическом, синтаксическом, семантическом.

Базы данных портала также могут быть использованы как в учебном процессе, так и как информационно-справочная система по тюркским языкам.

**Ключевые слова:** структурно-параметрическая модель, татарский язык, интернет-портал.

The article describes the architecture and functionality of the Internet portal “Türkic morpheme”, which is a set of interrelated linguistic databases and software tools that allow automating the filling and modification of data, as well as conducting research taking into account the peculiarities of the Turkic languages and in accordance with the requirements for scientific research activities in the field of computational linguistics, linguistic typology.

The portal was created on the basis of the structural-parametric functional model of the Turkic morpheme and contains special linguistic databases that describe the linguistic units of the Turkic languages at different linguistic levels: morphological, syntactic, semantic.

The portal databases can also be used both in the educational process and as an information and reference system for the Turkic languages.

**Keywords:** structural-parametric model, Tatar language, Internet portal.

Бүгенге вазгыятьтә телләрнең, рухи байлык чыганагы буларак та, дөньяны тану чарасы буларак та яшәеше аларның санак технологияләрендә кулланылышына нык бәйле. Күпсанлы фәнни чыганаклардан, Интернет битләреннән күренгәнчә, соңгы елларда төрки телләрне информацион технологияләрдә куллану, санак технологияләре ярдәмендә текстлар эшкәртү, фәнни эзләнүләр башкару өчен, санак белгечләре һәм лингвистлар тарафыннан күп практик эшләр эшләнелгән [Oflazer, 1994, Sharipbay, 2014, Orhun, 2010, Altenbek,

2006, Тукеев, 2014, Желтов, 2002, Орехов, 2010, Дыбо, 2014]. Бу бик уңай күренеш. Әмма шул ук вакытта, төрки телләрнең лексика, морфо-синтаксик төзелеш ягыннан да якын булуларына карамастан, нигездә, һәр төрки телне Интернетка кертү, текстларны санак ярдәмендә эшкәртү өчен, аерым технологияләр, хәтта тасвирлау өчен төрле стандартлар кулланыла. Нәтиҗәдә, төрки телләрне эшкәртүче программалар, лингвистик модельләр һәм ресурслар бер-берсен кабатлый. Шунлыктан, әлеге проблемалардан арыну, төрки телләрне санак ярдәмендә эшкәртү технологияләре төзү өчен, уртак проектлар булдырып, белгечләрнең бу проектларны берләшеп, эшләнелгән программаларны барлык төрки телләр өчен дә кулланырлык итеп башкаруы, шулай ук үзләре генә эшләгән аерым программ модульләр белән алмашып торуы – бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Мондый берләшү матди һәм финанс ресурсларын эффектив кулланырга, белгечләрнең көчен, бер-берсен кабатламыйча, әлегә хәл ителмәгән проблемаларны чишүгә юнәлтергә мөмкинлек бирер иде. Без моны төрки телләрне эшкәртү өчен яңа технологияләр тудыру һәм төрки телләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләренә нигезләнеп эшләүче яңа технологияләр төзүдә яңа мөмкинлек дип күрәбез. Әлеге мәкаләдә шундый технологияләрнең инде кулланышка кереп барган бер үрнәге – «Төрки морфема» интернет-платформасы һәм аның бер бик мөһим практик инструменты булган лингвистик мәгълүмат базаларын тутыру чаралары тасвирлана.

## «Төрки морфема» интернет-порталы

Алда атап үтелгән проблемаларны чишү өчен, әлбәттә, берьяктан, уртак концептуаль һәм формаль лингвистик модельләр, төрки телләр өчен уртак мәгълүмат базалары, һәм әлеге модельләр нигезендә төзелгән программалар эшләү кирәк булса, икенче яктан, әлеге программаларны, ресурсларны төрле илләрдәге белгечләр, телчеләр, фәнни оешмалар, хәтта аерым кешеләр уртак куллана алырлык, шул программалар урнаштырылган, аларны куллану өчен җайлы ачык интернет-ресурслар булуы кирәк.

Алга таба тасвирланган «Төрки морфема» порталы шундый ачык инструменталь-лингвистик ресурс буларак төзелә башлады. Әлеге интернет-порталны эшләү максатыннан чыгып, иң элек, кулланышта булган программаларның лингвистика өлкәсендә эзләнүләр башкару һәм эшләнмәләр төзү мөмкинлекләре анализланды һәм шуның нигезендә кулланучыларның лингвистик базалар белән эшен автоматлаштыру, ресурларны куллануны уңайлы итү, гадиләштерү, шул ук ресурслардан күбрәк һәм тулырак мәгълүмат алу өчен, программ коралларга карата таләпләр ачыкланды.

Алар түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Интернет платформа үзе дә, андагы ресурслар да, инструменталь программалар да ачык система таләпләренә туры китерелеп эшләнергә тиеш. Мондый программаларны төзегәндә, алар-

га фундаменталь үзгәрешләр кертмичә, аларның функциональ мөмкинлекләрен арттыру күз алдында тотыла Ягъни, фәнни-практик эзләнүләрдә кулланыла торган программаларны эшләү барышында үзгәртү, киңәйтү һәм көйләү мөмкинлеге булу мөһим. Чөнки, фәнни-практик эзләнүләр – ул күпкырлы эшчәнлек һәм үз эченә төрле мәсьәләләр чишүне туплый, һәм еш кына ул мәсьәләләрнең күбесен алдан ук формальләштереп, тулаем автоматлаштырып булмый.

2. Бу платформага кергән программаларда төрки телләр өчен санак модельләрен, ресурслар һәм яңа программалар төзүчеләрнең эшен берләштерү, күмәк эшләтү мөмкинлеге булырга тиеш. Эзләнүләрдә кеше факторы зур роль уйный, шуңа күрә ресурсларны һәм модельләрне күмәк, төркемнәргә берләшеп, я берәүләрнең эш нәтиҗәсен икенчеләр кулланып эшләү кулай күреләә. Бу очракта аерым уңышлы эшләнмәләрне һәм нәтиҗәләрне барлык эзләнүчеләр дә куллана алачак.

3. Платформадагы программаларның төрле төрки телләр белән эшләвен исәпкә алганда, бер телгә генә җайланган булмыйча, аларда аерым телгә көйләү мөмкинлеге булырга тиеш.

Беренче рәсемдә «Төрки морфема» порталының тасвирламасы күрсәтелгән (1 нче рәс.). Әлеге интернет-ресурс http://modmorph.turklang.net/ адресы буенча урнашкан.




1 нче рәсем. «Төрки морфема» Интернет-порталы

Әлеге порталның максатлары һәм функциональ мөмкинлекләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Портал төрки телләр арасында иркен, җайлы һәм тиз итеп мәгълүмат алмашу мөмкинлеге тудыра, һәм төрки телләр белән эшләүче белгечләрнең аралашу урыны булып тора.

2. Порталда төрки телләрдәге текстларны эшкәртүче программалар туплана, шул программалардан төрле функциональ юнәлештә эшли торган җыелма технологияләр, конвейерлар (pipeline) тудыру мөмкинлеген бирә.

3. Портал үзендә төрки телләрнең үзара тыгыз бәйләнгән күптелле онтологияләрен туплый.

4. Портал төрки телләрне заманча санак технологияләрен кулланып чагыштырып фәнни өйрәнү һәм үстерү җирлеге, шулай ук төрки телләрне укыту системалары өчен ярдәмчел материал да булып тора.

5. Телләрне порталдагы лингвистик базаларны, инструменталь чараларны кулланып эшкәртү программалары төзү мөмкинлеген бирә. Әлеге ресурсларга нигезләнеп, төрки телләр арасында тәрҗемәче программалар төзелә. Бу тәрҗемәче программаларның иң мөһим үзенчәлеге – аларның телләрне үз лексик-грамматик кагыйдәләренә нигезләнеп эшкәртүендә. Кагыйдәләргә нигезләнеп төзелгән программалар, бер яктан, телләрне фәнни өйрәнү, үстерү, башка телләр белән чагыштыру, укыту системаларында куллануда отышлы булса, икенче яктан, бүгенге көндә киң кулланылышка кергән нейро-челтәр технологияләре куллану отышсызрак булган очракта, аеруча аз ресурслы, параллель электрон текстлары булмаган телләр өчен алыштыргысыз инструменталь корал булып тора.

6. Портал телләрдәге лексик-грамматик берәмлекләрне чагыштыру, тегларны унификацияләү мөмкинлеген бирә. Төрки телләрдәге текстлар, тел берәмлекләре белән төрле чагыштырма анализлар үткәреп, телләрнең никадәр якын булуын ачыклап була.

Порталның нигезендә төрки телләр белән эшли торган лингвистик модельләр һәм технологияләр ята [Сулейманов, 2003]. Шундый модельләрнең берсе – ул татар аффиксаль морфемаларының структур-параметраль моделе (2 нче рәс.). Структур-параметраль модельдә төрки телләр системасының төрле дәрәҗәдәге тел берәмлекләре күрсәтелә: фонемалар, морфемалар, синтаксемалар һ.б. Төрле кагыйдәләр ярдәмендә ул тел берәмлекләре арасындагы үзара бәйләнешләр һәм мәгънә берәмлекләренә (концептларга) карата булган бәйләнешләр күрсәтелә.

Беренче чиратта, бу модельдә төрки телләрдәге морфемаларның (тамыр, аффиксаль морфемаларның) структур һәм функциональ сыйфатлары турында тулы мәгълүмат [Сулейманов, 2016] тупланыла. Соңрак, бу мәгълүматка нигезләнеп, башка катлаулырак программалар төзеләчәк. Әйтик, мондый программалар арасында төрки телләргә кагылышлы сорау-җавап системалары булырга мөмкин.

Порталда кулланылган модельнең төп үзенчәлеге – ул, бер яктан, төрки морфемаларының энциклопедик тулы мәгълүмат базасы булса, икенче яктан, шуның үрнәгендә, төрки галимнәрнең үзләре катнашында тутырылган, эшкәртелгән, барлык төрки телләр тупланмасы булыр дип күзаллана.




2 нче рәсем. Структур-параметраль модель

Югарыда әйтелгәнчә, модельдә төрле тел берәмлекләре үзара гына түгел, ә барлык төрки телләр өчен дә уртак булган семантик берәмлекләргә бәйле. Андый семантик берәмлекләрнең бер төре концептлар дип атала. Концептлар арасында шулай ук төрле семантик мөнәсәбәтләр бар һәм алар бергә онтологияләр булып оешалар. Мондый онтологиянең бер фрагменты 3 нче рәсемдә бирелгән. Бу рәсемдә bird’птицы’ исемле концептның башка концептлар белән гипонимия, гиперонимия мөнәсәбәтләре күрсәтелгән һәм төрки телләрдәге нинди морфемалар белән бәйләнештә булуы чагылдырылган.

Мондый күптелле зур мәгълүмат базалары (МБ) төзүнең мөһим өлеше – ул мәгълүмат базаларын тутыру, чөнки, куллану өчен әзер чыганаклар юк һәм кирәкле мәгълүматларны җыю күп вакытны ала.

Күптелле зур мәгълүмат базаларын тутыруны автоматлаштыру

Төрки морфема порталын гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмат җыюның төрле ысуллары кулланыла. Аларның берсе – ике телле сүзлекләрне автомат рәвештә эшкәртү.

Төрки морфема порталыннан алга таба эшләү өчен 7 төрки тел сайлап алынды: татар, кыргыз, үзбәк, кырымтатар, казакъ, чуваш, башкорт телләре. Ул телләрнең мәгълүмат базасын автомат рәвештә тутыру өчен күп лингвистик чыганаклар таләп ителә. Шундый чыганак-материалларны эзләү-күзәтүләр, төрки телләр өчен ике телле сүзлекләрнең интернет-ресурсларда, төрле рәсми чыганакларда




3 нче рәсем. Концептка бәйле төрле телләрдәге атамалар мисалы

бөтенләй булмавын күрсәтте. Шуңа да, төрле төрки телләрдәге мәгълүматны үзара бәйләү өчен, бер арадаш телне кулланырга дигән фикергә тукталдык. Бу очракта, арадашчы тел булып рус теле сайланды, чөнки бер теле рус теле булган ике телле рус-төрки телле сүзлекләр киң таралган.

Төрки телләр мәгълүмат базасы өчен мәгълүмат җыю түбәндәгегә кайтып кала:

– сүзлекләрне программа ярдәмендә эшкәртеп, рус телендәге сүзләрнең төрле төрки телләргә тәрҗемәләрен табабыз;

– бу тәрҗемәләрне автомат рәвештә үзара бәйләргә тырышабыз;

– бәхәсле урыннарны кулдан эшкәртәбез.

Бу функцияләрне автоматлаштыру өчен, махсус инструменталь программалар төзелде һәм шулар ярдәмендә Порталның лингвистик базасы тулыландырылды һәм яңа базалар төзелде.

Төрки морфема порталын гамәлгә ашыру барышында, андагы гамәли программалар кулланылып, алдагы елларда берничә төрки тел кергән эксперименталь сүзлек (4 нче рәс.) төзелгән иде.

Әлеге сүзлекнең күләмен арттыру өчен, ике телле сүзлекләрнең табылган электрон нөсхәләре автомат рәвештә эшкәртелде һәм рус теле аша үзара бәйләнде. Ике телле сүзлекләрнең бу электрон нөсхәләренең күләмнәре аз һәм тулы булмауга карамастан,

| Татар | Кыргыз | Үзбәк | Кырым-татар | Рус | Казах | Башкорт |
|---|---|---|---|---|---|---|
| котылгысызлык, өметсезлек, чарасызлык | аргасыздык, үмүтсүздүк | noumidlik, umidsizlik | | неминуемость | шарасыздық | |
| котылгысыз, өметсез, чарасыз | аргасыз, үмүтсүз | chorasiz | умютсиз, чаресиз, | безвыходный | үмітсіз | сараһыҙ |
| күзсез, сукыр | кашак, көр | ko'r, ojiz | кёр, сокъур | слепой | соқыр | һуҡыр |
| базнатсыз, базымсыз, буйсынучан, | жалкоотай, жалтак, | | абдыравукъ, тартынчакъ, | трусливый | үркек | йөрәкһеҙ |
| абайламаучан, аңгы-миңге, аңкы-миңке, | аланҕазар, аңгүдүк, аңсыз, | aqlsiz, boshsiz, devona, fahmsiz, miyyasiz, ongsiz, telba, | акъылсыз, къабакъбаш, | глупый | пайымсыз | аҡылһыҙ, алйот, иҫәр, йүләр, тиле |
| тавышсыз | дыбышсыз | | давушсыз | безголосый | дауыссыз | |

4 нче рәсем. Эксперименталь сүзлекнең бер өлеше

эксперименталь сүзлекнең зурлыгын беркадәр арттыруга ирешелде. Нәтиҗәдә төрки телләр сүзлегенең яңартылган нөсхәсе түбәндәге сыйфатламага ия булды:

татар теле – 33066 сүз;
казакъ теле – 18757 сүз;
башкорт теле – 2977 сүз;
кырымтатар теле – 7065 сүз;
кыргыз теле – 9686 сүз;
үзбәк теле – 5433 сүз.

Иң тулы ике телле сүзлекләр, нигездә, узган гасырда төзелгәннәр һәм нәшер ителгәннәр. Бу сүзлекләрнең электрон нөсхәсе юк, ә инде булган очракта да, алар тулы түгел һәм аз санлы сүзләрдән тора. Шуңа күрә, төрки телләр сүзлегенең күләмен арттыру өчен, ике телле сүзлекләрнең кәгазь нөсхәләре белән эшләү зарурлыгы туа. Әлеге гамәлнең адымнарын карап үтик. Беренче адымда кирәкле сүзлекнең сканлаштырылган нөсхәсен табарга яки, әгәр яхшы сыйфатлы нөсхәсе булмаса, сүзлекне сканлаштырырга кирәк була. Икенче адымда ике телле сүзлек махсус танып белү программасы ярдәмендә танылa (5 нче рәс.).

ВЕТВ||Ь ж. 1. (дерева) бұтақ; ~и сосныкарағайдың бұтақтары; 2. перен. (отрасль) тарау,сала, тарам,тармақ; ~ь науки ғылымның тараулары; 3. перен. (линия родства) үрім-бұтақ, тармақ; кипчакская ~ь тюркского языкатүркі тілінің қыпшақ тармағы.

5 нче рәсем. Сүзлек мәкаләсе үрнәге

Өченче адымда, программа ярдәмендә эшкәртелеп, алга таба кирәк булмаган мәгълүмат (мәсәлән, тәрҗемә мисаллары) алып ташлана. Ягъни, өченче адымнан соң сүзлекнең уң өлешендә тәрҗемә сүзләр генә кала, шул ук вакытта төрле мәгънәләр турында мәгълүмат та саклана (6 нчы рәс.).

ВЕТВ||Ь ж. 1. бұтақ; 2. тарау, сала, тарам, тармақ; 3. үрім-бұтақ, тармақ.

6 нчы рәсем. Программа ярдәмендә эшкәртелгән сүзлек мәкаләсе

Һәм, ниһаять, соңгы адымда сүзлек мәгълүмат базасына йөкләү өчен әзерләнә:

– мәгълүмат таблица рәвешенә китерелә;

– төрле мәгънәләр турында мәгълүмат саннар рәвешендә аерым баганага чыгарыла;

– синоним тәрҗемәләр таблицада төрле юлларга бүленә һәм нәтиҗәдә һәр юлда бер сүз – бер тәрҗемә кала (7 нче рәс.).

| | | |
|---|---|---|
| ВЕТВЬ | бұтақ | 1 |
| ВЕТВЬ | тарау | 2 |
| ВЕТВЬ | сала | 2 |
| ВЕТВЬ | тарам | 2 |
| ВЕТВЬ | тармақ | 2 |
| ВЕТВЬ | үрім-бұтақ | 3 |
| ВЕТВЬ | тармақ | 3 |

7 нче рәсем. МБга йөкләү өчен мәгълүмат

Мисал өчен казакъ телен алыйк. Беренче эксперименталь сүзлектә казакъ теле өчен 18757 тутырылган юл бар. Рус-казакъ сүзлегенең pdf файлында булган нөсхәсе 56000 чамасы сүзлек мәкаләсен үз эченә алган. МБга йөкләү өчен әзерләнгән текстлар якынча 117000 юлдан тора.

Ике телле сүзлекләрне эшкәртүнең алда карап киткән адымнарын башкарганда бик күп кыенлыклар туа. Аларның кайберләрен карап үтик. Ике телле сүзлекнең сканлаштырылган нөсхәсен махсус танып белү программасы ярдәмендә танып белгәндә, ышанычлы танып беленмәгән яки танып белү программасы сүзлегендә булмаган сүзләр очраса, орфографик хаталар барлыкка килә. Бу хаталарны автомат рәвештә төзәтеп булмый, аларны кулдан караганда гына ачыкларга һәм төзәтергә мөмкин.

Буш аралар булмау – танып беленгән текстларда киң таралган очрак (8 нче рәсем). Мәсәлән, китерелгән мисалда сүзлекнең сул өлешендәге сүз (сүзлек мәкаләсе башлана торган баш сүз) белән уң өлешендәге (анда баш сүз аңлатыла) беренче сүз арасында буш ара юк.

СИ`ЛОЙнареч. күшпен,күштеп,күш жұмсап; ~ заставить что-либо сделатьбір нәрсені күштеп істету.

СИЛО`Км. тұзақ; тут же сам голубь запутался в силках осы арада көгершініңөзі келіп тұзаққа шырмалды.

СИЛО`Нм. силон (жасанды мата талшығы,мата).

СИЛОМЕ`Рм. күш өлшеуіш(аспап).

СИ`ЛОСм. с.-х. сүрленген шөп,сүрлем.

8 нче рәсем. Буш аралар булмауга мисал

Сүзлекләрне эшкәрткәндә, юл күчерү билгесе, гадәттә, яңа мәкалә башланганны аңлата. Шулай ук юл күчерү билгеләренең артык булганнары да очрый (9 нчы рәс.). Шуңа күрә юл күчерү билгеләренә аерым игътибар итәргә кирәк.

ВЗЯТЬсов. 1. кого-чтоалу; ~деньгиақшаалу; ~ палку таяқ алу; 2. кого-что(нанять) жалдау,алу; ~ такси такси жалдау; ~лошадь на время для езды майын міну; 3. что (купить) алу,сатып алу; ~билетбилет алу; 4. кого,что(арестовать) тұтқынға алу,тұтқындау; ~преступника қылмыскерді тұтқынға алу; ~ в плен тұтқынға алу; 5. айырысу; ~расчетесеп айырысу; ¶
6. (с союзами да,ни,да и)ұстау; ни дать ни взять разг. аумаған өзі, дәл өзі, құдды өзі; он взял да и сделал разг. ол алды да, істеп те шықты; ~верх надкем-л.жеңу; ~в рот водуұрттау; ~даромбосқа алу,тегін алу; ~себя в руки өзін қолға алу; сабыр ету; ~за горложан алқымға алу; ~примерс кого-л.біреуден тәлім алу,үлгі алу; ~под свое крыло өз қанатының астына алу,өз қамқорлығына алу; с чего ты взял? сен мұны қайдан алдың? ~чью-л. сторонубүйрегі бұру; ~ в оборотақымға алу.¶
ВЗЯ||ТЬСЯсов. 1. за кого-что(хвататься) қарману,қол ұстасу,қолдасу,қолтықтасу; 2. за что (приняться) кірісу; ~ться за работужұмысқа кірісу; 3. (обязаться) міндеттену,міндетіне алу; ~ться написать статьюмақала жазуды міндетіне алу; 4. (появиться) пайда болу; откуда ты ~лся? сен қайдан пайда болдың?; ~ться за ум сабасына түсу,ақылға келу; откуда ни возьмись қайдан шыққаны белгісіз; аяқ астынан,күтпеген жерден.-¶

9 нчы рәсем. Юл күчерү билгесе артык куелуга мисал

Сүзлекләрдә еш кына аңлатма-сылтамалар очрый. Мәсәлән, «аттестация» сүзенең беренче мәгънәсендә (10 нчы рәс.) «аттестовать» сүзенә мөрәҗәгать итәргә кирәк, анда әлеге мәгънәгә аңлатма биреләчәк. Әгәр аңлатма кабатланса, ягъни сылтама кулланылмаса, яхшырак булыр иде, ләкин басма сүзлекләрдә сылтамалар хисабына кәгазь әзрәк китә. Шуңа күрә аңлатма-сылтамалар өстәмә эшкәртү таләп итә.

АТТЕСТА`ЦИ||яж. 1. см. аттестовать; 2. (характеристика) сипаттама,мінездеме; дать ~ютексеру,сынау.

АТТЕСТОВА`ТЬсов., несов. 1. кого-что; 2. кого аттестаттау, біліміне,мамандығына баға беру,баға қою,бағалау; ~ученика по всем предметамоқушыны барлық пән бойынша бағалау.

10 нчы рәсем. Аңлатма-сылтама мисалы

Ике телле сүзлекләрне программа ярдәмендә эшкәртү төрки морфема порталы мәгълүмат базасын тулыландыру вакытын шактый киметергә мөмкинлек бирә.

Бүгенге көндә порталны ясау процессы дәвам итә. Аңа төрле модульләр һәм функцияләр өстәлә бара. Төрки тел белгечләре, портал тулысынча төзелеп беткәнне көтмичә үк, портал белән эшлиләр, аның мәгълүмат базасын тутыралар. Ә бу исә, үз чиратында, программа өлешен төзегәндә белгечләрнең фикерләрен, тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләргә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Kemal Oflazer.* Two-level Description of Turkish Morphology // Literary and Linguistic Computing. Vol. 9. No 2. 1994.

*Sharipbay A.A., Bekmanova G., Yergesh B., Mukanova A.* Synchronized liner tree for morphological analysis and generation of the Kazakh language // Proceedings of the international conference «Turkic languages processing», TurkLang 2014. Istanbul. P. 113–117.

*Orhun, M., Tantug A.C., Adali E.* Morphological Disambiguation Rules For Uyghur Language // IEEE International Conference on Software Engineering and Service Sciences (ICSESS), Beijing, China, 2010. P. 542–547.

*Gulila Altenbek*. Automatic Morphological Tagging of Contemporary Uighur Corpus // The IEEE International Conference on Information Reuse and Integration, 2006. P. 557–560.

*Тукеев УА., Шормакова А.Н., Айткулова А., Сундетова А.* Разработка англо-казахского переводчика на базе Open-Source платформы Apertium. // Сулеймен Демирел атындагы университет хабаршысы. 2014. Т. 28, С. 99–111.

*Желтов П.В.* Морфологический анализатор чувашского языка // Материалы Международной конференции студентов и аспирантов по фундаментальным наукам «Ломоносов 2002». М., 2002.

*Орехов Б.В., Слободян Е.А.* Проблемы автоматической морфологии агглютинативных языков и парсер башкирского языка // Информационные технологии и письменное наследие: материалы международной научной конференции (Уфа, 28–31 октября 2010 г.) / отв. ред. В.А. Баранов. Уфа; Ижевск: Вагант, 2010. С. 167–171.

*Дыбо А.В., Шеймович А.В.* Автоматический морфологический анализ для корпусов тюркских языков // Филология и культура. 2014. №2.

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р.* Структурно-функциональная компьютерная модель татарских морфем. Казань: Фэн, 2003. 220 с.

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р., Альменова А.Б., Баширов А.М.* Многофункциональная модель тюркской морфемы: отдельные аспекты // В сборнике: TEL – 2016. Труды международной конференции по компьютерной и когнитивной лингвистике. Сер. «Интеллект. Язык. Компьютер». 2016. С. 168–171.

***Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы,***
*техник фәннәр докторы, ТР ФА Гамәли семиотика институты баш фәнни хезмәткәре*

***Гатиатуллин Айрат Рафиз улы,***
*техник фәннәр кандидаты, ТФА Гамәли семиотика институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Әюпов Мәдехур Мәсхут улы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика институты фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***М.З. Вәлиева***

# XVII–XVIII ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ‘ҮЛЕМ’ ТӨШЕНЧӘСЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

В данной статье на материале, извлеченном из старотатарских письменных источников XVII–XVIII вв., раскрывается содержание понятия ‘смерть’. В ходе исследования было установлено, что понятие ‘смерть’ в рассмотренных нами текстах выражается множеством слов и словосочетаний. Они, с одной стороны, являются синонимами между собой, с другой, каждый из них имеет свои уникальные коннотативные значения, которые в определенных контекстах обогощаются дополнительными эмоционально-экспрессивными оттенками.

**Ключевые слова:** старотатарские письменные источники, лексика, синонимы, лексико-семантические варианты.

In this article, on the basis of material extracted from the Old Tatar written sources of the 17th–18th centuries, the content of the concept ‘death’ is revealed. In the course of the study, it was found that the concept of ‘death’ in the texts we examined is expressed by many words and phrases. On the one hand, they are synonyms with each other, on the other, each of them has its own unique connotative meanings, which in certain contexts are enriched with additional emotional and expressive shades.

**Key words:** Old Tatar written sources, vocabulary, synonyms, lexical and semantic variants.

Ислам тәгълиматы, дини мифология нигезендә кеше яшәеше ике өлешкә бүлеп карала: бу дөнья һәм теге дөнья. Бу дөнья дигәндә, фани дөнья күздә тотыла. Коръән аятьләреннән күренгәнчә, кеше югары әхлак таләпләрен үтәп, дөньяви һәм дини кануннарны саклап яшәргә тиеш. Төрки-татар халкының бар яшәеше гасырлар дәвамында шушы ‘ике дөнья’ фәлсәфәсенә нигезләнгән булган һәм бу иске татар язма истәлекләрендә дә ачык чагылыш таба. Кешенең язмышы, бүгенгесе һәм киләчәге – барысы да Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә бәйләнгән. Гыйбадәт кылу, гөнаһ кылмау, булган гөнаһлардан арыну, ислам таләпләрен саклап, изге уй-ният белән көн итү һ.б. – барысы да фани дөнья гамәлләре. Адәм баласының фани дөньяда кылган һәр гамәле ахирәткә әзерлек буларак күзаллана. Ахирәт исә, бу дөньядан аермалы буларак, мәңгелек дип карала. Оҗмах, тәмуг, сират күпере, кыямәт көне һ.б. – ахирәт белән бәйле категорияләр. XVII–XVIII гасыр иске татар язма чыганакларында ‘ике дөнья’ фәлсәфәсенә бәйле бу категорияләрнең барысы да үзенчәлекле рәвештә чагылыш таба. Биредә җир йөзе, кешелек һәм барлык тереклек дөньясы, җир шары, бөтен галәм, кешенең бу дөньяга килүе, яшәеше, гомер итүе, бу дөньядан китүе һ.б. күздә тотыла. Бу төшенчәләр каралган текстларда күп төрле сүз, сүзформа һәм сүзтезмәләр ярдәмендә җиткерелә [Валиева, 2017,

с. 37–43]. Әлеге язмада без кешенең фани дөньядан китүе белән бәйле ‘үлем’ төшенчәсенә тукталырбыз. Үлем кеше тормышында иң зур һәм тирән фаҗига дип кабул ителә. Бу фәлсәфи категориягә халык авыз иҗатында да, язма әдәбиятта да зур урын бирелә. XVII–XVIII гасыр иске татар язма чыганакларында да үлем темасы һәрчак үзәктә тора.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *үлем* сүзенең түбәндәге мәгънәләре күрсәтелә: 1. Организмның эшчәнлеге тукталу һәм аның һәлак булуы; организмда яки аның бер өлешендә матдәләрнең биологик алмашынуы тукталу хәле; 2. Кеше яки хайванның яшәүдән тукталу хәле; 3. Начар нәрсә, кайгы-бәла [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1981, б. 728].

Бу төшенчә язма истәлекләрдә түбәндәге сүз һәм сүзтезмәләр белән җиткерелә: *үлем* (اولم)*, нагяһ үлем, үлем котылгысыз; ахирәткә күчү* ( آحرتكه كوچو)*; гүргә бару* (گورگه بارو)*; дөньядан үтү* (دونيادان اوتو)*, фани дөньядан үтү, дөньядин нәкыль кылу, дөньядин вафат итү, дөньяны уздыру; әҗәл* (اجل)*, әҗәл йитү, әҗәл ирешү; җан бирү* (جان بيرو)*, җан алу, җан тәслим кылу; үлү, үлмәк, үлә калды, үләр булу, үлтерү; вафат* (وفات)*, вафат улу, вафат итү; рихләт итү* (رحلت ايتو)*, даре бәкайә рихләт итү; һәлак булу* (هلك بولو)*; шәһид итү* (شهيد ايتو)*, шәһид китү; катил әйләү* (قاتل ايلو); *гәрд-гәрд кылу* (گەرد-گەرد قلو)*; баш кисү* (باش كيسو) һ.б.

‘Үлем’ төшенчәсе без караган текстларда, беренче чиратта, үзара синонимик мөнәсәбәттә торган *үлем* (اولم), *әҗәл* (اجل) лексик берәмлекләре белән бирелә: *Ғарипләргә үлем килсә, моңлуғ башы* [Мәүлә Колый, 1963, б. 495]; *Шул әҗәлдән Аллаһы Тәғалә Қоръәндә «Лоқман» сүрәсендә хәбәр бирде* [Мөслими, 1999, б. 18].

*Нагяһ үлем* (اولم ناگه) сүзтезмәсе ярдәмендә вакытсыз үлем, ягъни үлемнең котылгысыз булуы хакында хәбәр ителә: *Нагяһ үлем килер башқа беркөн байық* [Мәүлә Колый, 1963, б. 494].

*Әҗәл-үлем* (اجل-اولم) парлы сүзе үлем фаҗигасын эмоциональ-экспрессив яктан тагын да көчәйтеп, тагын да тулырак җиткерә: *Ул Торғайның хатыны йөкле торыр: аның қорсағындағы баласындан әҗәлең-үлемең йитебдер* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81].

Исламда кешеләр үлемне Аллаһы Тәгаләнең әмере, ягъни тәкъдир итеп кабул итәргә тиешләр. Беренче карашка, үлем – табигый күренеш, ахирәткә күчү, әмма барыбер котылгысыз фаҗига итеп карала, аңардан качып булмый, ул адәм баласын үзе үзләп таба. *Үлем қотылғысыз* (اولم قوتلعسز)*, әҗәл йитү* (اجل يتو)*, әҗәл ирешү* (اجل ايرشو) кебек сүзтезмәләр шул төшенчәләрне ирештерә дә. Аннары шунысы игътибарга лаек, *әҗәл* сүзе бары тик кешеләргә карата гына кулланыла: *Аһ, әй, қалтақ халық уғлы, белеңләр, үлемдин һич қотылғымыз йуқ ирмеш* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71]; *Әҗәл йитеб килсә, дару-дәрман булмас ирмеш* [шунда ук, б. 71]; *Имде әҗәл ирешде, бән үләрем, сез қаласызлар* [шунда ук, б. 71]. *Баш ағырса, әҗәл йетәр* [Мәүлә Колый, 1963, б. 495]. *Әҗәл килеб, үлеп гүргә барыр булсаң* шунда ук, б. 494].

Без караган текстларда ‘үлем’ төшенчәсе еш кына мәңгелек коннотациясе белән баетыла. Нәтиҗәдә ул күпмедер дәрәҗәдә тынычсабыр кабул ителә, чөнки аның килү-килмәве Аллаһ кодрәтенә бәйле: *Бишенче бармагы ишарәтдер бәни Адәм ќайу йирдә үләчәгене wә ќачан үләчәгене белмәсләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә белер, димәкдер* [Мөслими, 1999, б. 18].

Үлем – адәм баласы өчен котылу, дөньяви авырлыклардан качу чарасы да. Ул үлемне кайчак сорап ала: *Бәс Габдеррахман әйтде, бәнем җанымны ќачан алырсын, та ки бән үлем истигдадында үләйем, диде* [Мөслими, 1999, б. 16].

Әҗәл-үлем җитүнең Аллаһ кодрәтендә булуы *җан алу* (جان آلو), *җан биру* (جان بيرو) сүзтезмәләрендә аеруча ачык чагылыш таба: *Газраил галәйһиссәлам әйде: «Мән сәнең кебе ќол мән, илля Мәләкел-мәут див бәне әйтерләр, йәгни барча мәхлуќатлар җаныны wә һәм атаң-анаң җаныны бән алдым, див әйтде* [Мөслими, 1999, б. 16]; *Бичара вәзир җан ќурќынычындан бер лоќма агзыйга салды, дәрхаль йыгылыб җан бирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 510].

‘Үлү, үз үлеме белән үлү’ мәгънәсе XVII–XVIII гасыр иске татар язма истәлекләрендә *үлү* фигыле белән белдерелә: *Бер үлмәке мең үлмәкдин йаман иркән* [Мәүлә Колый, 1963, б. 495]; *Син күрсәң үләрсең, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69]; *Йәнә бер анча көнләрдин соң Тумаwыл Мәргәннең атасы Турымтай Чәчән үлде* [шунда ук, б. 71].

Шуның белән бергә ул тезмә фигыльләр составында еш очрый: *Ариг йуыб, гүргә ќуйар үләр булсаң* [Мәүлә Колый, 1963, б. 493]; *Андин соң ул хатынны йыгыб, андаг тезләде кем, эссүсе китде, үлә ќалды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82]; *Көн йаругы сарайга керде, Гыйләмалик Күрекле аны күрде, үлә ќалды* [шунда ук, б. 69].

Сөйләмдә ‘үлү’, ‘үлем’ төшенчәләре күп төрле эмоциональ-экспрессив төсмерләр белән баетыла. Югарыда искәртелгәнчә, ислам дине буенча дөньядагы һәрбер кешенең гомере, ул килгәнче үк Аллаһ тарафыннан билгеләп куелган. Кешеләр бу тормышта ничек кенә яшәсәләр дә үлемнән берничек тә котылып кала алмыйлар, чөнки ул – Аллаһ тарафыннан билгеләнгән тәкъдир. ‘Үлем’ төшенчәсенең бу үзенчәлеге, ягъни башка бер дөньяга күчү, кешеләр тарафыннан тынычрак кабул ителә. Әлеге семантик вариант аеруча Мәүлә Колый әсәрләрендә киң урын ала. Ул, суфи шагыйрь буларак, яшәешне ике дөньяга – фани һәм бакыйга бүлеп карый. Аның өчен үлем ахирәткә күчү, гүр өенә бару. Бу очракта ‘үлем’ төшенчәсе *гүр өе, гүр өенә бару, гүргә бару, ахирәткә күчү* кебек сүзтезмәләр белән белдерелә: *Хаќ төзесен гүр өйендә сәнең эшең* [Мәүлә Колый, 1963, б. 494]. *Әҗәл килеб, үлеп гүргә барыр булсаң* [[шунда ук, б. 494]; *Ахирәткә күчәрләр гөнаһ атына атланыб* [шунда ук, б. 488]

Үлемне табигый һәм котылгысыз күренеш итеп кабул итү иске татар язма истәлекләрендә *үлем* сүзенең семантик варианты булган *wафат* (وفات) лексемасы белән белдерелә. Дөрес, чыганакларда бу сүз үзе генә кулланылмый диярлек, ул, нигездә, *wафат улу* (وفات اولو),

*wафат иту* (وفات ايتو) сүзтезмәләре составында кулланыла һәм ‘үз үлеме белән, вакыты җитеп үлү’ мәгънәсенә ия: *Бәлқыйс кәмалға җҫитде, атасының wафаты йақын булды* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 511]; *Йегерме өченче көнендә хәзрәте рәсүлүллаһ ғаләйһиссәламнең wафаты улды* [Мөслими, 1999, б. 11]; *Хәзрәте Әбу Бәкер ул көндә wафат итмешдер* [шунда ук, б. 11].

*Дөнйадин wафат иту, дөнйадин киту, дөнйадин нәқыл қылу* сүзтезмәләре дә кешенең дөньяви яшәешне, ягъни фани дөньяны ташлап китүен эчке бер салмаклык-сабырлык белән хәбәр итә: *...wә һәм ул көн дөнйадан үтде* [Мөслими, 1999, б. 9]; *Бу сүзне халаиққа wасыйәт қылғандин соң Дуйын Бәйан дөнйадин үтде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71]; *Падишаһзадә балин ғамь wә бәстәр ғоссада йатыб, дөнйадин нәқыл қылды* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 512]; *Йәнә йитмеш ике йылдан соңра, туңғыз йылында, мөбарәк Рамазан айының ундүртенче көн, тарих алты йөздә дөнйадан wафат итде, сүзе дөнйада калды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81].

*Фани дөнйадан үту* дигәндә, яшәешне ахирәткә һәм дөньялыкка бүлеп карау, фани дөньяны ташлап, ахирәткә күчү турындагы ышанулар, кешенең ике дөнья хакындагы күзаллаулары тагын да ачыграк күренә: *Хақ Тәғаләнең тәгдире ирешеб, хәзрәте Ақсақ Тимер һәм ошбу фани дөнйадин үтделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 88].

Ислам динендә ахирәт – мәңгелек. Бу күзаллаулар язма истәлектә ‘мәңгелек йортка күчү’не аңлаткан гарәп алынмасы *рихләт иту* (رحلت ايتو) яки *даре бәқайа рихләт әйләү* (دارى ناقيا رحلت ايلهو) сүзтемәләре белән җиткерелә: *Ул мәқаме куйды, рихләт итде, дуслар* [Мәүлә Колый, 1963, б. 490]; *Хәзрәте Мир Тимер даре бәқайа рихләт әйләде* [Мөслими, 1999, б. 47].

Мифологик һәм дини күзаллаулар нигезендә, мәңгелек йортка, ягъни бакыйлыкка кешенең җаны күчә, чөнки җан үлемсез. ‘Үлү’ төшенчәсенә ия *җҫан тәслим иту* (جن تسلم ايتو) фразеологик әйтелмәсендә дә сүз нәкъ шул хакта бара: *Хаҗ юлында җҫан тәслим қылды, дуслар* [Мәүлә Колый, 1963, б. 490]; *...wә йәнә һәр төрле тәғанни илә әлхан идәрләр: ишедән ғашыйқлар рәкыс итеб җҫан тәслим итәр* [Мөслими, 1999, б. 21].

Үлем Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире дип каралса да, ул кешеләрне һәрчак тетрәндерә. Аеруча берәр төрле бәла-каза, фаҗига аркасында булган көтелмәгән, вакытсыз үлемнәр зур тетрәнү, коточкыч зур югалту ачысы белән қабул ителә. ‘Фаҗигале үлем’ төшенчәсе язма истәлекләрдә күпчелек очракта *һәлақ улу* (هلك اولو) сүзтезмәсе белән җиткерелә: *Ғуҗҫ бине Ғанк, wә Фирғаwен, wә Нәмруд, wә Ғад, wә Сәмуд коуме бу көндә һәлақ улмышлардыр* [Мөслими, 1999, б. 9]; *Кәнған туфанда һәлақ улды, нәселе киселде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69].

Әгәр инде кеше изге сугышта, хаклык юлында һәлак булса, *шәһид иту* (شهيد ايتو) тезмә фигыле кулланыла: *wә Җирҗис wә Зәкәрийә, wә Йахйа ғаләйһимус-сәламләр ул көн шәһид итделәр* [Мөслими, 1999, б. 9].

Кешенең үлемендә кемдер сәбәпче булырга да мөмкин, ягъни адәм баласын һәлак итү, үтерү кебек фаҗига һәм җинаятьләр тормышта еш очрый. Кемнедер фаҗигалы үлемгә дучар итү, һәлак итү, үтерү әдәби ядкярләрдә дә тасвирлана. Мондый төшенчәләр, беренче чиратта, *үлтерү* фигыле белән белдерелә: ... *wә Қабил Һабилне үлтерде* [Мөслими, 1999, б. 9].

Гарәп алынмалары белән ясалган *һәлак қылу* (هلك قلو)*, қатил әйләү* (قاتل ايلو) тезмә фигыльләре дә шул максаттан файдаланыла: *Бу көн форсатны ғанимәт тотды, мәни һәлак қылғай* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 505]; *Сафуан галиб улыб аны қатил әйләде wә қаwемене әсир әйләде* [Мөслими, 1999, б. 10]; *Әһле сөннәтнең күб шәһәрләренең алды wә ғоләмадан улғучыларны қатил әйләде* [Мөслими, 1999, б. 35].

*Баш кису* (باش كيسو), ‘тузанга әйләндереп юк итү’ не аңлаткан *гәрд-гәрд қылу* (گەرد-گەرد قلو) тезмә фигыльләре һәлак итү юлларын тагын да төгәлрәк тасвирлый: *Анда Ақсақ Тимер әйде: «Син ғафил дәгелсең, мин ғафил мен, син үзеңә йаманлық қылғайсың, мин үземгә йахшылық қылғаймын», – тиде, башын кисде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 83]; *Падишаһзадә әйтде: тәгамнән тәнаwел қылмасаң, башыңны фил Мәхмүтнең айақыйға салыб, гәрд-гәрд қылырмын* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 510].

Шул рәвешле, XVII–XVIII гасыр язма истәлекләреннән күренгәнчә, үлем һәм аның белән бәйле төшенчәләрне белдерә торган сүз, сүзформалар һәм сүзтезмәләр иске татар телендә шактый киң лексик-семантик кыр барлыкка китерәләр. Бу, үз чиратында, татар халкының ике дөнья (фани һәм бакый) арасында билгеле бер чик ролен үтәгән әлеге категориягә элек-электән зур әһәмият биргәнлеген күрсәтеп тора.

**Әдәбият**


*Валиева М.З.* Особенности синонимической парадигмы тюрко-татарского письменного памятника XVIII века «Маджмугыл-хикаят» // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. Чебоксары, 2017. № 1 (93). С. 37–43.

Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII – XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

Мәүлә Колый поэмалары / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 88 б.

Мәүлә Колый шигырьләре / Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 487–503.

Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

*Мөслими.* Тәварихы Болгария / басмага әзерләүче С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Т. 3. 831 б.



***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 792

*Л.Ш. Гарипова,*
*Ф.Х. Миңнуллина*

# ХАНБИКӘ – СӘХНӘДӘ: БЕРЕНЧЕ ТӘҖРИБӘЛӘР, ЯЛГЫШЛАР, УҢЫШЛАР...

В статье даётся сопоставительный анализ ряда драматургических произведений, посвященных Казанской царице Сююмбике. Особое внимание уделяется рецензиям, относящимся к пьесе М. Заитова «Царица Казанская», воспоминаниям о самом произведении и спектакле, которые хранятся в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Сююмбике рассматривается в статье как личность, не отступившая от своих идеалов, боровшаяся за безопасность государства, и хранительница национальных ценностей своего народа.

**Ключевые слова:** Сююмбике, пьеса, сцена, конфликт, герой.

The article provides a comparative analysis of a number of dramatic works dedicated to the Kazan Queen Syuyumbika. Particular attention is paid to reviews related to M. Zaitov's «The Queen of Kazan» and memories about the work itself and the performance, which are kept in the Center for Written and Musical Heritage of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov og the Academy of Sciences (Republic of Tatarstan). Syuyumbike is considered in the article as a person who did not deviate from her ideals, who fought for the safetyof the state, and the keeper of the national values of her people.

**Keywords:** Syuyumbike, play, scene, conflict, hero.

Казан тарихында милләтебез ханбикәсе Сөембикәнең роле гаҗәеп зур. Аннан соң дәүләтчелеген югалткан татар халкы легендалар һәм бәетләрдә аны сагынып сөйләгән, исемен данлаган. Әдипләребез Сөембикә турында язган романнарында, аның исеме белән бәйләп, татар халкының тарихтагы ролен, урынын, рухи һәм мәдәни дөньясының байлыгын күрсәтергә омтылганнар. Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында XIX–XX гасырлар чигендә яшәгән Р. Фәхретдин, Һ. Атласи, З. Вәлиди кебек тарихчыларыбыз, урыс тарихчысы М. Худяков һәм хәзерге чор татар тарихчылары Ф. Урманче, Р. Фәхретдинов, Р. Әмирханов, шулай ук язучылар М. Хәбибуллин, Р. Батулла, Р. Хәмид һ.б. Сөембикә турында әсәрләр иҗат иттеләр, татар тарихын яктыртуга һәм баетуга зур өлеш керттеләр. XX гасыр башында Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында күпсанлы тарихи хезмәтләр языла. Кыска гына вакыт аралыгында Сөембикә турында фәнни мәкаләләр дөнья күрә, проза һәм сәхнә әсәрләре, шигырьләр иҗат ителә. Бу чорда Сөембикә тарихи шәхес һәм әдәби каһарман булып кына калмыйча, татар халкының милли азатлык идеалларын үзенә туплаган символик образга әйләнә. Билгеле булганча, XX гасыр башында Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе турында берничә сәхнә әсәре дә языла.

Шуларның берсе – Казан ханлыгының соңгы көннәрен тасвирлаган Сөембикә ханбикә турындагы җиде пәрдәлек тарихи пьеса (1910). Пьесаның тексты һәм авторы билгеле түгел. «Вакыт» газетасының 597 нче санында урын алган кыска хәбәрдә, бары тик Казан яшьләреннән булган ике авторның күңел биреп эшләве, мөстәкыйль рәвештә иҗат итүләре турында искәртелә. Сөембикә турындагы безгә хәтта исеме дә мәгълүм булмаган бу пьесаның тарихи дөреслекне ничегрәк чагылдыруын күренекле тарихчы Гайнетдин Әхмәров тә тикшереп чыккан [Рәмиева, 2009, б. 122]. Вакытлы матбугат битләрендә шулай ук Фазыл Туйкинның да «Сөембикә» драмасын язуы хәбәр ителә. Кызганыч ки, югарыда телгә алынган сәхнә әсәре кебек, бу драма да, тексты югалу сәбәпле, бүгенге көн укучысына килеп җитмәгән [Гарипова һ.б. с. 18]. «Сөембикә» драмасының сәхнәгә куелуы хакында 1914 елда «Вакыт» газетасында да бер мәкалә дөнья күрә.

Сөембикәгә багышланган тагын бер әсәр – төрек офицеры Гали Хәйдәр тарафыннан язылган «Шаһгали хан» исемле трагедия. «Сәйяр» труппасы артистлары аны 1918 елның 4 маенда Казанда сәхнәгә куйган. Әсәрдә Шаһгали ролен мәшһүр Габдулла Кариев, Сөембикә ролен Фатыйма Ильская башкара. Спектакльгә Фәтхи Бурнаш (Номерсыз урындык) уңай рецензия язып бастырган [Рәмиева, 2009, б. 122].

Шулай итеп, татар халкының милли хисләре югары ноктага күтәрелгән 1910 елларда ханбикә турында берничә драма әсәре дә языла, сәхнәләштерелә. Бу хакта рецензияләр дә басылып чыга. Кызганычка каршы, аларның текстлары бүгенгәчә табылмаган, шуңа күрә безнең көннәргә килеп җитмәгән бу пьесалар турында тәфсилле, дәлилле фикер йөртеп булмый.

1928 елда Мирза Зәетовның «Ханбикә» исемле тарихи легендасы сәхнәләштерелә. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемдәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас фондында сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллинның зур һәм бай архивы саклана (185 нче фонд). Әлеге фондта Мирза Зәетовның Хәсән Гобәйдуллинга һәм язучы Әмирхан Еникига язган хатлары, театр тарихы хакындагы кызыклы истәлекләре урын алган. Х. Гобәйдуллин театр тарихын язу барышында халык театрлары, төрле спектакльләрнең сәхнәгә менү тарихы, һәм гомумән, аерым мәсьәләләргә ачыклык кертү җәһәтеннән М.Зәетовка мөрәҗәгать итә һәм алар арасында җанлы, эчтәлекле, бер-берсенә хөрмәт белән сугарылган әңгәмә-элемтә урнаша. Истәлекләр арасында «Иске Казан диварлары артында» (соңрак «Ханбикә») пьесасы хакында язылганы аеруча игътибарга лаек. «Ханбикә» – беренче мәртәбә 1928 елда театр техникумының бишьеллык юбилее уңаеннан, техникум тәмамлаучы укучыларның имтихан спектакле буларак куела. Шул ук елда Татар академия театрының 3 нче премьерасы булып сәхнәгә менә. Төп рольләрдә: Ханбикә – Г. Болгарская, Кулач – Г. Уральский, Василий – Камал II һ.б. Баш режиссер – Е. Вахтангов исемендәге студиядә

укыган Гомәр Девишев (1897–1964) була. З. Мәҗитов истәлекләрендә дә әсәр хакында кызыклы гына мәгълүматлар бар. «Театр техникумында бездә музыка мөгаллиме С. Габәши (композитор, музыка белгече Солтан Габәши (1891–1942) иде. «Ханбикә»не сәхнәгә техникум куйганда әсәрдәге шигырь һәм җырларга музыканы ул язды. Композицияләре аның матур, моңлы чыкты. Мелодияләрендә татар аһәңе яңгырый иде. Әсәр татар дәүләт театрында уйналганда, музыканы С. Сәйдәшев (1900–1954) язды. Ул шигырь-җырларны стиль ягыннан төзәттереп, көйләрне озынрак темпка салды». Ул елларда Главлитның башлыгы Хөсни Кәрим (1887–1965), аның урынбасары Ш. Камал (1884–1942) була һәм алар да әсәргә карата үзләренең фикерләрен җиткерәләр: «Язганың яхшы, темасы кызыклы. Һәрхәлдә, «әкият ханнары» хакында түгел, реаль моментлар бар. Китапта ачлар кузгалышы пәрдәсе миңа ошады, куярга рөхсәт» дип имза сала Х. Кәрим. Ш. Камал «Казан кальгасы янында җыйналган ачлар гыйсъяны миңа да ошады. Әсәрне күркәмли торган пәрдә – шул. Анда син дин башлыгы шәехне күрсәтәсең. Минем фикеремчә, синең язуыңда аның роле гади бер ишан-мулладан ашмый. Ә шәех баш рольләрнең берсен уйнаган. Хәтта яңа хан тәгаен кылу аның кулында булган, сарай интригаларына юлбашчылык иткән, шул моментларны да күрсәтү кирәк. Аның ачлар алдында сөйләгән вәгазен яңадан карап чык, аның нотыгы митинглардагы ораторлар сөйләвенә охшамасын, нотык стиле муллалар мәчеттә татарча сөйли торган хөтбәгә охшасын» – ди [Зәетов, 185 нче фонд]. Әсәрнең язылу тарихында автор үзе түбәндәгеләрне әйтә: «Ул заманда репертуар өчен тема эзләнү вакыты иде. Чынында, сәхнәдә уйналган пьесаларның художество ягыннан шактый уңышлы булуларына карамастан, күбесендә татар тормышыннан ерак, гарәп, фарсы, төрек легендаларыннан алынган иде. Менә шул дәвердә азмы, күпме татар тарихын гәүдәләндерергә тырышкан минем «Иске Казан диварлары артында» сәхнәгә килеп менде. Яхшымы, яманмы, әсәр ул заман өчен шактый гына яңалыкка ия иде [Зәетов, 185 нче фонд]. Техникум постановкасы «Большой театр» бинасында май аенда үтә. Билетлар тиз арада сатыла. Спектакльдән соң юбилей мөнәсәбәте белән үткәрелгән банкетта К. Тинчурин да катнаша. Ул халыкның күп булуына шакката: «Премьераларда моның кадәр халыкның булганы юк иде. Беләсегез килсә, бу – реклама көченең нәтиҗәсе», – ди. Безнең гади афишадан башка рекламабыз булмады, – дип җавап бирә М. Зәетов [Зәетов, 185 нче фонд]. «Сезнең пьесагызның исеме, иптәш Зәетов, үзе зур һәм көчле реклама иде», – ди аңа талантлы язучы. С. Борһан мәкаләсендә искәртелгәнчә дә: «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Ханбикә» кебек пьесалардан соң, озак вакытка хәтле тамашачының күңел кылларында чыңлаган Сәйдәш музыкасы спектакль булган көннең икенчесендә ул бөтен шәһәргә таралып үтелә торган, һәркем күңелендән сызгырып, шыңшып, борын астыннан булса да ерлап йөртә торган Сәйдәш көйләре – бу бит татар театры өчен һәркайда мактана алырлык факт» [Бурнаш Ф, 1918].

1900–1918 елларда Казан ханлыгы чорының мәшһүр ханбикәсе Сөембикә шәхесенә игътибар зур була. Аның турында күпсанлы фәнни мәкаләләр, сәхнә, проза әсәрләре языла. Бу чорда Сөембикә тарихи шәхес буларак кына түгел, ә милли азатлык идеалын үзенә туплаган образ буларак ачыла. Кызганыч ки, совет чорында татар язучылары милли тарих, дәүләтчелек турында язудан мәхрүм ителделәр. Мәсәлән, заман рухына хас булганча, М. Зәетов Сөембикәне уңай яктан сурәтләми. Бу хакта «Тамашачы» (1928, №1) журналында имзасыз бастырылгын мәкаләдән дә укып белеп була. «Хөкүмәтнең алдында күп вазифалар торуына карамасдан, сарайда көчле шәхси интригалар уйный. Халык ачлыкдан тилмерә, мирзалар тарафындан хатын-кызлар көчләнә, шуның белән бергә татар крестьян һәм һөнәрчеләре күтәрә алмаслык төрле налоглар белән эшдән чыгалар. Халык арый, ил сугыш инвалидлары белән тула, сугыш, ачлык, төркемчелек аркасында Казан ханлыгы бетәр хәлгә җитә. Сарайда мәхәббәт уеннары бара, мәхәббәт җырлары җырлана, тол калган ханбикә дә тик ятмый, Кырым мирзаларындан Госман исемле берәүгә мәхәббәт тота». Гали Рәхим дә үзенең бер мәкаләсендә, татар тарихының борынгырак дәверләреннән алынган тарихи пьесаларның татар сәхнәсендә сирәк куелуы хакында искәртә. «Әсир төрек офицеры Хәйдәр Гали тарафындан язылып, татарчага тәрҗемә кылынып, февраль чорында Кариев тарафындан куелган, һәр якдан зәгыйфь «Шаһгали хан» пьесасын алмаганда, Казан ханлыгы дәверен җанландыручы тарихи әсәрләр татар театрында куелганы юк иде. Шуның өчен «Ханбикә» пьесасының татар академия театры сәхнәсендә куелуы безнең сәхнә тарихында әһәмиятле бер вакыйга дип каралырга тиеш. Зәетов ибдәшнең «Ханбикә»се бу юлда беренче адым, беренче сынау дип каралырга тиеш» [Рәхим, 1928], ди ул. Мәкалә авторы фикеренчә, тарихи драмаларның сәхнәдә гәүдәләндерелүе – сәнгать ягыннан бик җаваплы эш. Мондый пьесаларның язылышы авторлардан, аларның куелышы режиссер һәм артистлардан бик зур хәзерлек, бигрәк тә гыйльми хәзерлек таләп итүен ассызыклый. Нәкъ менә шул яклардан карап, Г. Рәхим әлеге сәхнә әсәренең кимчелекле якларын күрсәтә. «Иң элек, тарихи пьеса язучы кеше тарихчы ук булмаса да, бер тарихчы кадәр, хәтта андан артыграк да үзенең алган тарихи чорын нечкәдән, тирәндән белергә, өйрәнергә тиеш. Бәлки автор бу турыда үз тарафындан зур тырышлык куйгандыр, шулай да, режиссерның тырышуына карамасдан, пьеса безне XVI гасыр Казанына алып кайтып, сәхнәдә күрсәткән нәрсәләрнең чынлаб да тарихи якдан дөреслегенә ышандыра алмады» [Рәхим, 1928]. Алга таба автор темасы, эчтәлегенә тулырак тукталып, кайсы якка тирәнрәк басым ясалырга тиеш булуы хакында әйтеп уза. Шулай ук әсәрнең тел ягына аерым туктала: «Башданаяк хәзерге әдәби татар теле белән язылган, сөйләшүләрендә тарихилыкка һич әһәмият бирелмәгән», – ди. Г. Кутуй (1903–1945) исә «Ханбикә» (Татар дәүләт академия театры. Мирза Зәетов әсәре. Сөембикә хакында легенда) дип исемләнгән

язмасында, әсәр авторын тәнкыйтьләп чыга. М. Зәетов тарафыннан Казан ханлыгы чорын, вакыйгаларын, Сөембикәне каралтып күрсәтүне, тасвирлауны кире кага, кабул итми. «Быелгы сезонның икенче спектакле булып куелган «Ханбикә» драмасы турында сүз башлавы, кай почмагыннан гына тотынсаң да, кыен. Әсәр үзенә тарихи исем алган булса да, тулы тарихи күренешне бирми. «Казан ханлыгының җимерелүе дә, кинәтдән, көтмәгәндә колакка кытыршы бәрелгән мылтык тавышлары һәм «грамота» уку белән генә аңлатыла. Әсәрдән читдә бәйләнми торган күренешләрне искә алмаганда, драманың бөтен нигезе, бөтен «экономикасы» – мәхәббәткә кайтып кала. Билгеле, тарихда төрле фикерләр, төрле материаллар ярылып яткан-да, мондый бай вакыйганы болай гына аңлату – академия театры өчен гафу ителмәслек эш. Гүяки, Сөембикә гыйшык утында янмаса, Кырым егетенең бөтен эш, бөтен омтылышы гыйшкы Әмирә булмаса, имеш, Казан ханлыгы да җимерелмәс иде, имеш, Казан да рус патшалыгына күчмәс иде. Казан ханлыгының экономика ягыннан көчсезлеге кайда? Сәүдә капитализмының башлануы кайда? Алар әсәрдә юк, яки күренерлек түгелләр. Аннары язучының Сөембикәгә бирелгән характеристикасы белән дә килешеп булмый. Зәетовның Сөембикәсе ямьсез, истеричка булып чыккан. Сөембикәнең власть яратуы да, акыллы булуы да, курыкмаслыгы да монда күренмиләр. Сыйнфый каршылыкны, туган, ямьсезлек белән генә биреп булмый. Кыскасы, әсәрнең төп нигезе, вакыйга – Казан ханлыгының җимерелүе – зәгыйфь» [Кутуй, 1928], – дип яза ул.

Истәлектә язучы, җәмәгать эшлеклесе Фатих Сәйфи-Казанлы (1888–1937) һәм аның тормыш иптәше – «Азат хатын» журналын оештыручыларның берсе, журналист, тәрҗемәче Абруй Сәйфи (1889–1960) бәясе дә китерелә: «Ул вакытта халыкны көрәшкә милләт-дин исеме белән чакырганнар. Шул моментны автор әсәрендә күрсәтмәсә, ул тарихны бозган булыр иде. Мәсьәлә анда түгел. Әсәрдә сарайның үз эчендә, автор әйтмешли, «диварлар артында» барган эчке көрәш моментлары аз күренә. Интриганың җебе мәхәббәт йомгагына уралган. Ә сарайда ул вакытта әсаси көрәш тәхет өчен булырга кирәк. Казан ханлыгы егылган көннәрдә Сөембикә сарайда гына түгел, Казан шәһәренең үзендә юк инде. Ә син аны көрәшнең иң ахыргы сәгатенә кадәр сарайда күрсәтәсең, хәтта аңар финал монологы бирәсең», – диләр [Зәетов, 185 нче фонд].

1929 елда «Безнең юл» журналы редакциясе агымдагы сезон турында анкета төзеп тарата һәм кайбер алган җавапларны журналга урнаштыра. Аларда шул заманның драматургиясе ни хәлдә, репертуар ничек сайлана, актерлар составы, гомумән, театрның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында бәяләре бирелә. Аларда «Ханбикә» спектакле дә телгә алына: «Әдәбиятның башка төрләренә караганда, драма әсәрләрен язу үзенә аерым катлаулы белем һәм осталыкны сорый. Драматург талантлы һәм мәгърифәтле бер әдип, шагыйрь булу өстенә, сәхнә кануннарын, артист сәнгатен белгән, хәрәкәт,

нәфис ритм кануннары белән танышкан художник да булырга тиеш. Шул шартларның кайсы булса да берәве табылмаганга да, мәсәлән, татар театрының быелгы сезонында Такташның «Югалган матурлыг»ы уңышсызлыкка очрады. Такташ яхшы ук көчле һәм нечкә психология нокталарын да күрергә булдыра ала торган шагыйрь булуына карамастан, аның драматургка хас сорауларга җавап биреп бетерә алмавы моңа иң зур сәбәпләрдән берсе иде, татар театрында «Ханбикә» тибындагы әсәрләрнең уңышсызлыкка очравына да иң зур сәбәп – бераз сәхнә кануннарына туры китереп эшләнү белән бергә, аларның әдәби әсәр булу ягыннан зәвыксыз, талантсыз язылган булуларыннан иде», – дип бәяли Галимҗан Нигъмәти («Безнең юл», 1929, № 5). Г. Кутуй да әлеге анкетага җавабында тагын бер кат «Ханбикә»не кискен тәнкыйть утына тота. Бу уңайдан, күптән түгел генә Татарстанның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында композитор Резеда Әхиярованың шагыйрь Ренат Харис либреттосына язылган «Сөембикә» операсын да телгә алу урынлы булыр. Киң җәмәгатьчелек операдагы Сөембикә образы, аның эш-гамәлләре белән килешмәде. Бигрәк тә ханбикәнең Кошчак морза сөяркәсе булуы белән. Опера дөньяга чыккач, премьераны тамаша кылган журналистлар «Сөембикә» операсының авторларын «Казан ханлыгының соңгы символын җимерүдә, Сөембикә-ханбикәне гап-гади татар хатыны итеп күрсәтүдә гаепләде. Тарихчы Фаяз Хуҗин сүзләре белән әйткәндә, «Сөембикәнең уйнашчы икәне тарихи яктан исбатланмый» [Сөембикә...].

Сөембикәне без ничә ел ханлык белән идарә иткән акыллы, чибәр, абруй казанган кеше һәм шул ук вакытта батыр йөрәкле милләт сакчысы итеп кабул итәбез. Сөембикә ханбикә – безнең бөек каһарманыбыз, гомумтөркичелек идеяләрен үзендә туплаган, милли символ дәрәҗәсенә күтәрелгән татар халкының горурлыгы. Бу уңайдан XX гасыр ахырында иҗат ителгән, тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне яктырткан әсәрләр игътибарга лаек. 80–90 нчы елларда язучылар, игълан ителгән сүз ирегеннән файдаланып, Болгар, Алтын Урда дәүләте, Казан ханлыгы чорларына багышланган, аларның таркалу сәбәпләрен тасвирлаган әсәрләр яздылар. Нәтиҗәдә Р. Батулланың «Сөембикә кыйссасы» (1991), М. Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк» (1990), «Шайтан каласы» (1993), «Сөембикә ханбикә Һәм Иван Грозный» (1992), «Хан оныгы Хансөяр» (1998), «Аллаһы бүләге» (1999), «Батыйхан Һәм Ләйлә» (2002), Ф. Латыйфиның «Хыянәт» (1993) һәм башка әдипләрнең әсәрләре дөнья күрде. Әлеге чор вакыйгаларын сурәтләгән әсәрләрнең күпчелегендә үзәк урынны татар ханбикәсе Сөембикә алып торды. Мәсәлән, 2014 елда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында танылган язучы Мәдинә Маликованың «Сөембикә» пьесасы «Соңгы риваять» исеме белән сәхнәләштерелде. Драмада Казан ханлыгы чорындагы хәйләмәкер һәм фетнә вакыйгалары, Казан ханлыгы чоры, андагы кешеләр тормышы тасвирлана. Автор Сөембикәне патшабикә сыйфатында

гына түгел, ә иле, халкы өчен кайгыртып яшәгән шәхес буларак ача. М. Маликова әйткәнчә: «Сөембикә — минем өчен бөек шәхес. Клеопатра белән чагыштырып карасак, безнең Сөембикә күпкә өстенрәк. Әсәрдә бәрелеш Явыз Иван белән түгел, Зөя каласын булдыруда зур роль уйнаган Серебрянный белән бәрелешләр тасвирлана. Сөембикәнең бер йомшак ягы – ул бик әхлаклы һәм гаделлеккә ышана торган саф намуслы хатын. Явыз Иванны ике тапкыр Казан яныннан куып җибәрә. Аны ачыктан-ачык көрәштә түгел, ә астыртын көрәш нәтиҗәсендә генә буйсындыра алганнар».

Спектакльнең режиссеры Рәшит Заһидуллин белдергәнчә: «Хан тәхетен кулга төшерү — эчке һәм тышкы дошманнарның төп максаты! Тик аларның хыялларын тормышка ашыру юлында бары бер генә киртә бар – тәхеттә горур Сөембикә утыра! Йомшак холыклы, әмма көчле рухлы, бәхетсез, ләкин сынауларга бирешмәс ханбикә мәңге кешеләр йөрәгендә урын алачак адымга барып, Казан ханлыгының соңгы риваятенә әверелә….» [Сөембикәнең...].

Билгеле ки, бер үк диндәге кардәш Кырым ханнарының идарә итүеннән курыккан Казан түрәләре Мәскәү патшасы алдында бил бөгүне өстенрәк күрәләр. Трагедиядә Нурали Ширин морза һәм аның яраннарының Сөембикәгә каршы көрәше, ахыр чиктә патшабикәне Явыз Иван кулына тапшырып, Шаһгалине кабат Казан тәхетенә кайтарырга тырышу вакыйгалары сурәтләнә.

1546 елдан бирле Казан ханлыгына хезмәт иткән кырымлы Кошчак углан аның яклаучысы булганда, Сөембикә үзен икеләтә көчле тойган. Колшәриф образы безгә Сөембикәне укымышлы, гади халыкка һәрвакыт ярдәм кулы сузучы, Казан халкы өчен утка-суга керергә әзер торучы олы зат итеп күрергә ярдәм итә.

Р. Хәмиднең Сөембикәсе исә дәүләт иминлеге өчен көрәшә торган идарәче генә түгел, ә баласының исәнлеген кайгыра торган ягымлы әни буларак сурәтләнә. Р.Хәмид әсәренең төп үзенчәлеге шунда, ул тарихта булмаган Язгөле образын кертә. Тарихи чыганакларда Сөембикә Шаһгалигә кияүгә бирелгәч кенә үлә. Пьесада исә ул, легендадагы кебек, манарадан сикерә. Ризван Хәмид Казан ханлыгының ханбикәсе Сөембикә хакында, легендаларга таянып, тарихи фактларны кулланып, неомиф иҗат итә. Сөембикәдән тыш авторның игътибары башка тарихи шәхесләргә дә юнәлтелә: Явыз Иван, Елена Глинская, илче Адашев һ.б. образларның һәрберсенең әсәрдә үз вазифасы бар. Драматург игътибарны Явыз Иван һәм аның якыннары арасында барган сөйләшүгә юнәлтә. Аларның Казан ханлыгын әлегәчә кулга төшерә алмауларының сәбәпләрен эзли. Төшендә Адашев дошманыннан үч алырга теләүче кешене күрә: «Имеш, ниндидер бер кеше дошманыннан үч алырга тели, ләкин үз көченә ышанып бетми. Шуннан ул нишләде, дисез? Тотты да берничә кешене үзенең дошманына каршы котырта башлады: янәсе, теге адәм берсен халык арасында мыскыллы сүзләр белән сүккән, икенчесенең шәп атына кызыгып йөри, өченчесенең хатынына оятсыз рәвештә күз ата. Адашев Иван патшага

Казанны төшендәгечә кулга төшерергә киңәш итә. Көнбатыш христиан дәүләтләре белен берләшеп, хәрби көчне арттырырга, Казанның үз эчендә тәхет өчен эчке көрәшне көчәйтү зарурлыгы турында әйтә. Казан ханлыгы тормышындагы иң катлаулы вакытта Сөембикәгә терәк булырга тиешле кешеләр тәхет бүлешәләр, мәкерле планнар коралар. Шул рәвешле, драматург игътибар үзәгенә һәлакәтнең төп сәбәпчеләре булган морза һәм бәкләрнең хыянәтчел мөнәсәбәтен күрсәткән күренешләрне куя. Драмада шундый типларның берсе – Камай морза. Камай морза югары власть турында хыяллана, һәм үзенең күптән көткән максатларын тормышка ашыру өчен, җентекле план төзи. Моның өчен ул ханбикәгә ике тамчы су кебек охшаган Язгөле исемле кызны алдап тәхеткә утыртырга тели. Язгөле Камайның Сөембикәгә каршы планнарын аңлый һәм качып китә. Поэмаларында оптимизмга, тугрылык, батырлыкка дан җырлаган шагыйрь Мөхәммәдьяр үз халкының бердәм булмавына, коткыга бирелеп, дошманнар кулында җиңел генә үз-үзенә каршы коралга әверелә баруына әрни, әлеге катлаулы хәлдән котылу юлын күрә алмыйча гаҗиз кала. XVI гасырның бөек шагыйрьләренең берсе тарафыннан бирелгән бәя пьесаның трагик яңгырашын көчәйтә. Й. Нигъмәтуллина фикеренчә, «Бу әсәрдә акцент Сөембикә образыннан Язгөле образына күчерелә. Героиняларның берсе әсирлеккә караганда үлемне өстенрәк күрсә, икенчесе үч алу нияте белән әсирлеккә төшә». Ханбикәнең гәүдәсен Сафагәрәй төрбәсенә яшергәннән соң, аның киемнәренә киенеп, Язгөле үч алырга ант итә. Драматург игътибарны Касыйм шәһәренә, Шаһгали сараена, кызның антын тормышка ашырган вакыйгаларга күчерә. Язгөле, гомере буе Сөембикәне үзенеке итәргә хыялланган Шаһгалидән җәза ала. Явыз Иванның Казан өстеннән җиңүе билгесе буларак үткәрелгән туйдан соң, Язгөле үзенең кем булуын ача. Шул рәвешле, ялган Сөембикә – Язгөле Шаһгалидән генә түгел, ә Явыз Иваннан да көлә. Сөембикә образын иҗат иткәндә, Р. Хәмид халыкта киң таралган ханбикәнең үз-үзен үтерүе турындагы легенданы файдалана. Сөембикә Мәскәү патшасының колы булудан котылуның башка юлларын күрмичә, хан сараендагы мәчет манарасыннан сикереп һәлак була. Әмма автор тарихи дөреслекне бозмас өчен, Явыз Иванга тоткынлыкка кемне алып баруларын аңлату мөһим булганлыктан, әсәр тукымасына, Сөембикә образы белән беррәттән, аңа бик нык охшаган игезе Язгөле образын кертә.

Р. Хәмид Казан ханбикәсе образын иҗат иткәндә аның үз халкына булган кайгыртучан мөнәсәбәтен күрсәтүгә зур игътибар бирә. «Казан халкы! Идел-Йортыбызның мондый киеренке хәлдә калуы беренче тапкыр гына түгел! Безнең ата-бабаларыбыз андый чакта сыгылып төшмәгәннәр, киресенчә, бер тән, бер йодрык кебек берләшеп, дошманнарын, капка төпләренә килеп җиткәннәрен көтеп ятмыйча, каршы барып кыйнап җибәргәннәр. Без дә бүген шулай эшләр идек, ләкин көчебез чамалырак чак. Димәк, безгә икенче юл кала: үзара ызгышларны онытып, дошманга каршы ныклап әзер тору!» Кызганыч

ки, гади халык ханбикәнең сүзен үтәргә, якларга әзер торса, аның гаиләнә-тирәсендәгеләр өчен үзләрен саклап калу мөһимрәк булып чыга. Шул рәвешле, пьесада Сөембикә зур газапларга дучар ителгән, әмма шул ук вакытта көчле, үз идеалларыннан кайтмаган трагик герой итеп сурәтләнә. Тарихи чынлыкны тасвирлау тарихи шәхескә игътибар артуга китерде. Мондый шәхесләрнең тормышлары, язмышлары үткән заман хакында гадел фикер йөртүгә юл ачты. Гыйбрәтле язмышлар, вакыйгалар бүгенге яшәешебез хакында уйланырга, үткәндәге хаталарны кабатламаска тырышырга ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Борһан Сафа*. Сөйләшәсе бар // Безнең юл. 1929. № 20.

*Бурнаш Ф.* Номерсыз урындык // «Кояш». 1918. 22 май.

*Гарипова Л.Ш., Миннуллина Ф.Х., Хуснутдинова Г.А., Зайнеева Г.Н.* Пьеса «Сююмбике» («Ханбика») М. Заитова и ее анализ на страницах периодической печати / Казанская наука. 2020. № 5. С. 18.

*Нигъмәти Г.* Яңа сезонга таба // Безнең юл. 1929. №5.

*Зәетов М.* «Ханбикә» пьесасы хакындагы истәлекләрем / ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 185 фонд, 3 тасв., 183 сакл. бер.

*Кутуй Г.* Театр тирәсендә // Безнең юл. 1928. № 9. Б. 40.

*Рәмиева И*. Рус, татар төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. – Казан, 2009. – 244 б.

*Рәхим Гали.* Академия театрында тарихи әсәрләр // Кызыл Татарстан. 1928. 28 ноябрь.

«Сөембикә» драмасы языльп тәмамлануы турында //Вакыт. 1914. 17 декабрь.

Сөембикә Ханбикә сөяркә була аламы: «Сөембикә» операсыннан соңгы буран [Электон ресурс ] https://intertat.tatar/madaniyat/s-embik-khanbik-s-yark-bula-alamy-s-embik-operasynnan-so-gy-buran/.

Сөембикәнең серен Тинчурин сәхнәсе ача [Электон ресурс]: https://tinchurinteatr.ru/?p=1747.

***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.21

***Ф.Ф. Гыйлемшин***

# ГАРӘП ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ СУРӘТЛӘНЕШЕ
## («Мең дә бер кичә» әкиятләре мисалында)

В статье рассматривается система женских образов в произведении «Тысяча и одна ночь». Автор акцентирует внимание на особенностях изображения образов мудрой Шахрезады, воинственных девушек Зумурруд и Мариам, находчивых наложниц Анис аль-Джалис, Шамс ан-Нахар и Кут аль-Кулуб, хитрой Далилы и её дочери Зайнаб и др.

**Ключевые слова:** «Тысяча и одна ночь», сказка, Шахрезада, халиф, Нур ад-Дин, Зумурруд, визирь, Мариам, Далила, Харун ар-Рашид.

The article examines the system of female images in the work «One Thousand and One Nights». The author focuses on the features of the image of the wise Shahrezada, warlike girls Zumurrud and Mariam, resourceful concubines Anis al-Jalis, Shams al-Nahar and Qut al-Qulub, cunning Delilah and her daughter Zainab, etc.

**Key words**: «One Thousand and One Nights», fairy tale, Shahrezada, caliph, Nur ad-Din, Zumurrud, vizier, Mariam, Delilah, Harun ar-Rashid.

Борынгы гасырлардан башлап хатын-кыз образы дөнья әдәбияты мәйданында үзенчәлекле урын алып тора. Аларга багышлап шигырьләр, поэмалар языла, әсәрләр иҗат ителә. Гасырлар узу белән хатын-кыз образлары да үзгәрешләр кичерә, чөнки һәр чорның үз идеаллары була.

Гарәп әкиятләре тупламы булган «Мең дә бер кичә» әсәренең буеннан буена акыллы, тапкыр, тәвәккәл, шул ук вакытта зирәк һәм кыю хатын-кызга дан җырлана. Һәр кичтә патшага мавыктыргыч һәм гыйбрәтле әкиятләр сөйләүче Шәһрезадә моңа үзе мисал булып тора. Шәһрезадәдә без шәхес бөтенлеген, эчке һәм тышкы гармониягә ирешкән хатын-кыз образын күрәбез. Вәзир кызының зирәклеге, кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтерлек әкиятләре аның үзен генә түгел, ил кызларының гомерләрен дә саклап кала.

Шәһрезадәнең үзе турында «Мең дә бер кичә»нең башында һәм ахырында гына мәгълүмат бирелә. Әсәр барышында мавыктыргыч әкиятләрне үлемгә хөкем ителгән кыз тарафыннан сөйләнгән булуын укучы онытып ук җибәрә. Әүвәлге әкиятләрнең берсендә Шәһрезадәнең белемле булуы, аның борынгы халыклар тормышы, патшалар тарихы турында күп китаплар укуы тырында әйтелә. Кызның тышкы кыяфәте турында әсәрдә бер сүз дә юк. Әмма Шәһрезадә белән тәүге тапкыр күрешкәндә патшаның аңа соклануы кызның чибәрлеге белән бәйле булган дигән фикер тудыра. Укучыны Шәһрезадәнең гүзәллеге түгел, аның зирәклеге һәм акыллылыгы, сөйләгән хикәятләрнең күплеге, кызның төрле фәннәрдән мәгълүматлы булуы шаккатыра.

Хикәятләр арасында әкиятче кыз турында «Кичә булгач, Шәһрезадә хикәягә башлап дияр ки...» [Әлф ләйлә вә ләйлә, 1, б. 22] яки «Янә ахшам булгач, Шәһрезадәдән шаһ хикәяне сөйлә, дип нияз әйләгәч, Шәһрезадә әйтде...» [Әлф ләйлә вә ләйлә, 2, б. 43] яки «Шәһрезадә таң якын дип сукут әйләде (сөйләүдән туктады)» [Әлф ләйлә вә ләйлә, 4, б. 46] кебек кыска хәбәрләр генә бирелә.

Шулай мавыктыргыч хикәяләр сөйли-сөйли мең дә бер төн үтеп китә. Әсәрнең ахырында без Шәхрияр патшаның кызга гашыйк булуы, аңа өйләнүе, гөрләтеп туй итүләре, өч балалары туу һәм озын-озак бәхетле гомер кичерүләре мәгълүм була.

«Шәһрезадә әкиятләре ... вәзир кызының эчке дөньясының байлыгын, талантлылыгын, зирәклеген күрсәтә» [Миңнегулов, 1993, б. 291].

«Мең дә бер кичә» геройларының күбесе – хатын-кызлар. Алар арасында зифа буйлы, нурлы йөзле чибәр җарияләр дә бар. Кызлар коллыкны гадәти хәлгә саныйлар, еш кына байлыкларын югалткан хуҗаларына төрлечә ярдәм итәләр.

«Ике вәзир һәм Әнис әл-Җәлис турындагы хикәят»тә әнә шундый җария кыз турында сөйләнә. Әнис әл-Җәлис – зифа буйлы, чибәр йөзле, коңгырт-кара күзле, тәмле телле кыз. Аны коллар базарыннан хәлифнең бер вәзире Һарун әр-Рәшид өчен сатып ала, һәм патшага күрсәткәнче, беразурет ял итеп алсын дип, үзенең өенә алып кайтып, бер бүлмәгә бикләп куя. Вәзирнең Нуретдин исемле улы була. Егет шул бүлмәгә керә һәм кызны күрү белән аңа гашыйк була. Вәзир бу хәлгә бик нык ачуланса да, улын җария кызга өйләндерергә мәҗбүр була. Бер елдан соң вәзир үлә. Нуретдин әтисеннән калган мал-мөлкәтне тиз арада туздырып бетерә, дуслары да аннан ваз кичәләр. Әнис әл-Җәлис, егетнең матди хәлен җиңеләйтү өчен, үзен базарда сатарга киңәш итә. Ләкин бу эш барып чыкмый. Яшьләр корабка утырып юлга чыгалар һәм Багдад шәһәренә килеп җитәләр. Багдад шәһәре буйлап йөргәндә, хәлиф Һарун әр-Рәшиднең бакчасына барып җитәләр. Бакчадагы матурлыкны күрү өчен эчкә үтәләр. Бакчачы карт та, яшьләрнең күркәмлегенә сокланып, аларның теләгенә каршы төшми, киресенчә, хәтта җиләк-җимешләр белән сыйлый. Төн җиткәч, бакчада янган утларга шикләнеп, Һарун әр-Рәшид балыкчы кыяфәтендә болар янына килә, һәм бакчага рөхсәтсез кергән өчен, аларны җәзага тартырга тели. Ләкин Әнис әл-Җәлис патшадан гафу сорый һәм музыка коралында уйный башлый. Һарун әр-Рәшид кызның осталыгына шакката [Герхард, с. 348] һәм аларны гафу итә. Нуретдин хәлифкә, хөрмәт йөзеннән, үзенең җариясен бүләк итә. Һарун әр-Рәшид егетнең юмартлыгына сокланып, аны хәлиф сараена эшкә ала.

Күп еллар үткәч, төрле михнәтләр кичергәннән соң, Нуретдин белән Әнис әл-Җәлис тагын кавышалар һәм озак еллар бәхетле тормыш кичерәләр.

Әнис әл-Җәлис – «Мең дә бер кичә»дә еш очрый торган җария образларының берсе. Ул белемле, чибәр, кыю һәм бик талантлы кыз:

төрле музыка коралларында уйный белә, шигырьләр яза. Үзенең чибәрлеге, тапкырлыгы, зирәклеге белән хуҗасына катлаулы мажаралардан исән-имин чыгарга, икесенең дә гомерләрен саклап калырга ярдәм итә.

Әнис әл-Җәлискә ошаган тагын бер Кут әл-Кулуб исемле жария кыз образы белән без «Ганим ибн Әйүб турындагы хикәят»тә очрашабыз.

Бу әкиятнең төп персонажы булган сәүдәгәр Ганим ибн Әйүб төнлә очраклы рәвештә шәһәр читендә бер ташландык җиргә килеп чыга. Төн уртасында зур сандык күтәргән өч кара гарәп килеп, сандыкны бер чокырга күмеп китәләр. Болар киткәч, Ганим сандыкны казып ала һәм ачып карый: аның эчендә матур киемнәр кигән, кыйммәтле энҗе-мәрҗәннәр таккан бер бик чибәр кыз йоклап ятканын күрә. Кыз уянгач, егеттән өенә алып кайтуын үтенә. Ганим кызны өенә алып кайта, алар бер-берсенә гашыйк булалар, кыз аңа үзенең Һарун әр-Рәшид җариясе булуын әйтә.

Күпмедер вакыттан соң хәлифкә җариясенең исән-сау булуы, бер егетнең өендә яшәгәнлеге мәгълүм була. Ул бик нык ачуланып, Ганим ибн Әйүб фатирына гаскәр җибәрә, егет качып котыла, кыз хәлиф сараена кайта. Әкият әйбәт тәмамлана: хәлиф егетне гафу итә, аның сеңлесен үзенә кияүгә ала, Ганимне Кут әл-Кулубка өйләндерә.

Кут әл-Кулуб акыллы, зирәк, тапкыр һәм курку белмәс кыз булып чыга. Ул дөреслекне ачарга ярдәм итә, хәлифкә үзенең тугрылыклы булып калуын, Ганимне яратуын, аның белән кавышырга теләвен әйтә һәм үзенең максатына ирешә.

Һарун әр-Рәшиднең тагын бер җариясе белән без «Гали ибн Бәккәр һәм Шәмс эн-Нәһар турындагы хикәят»тә очрашабыз. Шәмс эн-Нәһар бик нәзакәтле кыз, хәлифнең җариясе булу аңа җәмгыятьтә үзенчәлекле урын биләргә ярдәм итә. Ул базарга әйберләр алырга барганда, аны – ун кәнизәк кыз, кунаклар каршы алганда алтмыш җырчы кыз озатып йөри. Хәтта үзенең сөеклесе Гали ибн Бәккәр белән очрашканда да ул ялгыз кала алмый. Аның бөтен әйбере дә бар, ләкин иреге чикле, кыз алтын читлек эчендә яши.

Шәмс эн-Нәһар образы, алда сөйләнгән җария образларыннан аерыла. Ул үзенең тормышын үзгәртергә омтылмый, бәхете өчен көрәшергә теләми, язмышка сылтый. Әгәр ул кыюлыгын туплап, Кут әл-Кулуб кебек, сөеклесе белән бергә булырга, мал-мөлкәтне яраткан кешесенә алыштырырга теләвен Һарун әр-Рәшидкә әйтсә, киң күңелле хәлиф каршы килмәгән булыр иде. Әмма кыз алтын читлектә дә яшәргә теләми, яраткан кешесе белән бергә булырга да омтылмый. Әкият аяныч тәмамлана: яшьләр, бер-берсеннән еракта булсалар да, бер үк көнне бер үк вакытта һәлак булалар. Шәмс эн-Нәһар – серле, меланхолик, фатализмга һәвәс образ. Ул, матур кош кебек алтын читлектә яши һәм шунда һәлак та була.

Шәһрезадә хикәятләрендә чибәрлеге белән теләсә кемне таң калдырырлык Тәваддуд образы да игътибарга лаек. Ул байлыгын

югалткан хуҗасы Әбу Хөсн белән Һарун әр-Рәшид янына килә һәм сарай галимнәре өчен оештырылган ярышта катнаша. Дин белеме, фәлсәфә, Коръән тәфсире, табиблык, музыка фәннәре буенча Тәваддуд җиңеп чыга. Шахмат уенында да аңа тиңдәш табылмый. Кызның тапкырлыгына хәлиф тә таң кала.

«Мең дә бер кичә» әкиятләрендә зирәк, җитез, сугышчан хатын-кыз образлары да еш күзәтелә. Алар – үзләре өчен һәм сөекле ирләре өчен бәхеткә ирешергә сәләтле хатын-кызлар. Шуларның берсе – «Гали Шәр һәм Зумурруд хикәясе»ндәге Зумурруд образы.

Зумурруд Гали Шәрне коллар сата торган базарда күреп ала. Егет байлыгын туздырып бетергән, бөлгенлеккә төшкән була. Кыз аңа акча биреп, үзен сатып алырга мәҗбүр итә. Шуннан соң кыз чигелгән тәрәзә пәрдәләре тегеп, аларның сатып, икесенә дә җитәрлек акча эшли башлый. Аларның бу тыныч тормышларын Гали Шәрнең башбаштаклылыгы боза – ул өенә дошманын алып кайта. Нәтиҗәдә Зумуррудны урлап китәләр. Егет кайгыга бата, төшенкелеккә бирелә. Әмма кызны эзләп табу өчен бер чара да күрми. Аның бу мескен халәтен күргән бер әби, егетне кызганып, аңа ярдәм кулы суза. Ул кызның кайда булуын ачыклый һәм Гали Шәргә аны коткару юлын күрсәтә. Әмма иң кирәкле вакытта егет йокыга китә, һәм кызны башка берәү алып китә. Егеттә тагын депрессия башлана, ул өенә кереп бикләнә, авырый башлый. Бер ел дәвамында карчык егетне дәвалап аякка бастыра, кызны эзләп табарга үгетли. Күмәк тырышлык нәтиҗәсез калмый, кыз табыла, Зумурруднең тапкырлыгы һәм тырышлыгы аркасында яшьләр тагын очрашалар.

Кыюсыз, йомшак күңелле егет образы фонында зирәк, тапкыр, көчле рухлы, эшчән, чибәр хатын-кыз образы тудырыла. Ул курку белмәс, кыю, һ.б. ирләргә хас сыйфатларга ия, төрле һөнәрләр белә, дин мәсьәләләрендә дә мәгълүматы күп.

Мәсәлән, үзен юлбасарлар төркеме урлап киткәч, кыз аларны алдый, акчаларын ала һәм качып китә. Сөеклесе белән аерылышканга озак вакытлар үтсә дә, Зумурруд аңа тугрылыклы булып кала. Гали Шәр югалгач, кыз егет кыяфәтенә кереп, шәһәр белән бик оста идарә итә, халык аны ярата һәм хөрмәтли. Сөйгән ярын табу өчен, ул һәр ай башында шәһәр халкы өчен түләүсез мәҗлесләр уздыра, Гали Шәрне шунда очратырмын дип уйлый. Әкият яшьләрнең кавышуы белән тәмамлана.

Зумурруд – үз эченә ир-егетләр һәм хатын-кызларның күркәм сыйфатларын җыйган образ. Көчсез, булмаган, ярдәмгә мохтаҗ ир-егет һәм кыю, тәвәккәл, шул ук вакытта мөлаем, нәфис хатын-кыз образлары белән без «Мең дә бер кичә»нең башка әкиятләрендә дә очрашабыз.

Мәсәлән, «Нуретдин һәм Мәрьям турындагы әкият»тәге Мәрьям Зумурруд образының дәвамы булып тора.

Әкияттә Нуретдин үзенең начар эшләре белән таныла: ул өенә эчеп исереп кайта, әтисен кыйный, аңа авыр тән җәрәхәтләре сала, һәм әти-әнисенең җыйган акчаларын урлап, өennән чыгып кача.

Искәндәрия шәһәренең коллар базарында йөргәндә, аны Мәрьям исемле җария кыз күреп ала. Ул Нуретдиннең матурлыгын күреп гашыйк була, аңа үзен сатып алырга тәкъдим итә. Мәрьямны сатып алу өчен, егетнең әти-әнисеннән урлаган акчасы җитә дә.

Мәрьям егеткә бик нык ярдәм итә башлый, ашарга әзерли, өй эшләрен башкара, матур ефәк билбаулар тегә. Нуретдин бу билбауларны базарга алып чыга һәм бик кыйммәт бәягә сата. Шулай матур гына яшәп ятканда, Нуретдин кызны, исерек баштан, үзенең дошманнарына сатып җибәрә. Шуннан соң бик кызыклы мәгълүмат ачыклана: баксаң, Мәрьям франк (Европа) патшасының кызы, аны яшьли Көнчыгыш иленә урлап киткәннәр, ул ислам динен кабул иткән икән. Әтисе үзенең вәзирен аны эзләргә җибәргән. Аксак вәзир патша кызын тапкан, Нуретдиннән сатып алып, Европага алып киткән. Егет үзенең хатасын аңлаган һәм кызны эзләргә чыккан. Мәрьямны эзләп табып коткарганда, үзенең ваемсызлыгы аркасында, төрле маҗараларга юлыккан. Ләкин Мәрьям белән бергә алар барлык авырлыкларны җиңеп чыкканнар.

Нуретдин әкияттә аумакай, куркак, ваемсыз итеп сурәтләнсә, Мәрьям исә, киресенчә, сугышчан, батыр, нык рухлы кыз итеп тасвирлана. Чолганышта калгач, Нуретдин кызга үзенең тычканнан да куркуын, дошманнар белән сугыша алмавын хәбәр итә. Кыз бу хәбәрне гадәти кабул итеп, франк гаскәрен берүзе тар-мар итә. Бу вакыйганы әкият сөйләүче тарафыннан комик ситуация тудыру өчен махсус уйланылган адым дип санарга мөмкин.

Шәһрезадә әкиятләрен өйрәнүче галим Миа Герхард «Мең дә бер кичә»дә сурәтләнгән христиан патшабикәләренә билгеле бер дәрәҗәдә амазонкалар сыйфатлары да хас булуын ассызыклый [Герхард, б. 127]. Чыннан да, Мәрьям бик сугышчан кыз, ул йөзенә тиредән ясалган битлек киеп, дошман корабына һөҗүм итә, башта капитанны, аннан соң матросларны юк итә, үзен Нуретдиннән сатып алып, әтисе янына алып киткән аксак вәзирнең дә башын кисә. Кызның кыюлыгына һәм тәвәккәллегенә хәлиф Һарун әр-Рәшид тә шакката. Ә Нуретдин үзенең тышкы кыяфәте белән генә хәлифнең игътибарын җәлеп итә ала.

Мәрьям образы һичшиксез, әкияттә уңай образ буларак карала, әмма монда дини фанатизмга зур урын бирелә, әхләкый як бераз аксый: ике герой да үзләренең әти-әниләренә бик начар мөнәсәбәттә. Бу күренеш бераз сәеррәк тәэсир калдыра.

Кайбер әкиятләрдә хатын-кызлар максатларына ирешүдә хәйләне дә юлдаш итәләр. Моңа «Хәйләкәр Дәлилә һәм мәкерле Зәйнәп турындагы хикәят»не мисал итеп китерергә мөмкин. Аналы-кызлы Дәлилә белән Зәйнәп, изге максатларны күздә тотып, халык исәбенә көн күрүче залим түрәләргә каршы көрәш ачалар. «Хәйлә капчыгын асып, мәкер таягына таянып» Дәлилә карчык түрә хатыннарын акылга утыртып йөрсә, кызы Зәйнәп анасыннан да уздырып, түрәләрнең үзләрен төп башына утырта. Максатларына ирешүдә хәйләгә,

кайчагында алдауга таянган Зәйнәп соңыннан тугрылыклы хатын һәм кайгыртучан ана була.

«Мең дә бер кичә» әкиятләрендә явыз патшалар да, икейөзле түрәләр дә тәхетсез кала. Яла ягучы, хыянәтче хатыннар да тиешле җәзасын ала.

Әкиятләрдәге сюжетлар, образлар охшашлыгы татар халык авыз иҗатында, язма әдәбиятта киң чагылыш тапкан. Мөхәммәдьяр, Каюм Насыйри, Габдерәхим Утыз Имәни, Нәкый Исәнбәт әсәрләрендә дә бу традицияләр дәвам итә.

Әлеге мәшһүр әсәр берничә гасыр дәвамында татар укучысының яраткан китабы булып кала. Бу аңлашыла да, Җирдә кешелек яшәгәндә, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр – мәңгелек.

**Әдәбият**

*Герхард Миа И.* Искусство повествования: литературное исследование «Тысяча и одной ночи»: пер. с английского / автор послесловия И.М. Фильштинский. М.: Наука, 1984. 455 с.

*Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и восточная классика. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 383 с.

«Тысяча и одна ночь»: избранные сказки / перевод с арабского М.А. Салье, вступ. статья и прим. И.М. Фильштинский. М.: Гос. изд-во худ. лит., 1983. 542 с.

Әлф ләйлә вә ләйлә. 1 т. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1897. Т. 1. 113 б.

Әлф ләйлә вә ләйлә. 2 т. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1898. Т. 2. 160 б.

Әлф ләйлә вә ләйлә. 3 т. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1899. Т. 4. 318 б.

Әлф ләйлә вә ләйлә. 5 т. Казань: Типо-литография Императорского университета, 1899. Т. 5. 372 б.

***Гыйлемшин Флер Фоат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*гыйльми сәркәтибе*

УДК 82.091

***Г.Ф. Төхфәтова***

# «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МӘҖМУГАИ АСАРЕ» ҖЫЕНТЫГЫНЫҢ БАСЫЛУ ТАРИХЫ, ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В статье, основываясь на нововыявленных источниках, воспоминаниях современников, рассматривается история подготовки, издания сборника произведений Габдуллы Тукая 1914 года.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, история литературы, история изучения, изобразительное искусство, текстология произведений Г. Тукая, татарская литература.

The article, based on newly revealed sources and memoirs of contemporaries, examines the history of the preparation and publication of the collection of Gabdullah Tukay's works in 1914.

**Keywords:** Gabdullah Tukay, history of literature, history of study, art, G. Tukay's textual works, Tatar literature

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның үзе исән вакытта барлыгы 33 китабы дөнья күрә. Аның вафатыннан соң да җыентыклары басылып чыгу дәвам итә. 1913 елда алты китабы, тагын бер елдан соң ун китабы нәшер ителә. 1914 елда «Мәгариф» нәшриятында күптән көтелгән, «Һәр өйдә бер нөсхә булырга тиеш китап» [Игълан, 1915] – «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» басыла. 1915 елда Петербургта чыга торган «Ил» газетасы билгеләп үткәнчә, «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре – әдәбиятымызда беренче мәҗмугаи асардер» [Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре, 1915].

Шагыйрьнең үзе исән вакытта нәшер ителгән китаплары 20–70 битле булса, әлеге мәҗмуга шагыйрьнең үз чорында китап-рисаләләрендә, газета һәм журналларда дөнья күргән күп кенә әсәрләрен бергә туплаган 463 битле җыентык булып дөнья күрә. Ул озак еллар укучылар ихтыяҗын канәгатьләндереп килә, һәм берникадәр кыскартылып, 1918 елда яңадан бастырыла.

Китап Казанда «Мәгариф» көтепханәсе, «Мәгариф» матбагасында нәшер ителгән. Казан губернаторы тарафыннан алдынгы идеяләр чагылдырган әсәрләр бастырганы өчен яптырылган «Матбагаи Шәрәф» һәм «Үрнәк» матбагаларының турыдан-туры дәвамы булган әлеге нәшрият белән бертуган Гыйльметдин (1885–1943) һәм Борһан (1883–1942) Шәрәфләр идарә итә. Бу типографиядә М. Гафури (1880–1934), Ф. Әмирхан (1886–1926), Г. Камал (1879–1933), С. Рахманкол (1888–1916), Х. Ямашев (1882–1912) һ. б. китаплары нәшер ителә. Г. Тукай әсәрләренең күп өлеше (14 китап) шушы нәшрият басмасында тарала.

«Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларны теркәү дәфтәре» [Татарстан Республикасы Милли архивы...] буенча 1914 елның октябрендә нәшер ителгән «Мәҗмугаи асар»ен Тукай үзе исән чагында төзеп калдырган [Тукай, 2016, 6 т., б. 353.]. 1913 ел башында Шәрәфләр белән килешү төзегәннән соң [шунда ук], шагыйрь «...шул мәҗмуганы төзү өстендә бик басылып эшкә кереште. ... Мәҗмуга, Тукайның үзе исән вакытында басыла башлап, Тукай үлгәч ... дөньяга чыкты» [Әхмәров, 1960, б. 193], – дип яза журналист, нәшир һәм педагог Ш. Әхмәров (1882–1966) үзенең бер истәлегендә. «Мәҗмуга өч төрле кәгазьдә бастырылган, иң очсызының хакы 1 сум 75 тиендер. Баш склады Казанда, «Мәгариф» көтепханәсендә. Башка мәшһүр китапчыларда да бардыр» [Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре, 1915], – дип яза «Ил» газетасы 1915 елның башында. «Бәһасе гади кәгазьдә әҗза[1] – 1 сум 7 тиен, мөҗәлләд[2] – 2 сум, әгъла кәгазьдә әҗза – 2 сум 2 тиен, мөҗәлләд – 2 сум 55 тиен, коленкоровый мөҗәлләд – 3 сум, әгъла мөҗәлләд – 5 сум, бархат белән тышланган әгъла... – 10 сум. Пучта мәсарифы алучыдан. Задаткасыз налож йибәрелми» [Игълан, 1915], – дигән игълан «Кояш» газетасының 1915 ел 16 апрель санында басыла.

Җыентыкның тарихы 1912 елның көзендә башлана. Клячкин хастаханәсендә ятканда да Г. Тукай эшен туктатмый. Шагыйрьнең үләренә 40 көн кала, аның янына хастаханәгә килгән нашир Шәһәр Шәрәф (1879–1938) Г. Тукайның, «Мәгариф» көтепханәсе тәкъдиме буенча, үзенең бөтен язган шигырьләрен бер тәртипкә төзәтеп, «Мәҗмугаи асар» әзерләгән вакыты»на [Шәрәф, 2015, 1 т., б. 290] туры килә. Шул вакыт бәгъзы шигырьләрен бозып, төзәтеп утырган Тукай үзенең иҗатын «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми» [Шәрәф, 2015, 1 т., 290 б.] , – дип бәяли.

14 мартта Г. Тукай соңгы мәкаләсен – «Уянгач беренче эшем» не яза. Мәкалә «Кояш» газетасының 1913 ел 18 март (74 сан) санында басылып чыга: «1913 ел, менә мин уяндым. (...) Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем. Валлаһел муаффикъ» [Тукай, 2011, 4 т., б. 262].

Әмма галим З. Рәмиев фикеренчә, «авыруы көчәйгәннән-көчәя барган шагыйрь «Мәгариф» нәшриятындагыларга җыентыкка кайсы әсәрләр кертелергә тиешлеген, аларның кайдан алырга тиешлеген генә күрсәткән булырга тиеш» [Рәмиев, б. 60]. «Монда «Мәгариф»тәгеләр үзләре дә шактый эш башкарганнар» [шунда ук].

Г. Тукай үлгәннән соң да, китапны нәшер итүгә әзерлек эше дәвам итә. Бу турыда вакытлы матбугатта, «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган китапларда хәбәр ителеп тора. «Кыска гына хәятендә матбугат вә әдәбиятымыз дөньясына байтак сөйкемле чәчәкләр

---

[1] Әҗза – кисәкләп, бүлекләп.

[2] Мөҗәлләд – төпләнгән, тышланган.

тезеп киткән мөхтәрәм шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләренең таралып яткан шигырь вә нәсерләре «Тукай мәҗмугасы» намилә[1] «Мәгариф» көтепханәсе хакында нәшер ителәчәге ... шагыйрь үлгән көндә, аның кабер якасында ук сөйләнеп, матбугат аркылы бәян ителгән бер фикер иде» [Юлдаш, 1915; Тукай – ядкәрләрдә, 1 т., б. 321]. Галимҗан Шәрәф (1896–1950) тарафыннан тупланган «Тукаев сүзләре» (1913) исемле җыентыкның кереш өлешендә түбәндәге юллар бар: «Тукай берлә якынрак, яхшырак танышырга теләүчеләргә Тукаевның тиздән басылып чыгачак «Мәҗмугаи асар»ене тәкъдим итәмез. Анда Тукаевның әлегә кадәр китап шәкелендә басылмаган байтак яңа әсәрләре дә булачакдыр. «Мәгариф» көтепханәсе» [Шәрәф, 1913, б. 31; Рухи мирас, 2016, б. 9].

Г. Тукайның мәҗмугаи асарләрен чыгаруга «Мәгариф» нәшрияты зур игътибар бирә, «мәҗмуганы тулы нәшер итү, шагыйрьнең җан хәрәкәтләрен төшенү өчен, төрле кешеләргә төрле мөнәсәбәт белән язылган мәктүбләрен, шигырь вә нәсерләрен сорап газеталарда игълан итә» [Юлдаш, 1915]. Матбугат укучылары да бу уңайдан үз теләкләрен белдерәләр: «Мәрхүм Тукаевның язылачак тәрҗемәи хәленә, аның татарча вә русча кулъязмаларының фотографлары, туган йорты вә авылының, сабак башлаган Кырлай авылы мәктәбенең, Уральскида укыган мәдрәсә вә шкуланың, остазларының рәсемнәре вә үзенең төрле вакытта алдырган рәсемнәре дә дәреҗ ителсен иде» [Фәхретдинов, 2015, 1 т., б. 674].

Җыентыкка тел һәм әдәбият галиме, тәнкыйтьче Җамал Вәлиди (1887–1932) тарафыннан кереш сүз әзерләнә. Әлеге мәкаләдә Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты беренче мәртәбә әтрафлы яңгыраш тапкан [Тукай, 2016, 6 т., б. 9]. «Бүгенгә чаклы Тукайның тормышы һәм аның әдәби иҗаты турында язылган тикшеренүләрнең иң мөһиме, шөбһәсез, Җамал Вәлиди каләме берлә язылып, Габдулла Тукаевның «Мәҗмугаи асаре»нең беренче басмасына кергән мәкалә иде» [Биктимер, б. 30], – дип билгеләнә «Яңа милли юл» журналының 1933 ел 5 нче санында. Тәнкыйтьче һәм әдип Р. Мөхәммәдиев Җ. Вәлидине бик хаклы рәвештә «тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләребездән беренче тукайчы» дип атый [Мухамадиев, 1982, с. 81].

Галим, беренчеләрдән булып, шагыйрьнең фәнни тәрҗемәи хәлен төзүгә омтылыш белдерә, иҗади үсеш баскычларын аерып чыгаруны тәкъдим итә [Габдулла Тукай. Энциклопедия, б. 156], фәнни биографиясен тудыруда беренче адымны ясый. Җ. Вәлиди шагыйрь иҗатын өч дәвергә бүлә: 1905–1907, 1907–1910, 1910–1913 еллар.

Г. Тукайның 1905–1907 еллардагы иҗаты «Шәкердлек һәм иске әдәбиятка тәкълид» дәвере буларак аерып карала. Җ.Вәлиди Тукай әсәрләрен иң беренче тапкыр «Нур» газетасында күрүен хәбәр итә, ә шагыйрьнең чынлап танылуы исә «Әлгасрелҗәдид» газетасында булуын искәртә. Автор Г. Тукайның беренче чор иҗатына хас төп

[1] Намилә – исем белән.

сыйфат итеп аның фикри үсешен күрсәтә. Үзенең фикерләрен шигырьләрнең идея-эчтәлеге, форма-төзелеше мисалында исбатлап бирә. «Тукаевның бу дәверендә (1905–1907) шикаять вә мөнәҗәтләрдән һәм сөю шигырьләрендән соң, «Пушкинә» һәм «Милләтә», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» кеби шагыйрьлек вә милләткә хезмәт хакында күбрәк өмид вә ышаныч илә аңкый торган шигырьләре күзгә бәреләә» [Тукай, 1914, б. 19],– дип яза Җ. Вәлиди. Ә 1907 елның башларында исә «Ул хәзер үзен мөстәкыйльрәк хис итә, аның телендә, өслүбендә дә госманлылыкдан татарлыкга таба бер сафлану вә истикъляял күренә», – дип ассызыклый [Тукай, 1914, б. 19].

Казан чорының беренче елларында – «Азатлык вә истикъляял» [Тукай, 1914, б. 19] дәверендә язылган шигырьләрендә, Җ. Вәлиди фикеренчә, осталык, талант хөкем сөрә, халык авыз иҗаты әсәрләреннән уңышлы файдалану, иркен, азат рухта иҗат итү күзәтелә. «Ишдә бу 1907–1910 еллар дәвере – аның шул шалтырап акган вакытыдыр. Аның бу дәвердәге шигырьләрен барысын бергә җыеп, бер якүн чыгарсак, бунларда өмид вә ышаныч ягы күбрәк чыгачак. Дөрест, бунда да зар-моңлар аз түгел, ләкин шунысы мөһимдер ки, бу моң вә өмидсезлекләр әле гомумирәк вә дөньядан зарлану рәвешендәрәк булып, аның үз шәхесенә карап, үзенә терәбрәк сөйләгән шигырьләре эчендә бигрәк өмид, ышаныч, хәтта горур сизелә» [Тукай, 1914, б. 19], – дип яза тәнкыйтьче.

«1910 елларда Тукаевның рухында шактый алмашыну сизелә. Бу алмашыну аның әллә ничек сүнүгә таба булганлыгын аңлата. Аның әүвәлге өмидсезлекләре, югарыда әйтелгәнчә, үз шәхесенә гаид түгел, бәлки әтрафдан, мохитдан алган бер күңелсез тәэсирдән гыйбарәт була иде». Бу чорда, галим фикеренчә, Тукай әсәрләрендә лирик геройның күңел дөньясы тагын да катлаулана, аның драматик кичерешләре, драматик психологизмы көчәя, бу Тукайның хәле, шәхси рухы, аңа иҗтимагый милли мохитнең тәэсире белән бәйле була [Габдулла Тукай. Энциклопедия, б. 157]. «Вәлиди Тукайда соңгы көнгәчә шигъри куәтнең кимемәве, сәнгати камиллек һәм лиризмның көчәюе, шагыйрьне әхлакый, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләрнең һәрдаим борчып торуы ... турында сөйли» [шунда ук, б. 156], – дип яза галим Т. Гыйләҗев.

Гомумән, Җ. Вәлиди бу мәкаләсендә Тукай иҗатына нигезле, фәнни югарылыкта бәя бирә. Ул шагыйрь иҗатын татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре белән бәйләп, тарихи, милли яссылыктан торып анализлый [Зарипова, б. 132]. Бу турыда ул түбәндәгечә яза: «Тукайның татар шагыйре икәнлеген, үзебезнең дә татарның зур кешеләреннән булып йөрүебезне онытабыз, һичбер кеше, үз халкының тарихыннан узып, әллә кая китә алмый; моның хикмәте нәрсәдәдер, ләкин бу – факт. Менә шуның өчен дә, Тукайны үлчәгәндә, Лондон белән, Нью-Йорк белән түгел, бәлки үзебезнең Казаныбыз белән үлчәргә туры килә».

Мәҗмугадагы кереш мәкаләгә тәнкыйть фикерләре дә әйтелә. «Мәҗмуганың тәрҗемәи хәл вә тәнкыйтьләре гаять суык кан вә

могтәдил[1] караш белән язылган. Ул бу кыйсемдә үзенең бурычын гүзәл генә үтәгән, шигырьләренә вә мәктүпләренә карап, аның җан хәрәкәтләрен тикшереп үткән, ләкин тәрҗемәи хәле бик кыска, шуның белән бәрабәр анда матбугат мәйданына чыккан нәрсәләрдән башка һичнәрсә белеп булмый» [Юлдаш, 1915; Тукай – ядкярләрдә, 1 т., б. 321], – дип бәяли шагыйрь Кыяметдин Юлдашев (1890–1955). Ул шулай ук «Тукайның шагыйрьлек чишмәсе Уральски булдыгыннан, андагы тормышын соң дәрәҗәдә дикъкатьләү тиеш иде», – дигән фикерне дә үткәрә. Берничә дистә елдан соң Р. Мөхәммәдиев, киресенчә, «тәнкыйтьченең Тукай турында инде ун ел чамасы төрле вакытлы матбугат органнарында чыгып килгән мәкаләләрне туплап, аларга күзәтү ясавы да үз чоры өчен гаять зур әһәмияткә ия булуын ассызыклый [Мөхәммәдиев, 2010, б. 487].

«Мәҗмугада Тукайның шигырьләре үзе тәртип итеп калдырган бүлемнәргә бүленгән» [Габдулла Тукай..., 1915]. Замандашларының истәлекләреннән күренгәнчә, Г.Тукай шигырьләрне урнаштыру тәртибенә нык игътибар бирә. «Үзенең әүвәлдәрәк, хосусән төрекләргә тәкълид берлә язылган шигырьләренең телен яратмаенча, шуларны бөтенләй мәҗмугадан төшереп калдырсам ничек булыр икән дип киңәшләште. Нәтиҗәдә ул шигырьләрне мәҗмуганың башларына куймый, урта бер йиренәрәк кертергә, һәрхәлдә, бөтен шигырьләрнең язылу тарихларын гыйлавә итеп бастырырга карар бирелде» [Шәрәф, 2015, б. 291], – дип яза Ш. Шәрәф. Җыентыкта шигырьләрне урнаштыру тәртибенә А.И. Емельянов та 1915 елда ук игътибар итә: «Принцип деления довольно странный, издатель, по-видимому, не считал серьезными произведения сатирического характера и детскую литературу. К тому же, этому делению издатель сам не остается верен; в разряд детской литературы, например, он включает автобиографические заметки Тукая, его мысли о произведениях татарской народной словесности, его историю татарских народных напевов и т.д.» [Емельянов, с. 6].

Мәҗмугада әсәрләр «Җитди шигырьләр», «Көлке һәм һәҗүв кыйсеме», «Балалар кыйсеме» исемле өч өлешкә бүленеп урнаштырылган. «Әмма бүленешне үзенчәлекле колонтитулга (ул битнең өске өлешенә түгел, бәлки аска урнашкан) таянып санасак, җиде булып чыга: өчесе югарыда аталды, калган дүртесе «Шүрәле», «Халык моңнары», яңадан «Балалар кыйсеме», «Нәсер кыйсеме» дип аталган.

Беренче өлештә әсәрләр «Җитди шигырьләр» исеме белән берләштерелгән. Биредә шагыйрьнең тәүге шигырьләре дә һәм шулай ук үлеменә берничә көн кала иҗат иткән әсәрләре дә кертелгән.

«Көлке һәм һәҗүв кыйсеме» «сиксән сәхифә чамасы булып, шагыйрьнең иң гүзәл шигырьләре кертелгән һәм гүзәл-гүзәл рәсемнәр белән бизәлгән» [Юлдаш, 1915; Тукай – ядкярләрдә, 1 т., б. 321].

---

[1] Могтәдил – уртача.

«Балалар кыйсеме»ндә Г. Тукайның 1908–1911 елларда балалар өчен язылган әсәрләре тупланган.

Г. Тукайның мәҗмугаи әсәре безгә авторның иҗат лабораториясен күзәтергә мөмкинлек бирә. Автор җыентыкка әсәрләр туплау барышында алар белән эшләүне дәвам итә. Шулай ук биредә әдәбият һәм тел галиме буларак Җ. Вәлидинең хезмәте дә зур була.

Берничә шигырь, алдагы басмалардан аермалы буларак, кыскартылып яисә шигырь юлларының урыннары алыштырылып тәкъдим ителә. Мәсәлән, мәҗмугада «Туган тел» шигыренең ике төрле варианты очрый. Беренче варианты тулы килеш «Балалар кыйсеме» бүлегенә кертелгән. «Халык әдәбияты» әсәре дә «Туган тел» шигыре белән тәмамлана. Әмма биредә әсәрнең икенче дүртьюллыгы төшереп калдырылган һәм соңгы өлешендә «үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам» гыйбарәләре үзгәртелеп, түбәндәгечә бирелгән:

Ярлыкагыл, дип, үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам.

«Көз» шигырендә дә шактый үзгәрешләр булуы күзәтелә. Әсәрне мәҗмугага урнаштырганда аның уртадагы һәм ахырындагы ике дүртьюллыгы төшереп калдырыла. Шулай ук «татар башы кеби кыр» гыйбарәсе «фәкыйрь калды кысыр кыр» юллары белән алыштырыла.

Мәҗмугада аерым бер сүзләрнең лексик-семетантик яктан үзгәртелүе, синонимнары, гарәп-фарсы алынмаларының татар сүзләре белән алышынуы һ.б. күзәтелә.

Җыентыкка шагыйрьнең 3 фотосы – 1908, 1911 елларда һәм Клячкин хастаханәсендә төшерелгән соңгы фотосурәте кертелгән.

Г. Тукайның 1908 елда төшкән фотосы «Габдулла Тукаевның матбугат галәменә беренче чыккан рәсеме» аңлатмасы белән китапның беренче битенә урнаштырылган. Әлеге рәсемдә шагыйрь бүгенге көндә Г. Тукай әдәби музеенда саклана торган түбәтәендә сурәтләнгән. Замандашлары искә алганча, аны шагыйрьгә 1908 елда яңа җыентык әзерләгәндә С.И. Иванов фотоостаханәсендә нашир Гыйльметдин Шәрәф бүләк иткән була [Мостакаев, б. 475; Багаутдинова, с. 54].

«Г. Тукаевның 1910 сәнәдә алдырган рәсеме» дип билгеләнгән фотосы кызыксыну уята. Чынлыкта бу шагыйрьнең Әстерханда 1911 елда И.М. Бочкарев фотостудиясендә С. Рәмиев һәм Ш. Гайфи белән бутафор көймәдә төшкән фоторәсемнең фрагменты. Шәһид Гайфи Г. Тукайның «Кыйтга» шигыреннән алынган «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым. Г. Тукаев» өзеге белән почта открыткасы бастырып чыгара.

Клячкинда төшкән фотосурәт хакында мәгърифәтче, «Мәктәп» журналы мөхәррире Шиһаб Әхмәров (1882–1966) истәлекләреннән укыйбыз: «1 нче апрель, өйләдән соң сәгать 3 тә «Габдулла әфәнде, хәлегезне үзеңез дә начар дисез һәм шулай күренә дә, мондый вакытта рәсем алдырып калу гадәте бар, бу нәрсә, сәламәтләнсәңез,

үзеңез өчен, тәкъдир йитеп үлсәңез, дустларыңыз өчен бер ядкяр булыр иде», – дия, рәсемене алдырырга рөхсәт сорадым. Моңар каршы: «Беркадәр хәл алгач алдырсак, ничек булыр икән, бер дә хәлем юк бит», – дисә дә, мин: «Сез шул урыныңыздан кузгалмассыз, Сезгә мәшәкъкате булмас», – дигәч, рөхсәт итте. Фотограф чакыртып, утырган һәм яткан көенчә рәсемнәре чыкартылды» [Әхмәров, 2015, б. 737]. Фотографы – И.М. Якобсон.

«Мәҗмугада «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан махсус фотографлар йибәрелеп алдырылган Г. Тукайның туган өе, укыган мәктәбе, авылының рәсемнәре ... бар» [Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре, 1915].

Тукай урыннары белән бәйле фотоларны беренче татар фотографларыннан Кыйвам карый Зөлфокаров (1870–1921) ясаган.

Шунысын әйтергә кирәк, каллиграф, педагог һәм фотограф Кыйвам карый Зөлфокаров исеме шагыйрьнең әсәрләрендә дә берничә тапкыр очрый.

Г. Тукайның «Мәҗмугаи асаре»ндә алтысы – Зөлфокаров ясаган фотолар: Г. Тукай туган Кушлавыч авылы; Кушлавычта Г. Тукай туган йорт; Кырлай авылында Фәтхрахман хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукай абыстайдан дәресләр ала); Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукайның әнисе Бибимәмдүдә туган; әнисе үлгәч, бәләкәй Габдулла бу йортта торган; 1912 елда Өчилегә кайткач та, Тукай бу йортта булган); Кырлай авылында Г. Тукай укыган малайлар мәктәбенең ике фотосы (берсендә мәктәп Кырлай мәчете фонында). Бу фотосурәтләр Г. Тукай белән бәйле күп басмаларга, шул исәптән юбилей альбомнарына да кертелгән. Ләкин басмаларның берсендә дә фотографның исем-фамилиясе күрсәтелмәгән.

«Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» – татар китап графикасының беренче үрнәкләреннән берсе. Җыентыкта «үзләренең тәэсир көче, эчкерсезлеге һәм эмоциональлеге белән аерылып торган» [Улемнова, б. 259] 33 иллюстрация бар. Бу китапта Г. Тукай иҗатын иллюстрацияләр белән бизәп бастыру тарихының беренче этабына йомгак ясала [Улемнова, б. 259]. Сәнгать белгече О. Улемнова фикеренчә, аларның, элеграк эшләнгән иллюстрацияләр кебек үк, шагыйрьнең турыдан-туры үзе катнашында әзерләнгән булу ихтималы зур [Улемнова, б. 259].

«Можно предположить, что все иллюстрации выполнены одним художником, но свои инициалы «Б.Э.» он оставил только к рисункам «Шурале», что видимо, это связано с тем, что это произведение стоит в сборнике первым» [Вагапова, с. 97], – дигән нәтиҗәгә килә Ф.Г. Вагапова. Әмма китапта Г. Тукайның «Шүрәле», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Кәҗә белән Сарык хикәяте» поэмаларына һәм «Тотса Мәскәүләр якаң», «Ысулы кадимче» шигырьләре өчен махсус ясалган иллюстрацияләр белән бергә, «Мияубикә», «Су анасы» шигырьләренә иҗат ителеп, инде дөнья күрергә өлгергән оригиналь иллюстрацияләр басыла һәм «Безнең гаилә», «Гали белән кәҗә», «Бичара куян», «Кызыклы шәкерт» шигырьләре рәсемнәренең «Милләт»

типографиясендә нәшер ителгән «Күңелле сәхифәләр» [Тукай, 1910, 16 б.] китабыннан алынган әзер клишелары да кулланыла. Кайбер рәсемнең әзерләнүе турында мөгаллим, дәреслекләр авторы, полиграфия эшлеклесе Хәбибрахман Зәбири истәлекләрендә ачыклык кертелә: «Беркөнне художник Зверевка барып, «Су анасы» һәм «Безнең гаилә» дигән шигырьләргә карата рәсемнәр ясарга заказ бирдек. Тукай шулар артыннан йөри-йөри үзе җитәкчелек итте. Хәзер булгач та, үзе алып кайтты, ләкин һичбер төсле канәгатьләнмәгәнлеген сөйләде» [Зәбири, б. 365]. «Кара инде, шул да булдымы песи, рәсемнең иң мөһим ноктасы безнең песи икәнлеген аңлата алмадык шул. Йә инде, татарлар чәй эчәргә ярата дигәч тә, ун чиләкле самавыр ясап куймыйлар бит. Моның самавыры нәкъ бабай кадәрле», – дип көлеп куя Г. Тукай [шунда ук].

Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасында «Б.Э.» имзасы белән билгеләнгән Г. Тукай әсәрләренә җиде иллюстрация саклана: «Шүрәле» әкият-поэмасына – 3, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына – 3, «Кәҗә белән Сарык» әсәренә – 1. Графит карандаш һәм каләм, пумала ярдәмендә тушь белән ясалган әлеге рәсемнәр «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»ндә нәшер ителгән. Кайбер рәсемнәрнең арткы ягында аңлатма язулары бар. Мәсәлән, «Шүрәле» әкият-поэмасына ясалган рәсем артында зәңгәр паста белән «Габдулла Тукай мәҗмугае асарен нәшер иткән чакта китап эченә кертер өчен эшләнелгән рәсемләрнең берсе «Шүрәле» әкиятенә бер күренеш. 1912 ел» [Татарстан Республикасы Милли музее..., 19981/2], – дип язылган. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» иллюстрациясе артындагы рус телендәге язу түбәндәгечә: «Подлинник рисунка к поэме А. Тукая «Кисекбаш» («Отрезанная голова»). Художник первый иллюстратор произведений поэта. Книга была издана в Казани в 191... году издательством Магариф братьев Шараф. Рисунок передан мне моей тетушкой З. Г. Шараф женой одного из издателей. Казань 1950 г.» [шунда ук, 19981/4]. Шундый ук эчтәлектәге язулар башка кайбер рәсемнәр артында да бар.

Әлеге рәсемнәр музей фондына 1985 елда театр эшлеклесе, педагог Саллави (Соловьев) Фуад Тимур улы тарафыннан тапшырыла. Ул – нашир, «Матбагаи Шәрәф» һәм «Мәгариф» нәшрияты хуҗаларының берсе булган Борһан Шәрәф улының (1883–1942) хатыны Закирә Гыйльман кызының туганнан туган энесе. Рәсемнәрнең берничәсе Г. Тукай әдәби музее экспозициясендә дә тәкъдим ителә.

«Б.Э.» монограммасы белән бирелгән рәссам шулай ук 1913 елның язында «Ялт-Йолт» журналы белән хезмәттәшлек иткән, журналның Г. Тукай вафаты алдыннан басылып чыккан 54 нче санының тышлыгын эшләгән, басманың чыгачак берничә санына иллюстрацияләр ясаган. Ягъни журналның җаваплы сәркәтибе булган Г. Тукайның авыруына карамастан, ул аның белән очрашырга тиеш була [Улемнова, б. 259]. Бүгенге көндә әлеге рәссамның кем булуы билгеле булмаса да, гарәп язуын укуда күзнең сулдан уңга таба хәрәкәт

юнәлешен саклаган рәсем композициясе аша аның көнчыгыш һәм ислам рәсем сәнгате традицияләренә якын булуын күрәбез [Вагапова, 2016, с. 98].

Китапка урнаштырылган рәсемнәр арасында Петербургта чыккан атналык «Живописное обозрение» журналында серияләп басылган иллюстрацияләр тәэсирендә иҗат ителгән [Тукай, 1911; Тукай, 2011, 2 т., б. 345] һәм, Г. Тукай әйткәнчә, «шактый муаффәкыятьле чыккан» [Г. Тукайның Сүнчәләйгә..., б. 219] «Мияубикә» әсәренең бизәлеше дә кызыклы. Биредә песиләрнең төрле позаларда һәм ракурсларда сурәтләнгән, хайваннарның тормыш итү рәвеше, төрле шартларда үз-үзләрен тотулары, хәрәкәтләре, хәтта уйланулары чагылыш тапкан 13 рәсем тәкъдим ителә. Бу иллюстрацияләр беренче тапкыр Г. Тукайның 1911 елда аерым китап булып басылып чыккан «Мияубикә» [Тукаев, 1911] китабында да кулланылган. Цинкографик клишелар, Н.И. Харитонов типографиясендә эшләгән осталарның берсе тарафыннан булса кирәк, башкала журналында басылган иллюстрацияләрдән, ирекле рәвештә текст эчтәлегенә көйләп, яңадан ясалган [Улемнова, б. 259].

Габдулла Тукайның «Су анасы» поэмасына иллюстрацияләр 1908 елда нәшер ителгән «Җуаныч» [Тукаев, 1908] китабыннан (китап ике төрле вариантта нәшер ителә. Берсендә төсле рәсемнәр кулланыла, ә икенчесендә, бәясен арзанайту тәэсирендәдер, алар кулланылмый) алынган. «Ирексездән матәм характерында булган җыентыкта «Су анасы», «Безнең гаилә» шигырьләре өчен әзерләнгән төсле рәсемнәр аклы-каралы итеп, троецлы ксилография техникасында эшләнгән яңа клишелар белән алыштырылган, алар китап бизәлешенә җитдилек һәм бөтенлек өстиләр» [Улемнова, б. 259].

«Безнең гаилә» әсәренә иллюстрация беренче тапкыр махсус Г. Тукайның «Күңелле сәхифәләр» җыентыгы өчен эшләнә. Сәнгать белгече О. Улемнова М.Я. Чемберс-Белебинаның «Живое слово» [Живое слово, ч. 2, с. 103] китабында басылган рәсемнең үрнәк итеп алынуын искәртә [Улемнова, б. 259]. Рәссам анда шул ук композицияне файдаланган, фәкать катнашучылар санын, татар көнкүреше үзенчәлекләрен истә тотып, киемнәрне генә үзгәрткән [шунда ук].

Мәҗмуганың тагын бер кыйммәте – биредә Г. Тукай автографы факсимилелары бирелә. Җыентыкка шагыйрьнең «Исемдә», «Васыятем» һәм шифаханәдә язган соңгы әсәрләреннән «Толстой сүзе», «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» шигырьләре кульязмаларының фотокүчермәләре бирелә.

* * *

«Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» китабы, шактый гына кыскартылып һәм шигырьләрне бүлекләргә урнаштыру тәртибенә дә берникадәр үзгәрешләр кертелеп, яңадан 1918 елда нәшер ителә, соңрак, 1933 елда Токиода басылып чыга. Кызганычка каршы, Габдулла Тукай үзе күрергә теләгән әлеге әсәрләр җыентыгы XX гасыр буена кабат дөнья күрмәде, ул игътибар үзәгеннән читтә кала килде.

2019 елда Г. Тукай әдәби музеенда, җыентык басылуга 115 ел тулуга багышлап, «Кулыма китап алам…» күргәзмәсе оештырылды. Анда «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» китабы, К. Зөлфокаров һәм Җ. Вәлиди турында материаллар урын алды. Әлеге җыентыкка кергән иллюстрацияләр белән күргәзмә аша да танышып була.

**Әдәбият**


*Әхмәров Ш.Г.* Тукай турында исемдә калганнар // Тукай турында замандашлары. Казан: Татар.кит.нәшр, 1960. Б.193.

*Әхмәров Ш.* Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 737–741.

*Багаутдинова Д.Б.* Музей Габдуллы Тукая в Казани. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 66 с.

*Вагапова Ф.Г.* Произведения Г. Тукая в иллюстрациях художников начала XX века // Габдулла Тукай һәм төрки дөнья: Халыкара конференция материаллары. Казан: ТәһСИ, 2016. С. 96–98.

Г. Тукайның С. Сүнчәләйгә язган хаты. 1911 ел, 4 март // Тукай Г.М. Әсәрләр: алты томда. 5 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 219–220.

Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре // Ил. 1915. 25 гыйнвар.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөх. З.З. Рәмиев. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

*Биктимер Г.* Тукайны аңлар өчен // Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз. З.Г. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 30–33.

*Емельянов А.И.* Краткий обзор татарско-мухаммеданской неповременной печати за 1914-й г. Казань : Центральная тип. 1915. 22 с.

*Живое слово*. Книга для изучения родного языка. Ч.II / сост. А.Я. Острогорский. СПб.: Т-во художественной печати, 1909. 406 с.

*Зарипова Р.* Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты турында Җ. Вәлиди // Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г. Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 130–132.

*Зәбири Х.* Шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 350–375.

Игълан // Кояш. 1915. 16 апрель.

*Мостакаев К.* Тукай турында исемдә калганнар // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз. Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 475–502.

*Мөхәммәдиев Р.* Фидакарьләр фидакарьлек көтә // Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. Б. 484–493.

*Мухамадиев Р.* Проблемы формирования татарской литературной критики (1905–1917). Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 144 с.

*Рәмиев З.* Әдәбиятчы-текстолог язмалары. Казан: Ислах, 2014. 436 б.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар / И.Г. Гомәров ред. Чыг. 1. Казан: ТӘһСИ, 2016. 276 с.

Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасы // КП 19981-2

Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасы // КП 19981-4

Татарстан Республикасы Милли архивы. 420 ф. 1 тасв.

*Тукаев Г.* Җуаныч. Казан: «Сабах» көтепханәсе, Н.И. Харитонов матбагасы, 1908. 19 б.

*Тукаев Г.* Күңелле сәхифәләр. «Мәктәп мөкяфәте»ннән 4 нче дәфтәр. Казан: «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы, 1910. 16 б.

Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төзүчеләр: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. 968 б.; 2 т. 720 б.

*Тукай Г.* Мияубикә. Казан: «Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов литотипографиясе, 1911. 24 б.

*Тукай Г.* Уянгач беренче эшем // Тукай Г.М. Әсәрләр: алты томда. 4 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 259 –262.

*Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 1 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Р.М. Кадыйров, З. Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт.: Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. 2011. 407 б.; 2 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. 2011. 384 б.; 3.т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов. 2015. 415 б.; 4 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. 2011. 431 б.; 5 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. 2016. 415 б. 6 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт.: Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина. 2016. 471 б.

*Улемнова О.* Рәсемнәр // Тукайга сәяхәт: күргәзмә катологы. Казан: Заман, 2016. Б. 256–273.

*Фәхретдинов Ә.* Мәрхүм Тукаевның... // Кояш. 1914. 6 май.

*Шәрәф Г.* Тукай сүзләре. 3 нче басма. Казан: «Мәгариф» ширкәте, 1913. 31 б.

*Шәрәф Ш.* Габдулла Тукай хакында бәгъзе хатирәләрем (Вафатына биш ел тулу мөнәсәбәте илә искә төшерү) // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 287–292.

*Юлдаш К.* Матбугат вә әдәбият (Тукай мәҗмугасы) // Тормыш. 1915. 14 гыйнвар.

***Төхфәтова Гүзәл Фәрдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Тукай әдәби музее мөдире,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара*
*багланышлар институтының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы*
*өлкән укытучысы*

УДК 82.091

***Җиһан Чакмак***

# ТАТАРЛАРНЫҢ КӨЧЛЕ КАЛӘМЕ – ФАТИХ КӘРИМИ

Фатих Карими, являющийся одним из важнейших представителей джадидизма среди татар, всю свою жизнь продолжал борьбу за реформистские идеалы и был связующим звеном между Стамбулом и Казанью.

Цель исследования – изучение деятельности Фатиха Карими в разных ракурсах. В данной статье освещается встреча отца Фатиха Карими – Гильмана Карими с Исмаилом Гаспринским, жизнь и деятельность Ф. Карими в Стамбуле, его отношения с представителями османских интеллектуальных и литературных кругов, издательская и творческая деятельность.

**Ключевые слова:** Фатих Карими, джадидизм, Исмаил Гаспрали.

Fatih Karimi was one of the most important representatives of Jadidism among the Tatars. And throughout his life he continued to fight for reformist ideals and was a link between Istanbul and Kazan.

The purpose of the research is to study the activities of Fatih Karimi from different angles. This article covers the meeting of Fatih Karimi's father – Gilman Karimi with Ismail Gasprinsky, the life and work of F. Karimi in Istanbul, his relations with representatives of the Ottoman intellectual and literary circles, publishing and creative activities.

**Keywords:** Fatih Karimi, Jadidism, Ismail Gaspirali.

Язучы, журналист, педагог Фатих Кәрими (Мөхәммәтфатих Гыйльман улы Кәримов) 1870 елның 30 мартында Самара губернасы Бөгелмә өязенең Миңлебай авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә [Госманов, 2000, б. 9]. Кәриминең әтисе Гыйльман ахун бөтен Идел-Урал буена мәгърифәтче һәм рухани буларак танылган һәм халык тарафыннан бик ихтирам ителгән шәхес була. Озак вакыт үз авылында имам-хатыйп булып эшләгән Гыйльман ахун, бала чагында Чырчылы мәдрәсәсендә башлангыч белем алганда ук үтә сәләтле һәм акыллы укучы буларак игътибарны җәлеп итә. Аның әтисе кечкенә Гыйльманны, укуын дәвам итү өчен, Чистай мәдрәсәсенә җибәрә. Чистайда ул җиде ел укый. Гыйльман Кәрими гомере буе халыкның яраткан рухание була.

Гыйльман Кәрими – үз эшенә чын күңелдән бирелгән тәрбияче һәм дин әһеле булган җәдитче. Күрсәткән хезмәтләре, тырышлыгы өчен ул Россия императорлары Александр III һәм Николай II тарафыннан алтын һәм көмеш медальләр белән бүләкләнә. Ләкин үзе ахун булган авылларда ул теләгән белем бирү системасының каршылыкка очравына бик нык борчыла. Планнары җимерелү сәбәпле, өметсезлеккә бирелеп, эшләгән мәдрәсәсен яба, муллалыктан баш тарта. Нәкъ шул елларда ул Кырымның Бакчасарай шәһәрендә

Исмәгыйль Гаспралының «ысулы җәдит» дип аталган яңа уку-укыту методына нигез салуы турында ишетә. Яңа белем бирү системасы белән бик нык кызыксынган Гыйльман Кәрими И. Гаспралы белән киңәшә башлый. Казан һәм Бакчасарай арасында хат алышу белән башланып киткән бу бәйләнеш, соңрак, һәр ике тарафның да катгый үз фикере булу сәбәпле, кискен бәхәсләргә хәтле барып җитә. «Исмәгыйль Гаспралы бәй үз язмаларында төрекләрнең, бер яктан, заманча белем алымнарын кулланырга тиешлеген, икенче яктан, мәдрәсәләрнең иске мәгариф системасында реформалар ясарга мәҗбүр булуын ассызыклый, һәм мәсьәлә бары тик шул юл белән хәл ителә ала, ди. Бу исә фанатик даирәләрдә көчле реакция тудыра. Чыннан да, бу даирәләрдән берничә кеше хәтта үз-үзен үтермәкче була. Аларның берсе Казан галимнәреннән Гыйльман Кәрими бәй (Илман Кәрими) була. Гыйльман бәйнең улы Фатих Кәрими – Оренбургта басылган «Вакыт» газетасының баш мөхәррире, шулай ук мәгърифәтче, Исмәгыйль бәйнең кайнар тарафдарларыннан берсе. Көннәрдән бер көнне, «Тәрҗеман» газетасын укыганда, әтисенең «Гаспралы үзенең яңа идеяләрен тарата һәм минем улым да аның артыннан бара» дип, улын үтерү карарына килгәнен белә. Ләкин төп гаепнең улында түгел, ә Гаспралыда булуын аңлап, аны үтерүне «үзенең вәҗибы» дип саный һәм Бакчасарайга китә. Фанатикларча инануына карамастан, Гыйльман Кәрими бәй акыллы кеше була, Исмәгыйль бәй белән бик мавыктыргыч һәм көчле бәхәсләргә керә. Нәтиҗәдә, Исмәгыйль Гаспралы бәйнең сак һәм акыллы сүзләренә инанган Гыйльман бәй тулысынча аның тарафдары булып туган ягына кайта һәм хәтта улы Фатих бәйне, белемен тәмамлау һәм төреклеккә хезмәт итү өчен, Истанбулга җибәрергә була» [Saray, 2008: б. 29, 30; Кырымэр, 1934, б. 47].

И. Гаспралы фәннең мәгариф тормышында мөһим һәм алыштыргысыз булуы турындагы фикерне алга сөрсә, Гыйльман Кәрими фәндингә киртә, дигән караштта тора. Озакка сузылган хат алышулар һәм бәхәсләр туктамый, һәм, ниһаять, Гыйльман Кәрими Бакчасарайга китә һәм Гаспралы белән очраша. «Исмәгыйль Гаспралы белән Гыйльман Кәрими арасындагы мөнәсәбәтләр әтисе хакында Фатих Кәрими язган биографиядә ачык тасвирлана: «Күп тә үтмәде, Бакчасарайлы мөхтәрәм Исмәгыйль Мирза Гаспринский «Тәрҗеман» газетасын чыгара башлады, безгә билгеле булмаган Европа һәм Россия дөньясына кечкенә генә булса да тәрәзә ачты, цивилизация һәм мәгариф ягыннан гасырлар дәвамында томаланып яткан аңыбызны агарта башлады: «Халкыбыз наданлыкта һәм зольмәттәдер, гыйлем һәм мәгарифкә бик мохтаҗбыз. Аксөякләребез һәм галим исемен алучыларыбыз дөнья хәлләреннән бихәбәр дәрәҗәдә гыйлем вә мәгарифтән мәхрүм булып тынычлап йоклаудадыр. Мәктәп вә мәдрәсәләребездәге ысулы җәдит белем бирүне үстерергә кирәк» дип, безнең электән гадәтләнгән фикерләребезгә өстәп, башка фикерләр яза башлады, болар безгә сәер тоелмады, үзебезнең элекке фикерләребезнең ялгыш булуын кисәк кенә тану авыр булды. Канымда һәм табигатемдә

кабатланган иске карашлар һәм гафләт йокысы аркасында Гаспиринский идеяләре минем үземә дә каршы булып тоелды. Килешәсем килмәде. Хат алыша башладык. Мин исламны һәм динне яклап, белем бирү, мәгариф, русча укыту мөмкин түгел, дигән фикер яклы идем. Ул исә, киресенчә, исламның һәм диннең яшәве, алга китүе белем бирү һәм мәгариф ярдәмендә генә була алуын, Рәсәйдә яшәүче ислам халкының рус телен белүе, һичшиксез, кирәк булуын алга сөрде. Бәхәсебез шактый дәвам итте, ничә тапкырлар аңа шактый кискен һәм ачык сүзләр белән хатлар язып, үз фикеремне якладым. Соңрак, ниһаять, Бакчасарайга шәхсән килеп, Гаспиринскийның үзе белән очрашып, үзебезнең максат һәм фикерләребезне ачык итеп һәм җентекләп аңлатканнан соң, мәсьәлә хәл ителде һәм икебезнең дә максатыбыз шул бичара һәм надан халкыбызны цивилизация һәм мәгариф юлына кертеп, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле итүдә булуы ачыкланды» [Кәрими, 1904, б. 7–8].

Гаспралы үзенең эшчәнлеге, мәктәпләрдә урнаштырган уку-укыту системасы, укучылар һәм укытучылар өчен язган китаплары турында сөйли һәм болардан бигрәк, үзенең теләкләрен Кәримигә ачык итеп аңлатып бирә. Бу очрашу һәр ике мәгърифәтче өчен дә бик файдалы була, Гыйльман Кәрими туган ягына Гаспралының идеяләрен кабул иткән татар зыялысы буларак кайта. Кайтып җитү белән, Гаспралының ысулы җәдит методын тормышка ашыру өчен, үзе эшләгән 136 авылда заманча мәктәпләр ача. Тирә-яктагы авылларда бу ысулны җәю өчен бик күп тырышлык куя һәм өлешчә уңышка да ирешә. «Богырыслан өязендә имам һәм ахун булып торган Рахманкуловның сүзләренә караганда, Россия мөселманнарының үсеш юлында бик зур хезмәт куйган ике шәхес бар. Боларның беренчесе итеп Исмәгыйль Бәй Гаспралыны атап үтәргә кирәк. Аның артыннан исә Гыйльман Кәрими халыкны агарту, укыту, белем һәм фән юлында алга китүе һәм баюы өчен иң зур тырышлык күрсәткән икенче шәхес булып тора» [Кәрими, 1904, б. 81].

Гыйльман Кәрими Фатихның сәләтле булуын күрә. Башка туганнарыннан үзенең холкы, укудагы уңышлары белән дә аерылып торган улын белемле итү өчен тырыша: башлангыч белемне Фатих Чистай мәдрәсәсендә ала, монда уку чорында классик белем бирү системасын уза. Гарәп, фарсы телләре берән беррәттән рус телен дә әйбәт дәрәҗәдә өйрәнә. 11 яшенә кадәр этисе мәдрәсәсендә укыган Фатих Кәрими Чистайда танылган галим Закир Камалов мәдрәсәсендә белем эсти. Бер үк вакытта Чистайдагы ике еллык рус мәктәбен дә тәмамлый. Ләкин Фатих Кәрими үзе укыган мәдрәсәләрдәге искечә тәрбия-белем бирүне кабул итә алмый. Алай гына да түгел, биредәге белем бирүне һәм укытучыларын тәнкыйтьләве аркасында, аңа мәдрәсәдән китәргә туры килә.

«Закир ишан атабызга хат җибәргән булган: “Улың Фатих бозылды, тиз килеп җит. Килеп алмасаң, мәдрәсәдән кудырып чыгарам”» [Шәрәф, 2000, б. 76].

Чистай мәдрәсәсендә укыган вакытта чыга башлаган «Тәрҗеман» газетасын яшерен рәвештә дуслары арасында укуы һәм рус китаплары белән кызыксынуы аның укытучысын борчуга сала. Шуның өчен укытучысы тарафыннан кяфер булуда гаепләнә һәм мәдрәсәдән куыла [Шәрәф, 1960, б. 76–77].

1891 елда ул укуын дәвам итү өчен, үз заманында иң яхшы мәктәпләрнең берсе булган Төркиядәге Мәктәб-е Мөлкиягә [Гражданлык мәктәбенә) җибәрелә. Монда уку елларында госманлы төрек телен яхшы үзләштергән Фатих Истанбулдагы мәдәният, сәнгать һәм әдәбият даирәләре белән дә яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра. Һичшиксез, Фатих Кәриминең Истанбулда белем алуында чорының иң көчле язучыларының берсе һәм бихисап әсәрләре белән «язу машинасы» буларак танылган Әхмәт Мидхәт әфәнденең ярдәме зур була. 1896 елда Истанбулда укуын тәмамлаганнан соң, Фатих Кәрими Кырымның Ялта шәһәрендә Исмәгыйль Гаспралы нигез салган ысулы җәдит мәктәпләрендә укыта башлый.

1898 елда ул Бакчасарайда җыелган укытучылар әзерләү курсларын җитәкли, әдәбият һәм педагогика дәресләрен алып бара. Истанбулда укуын уңышлы тәмамлаган соң, Кәрими туган ягына кайта.

Рус һәм француз телләрендә иркен сөйләшә алган Фатих Кәриминең сәләте алтын приискалары хуҗасы Мөхәммәтшакир Рәмиевнең игътибарыннан читтә кала алмый. Идел-Уралда сәүдә белән шөгыльләнүче Рәмиев кардәшләренең берсе Мөхәммәтшакир Рәмиев Европага сәяхәткә чыгарга әзерләнә һәм Фатих Кәримине дә үзе белән чакыра. Соңрак Фатих Кәрими бу сәфәр барышында туган күзәтүләрен «Аурупа сәяхәтнамәсе» исеме белән бастырып чыгара. 1899 елның 15 февралендә башланып, дүрт ай дәвам иткән сәяхәт Фатих Кәримигә Европаның алга киткән илләрен күрергә мөмкинлек бирә. Бу сәяхәт вакытында Кәрими Рәмиевләр гаиләсенә бик тә якыная, соңрак аларның юллары татар вакытлы матбугатының иң мөһим медиа органнары булган «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы тирәсендә кабат кисешә. Фатих Кәрими өчен әлеге сәяхәт барышында беренче мәртәбә төрки мөселман җәмгыятен Көнбатыш җәмгыяте белән чагыштыру мөмкинлеге туа. Анда алган тәэсирләрен язучы үзенең «Бер шәкерт илә бер студент», «Мирза кызы Фатыйма», «Салих бабайның өйләнүе, «Аннан-моннан» кебек әсәрләрендә искелек – яңалык, Көнчыгыш – Көнбатыш, мәктәп – мәдрәсә каршылыгы нигезендә чагылдыра.

Фатих Кәрими, алда әйтелгәнчә, күп телләр белә, шул ук вакытта кечкенәдән үк әтисе Гыйльман ахун аны полиграфия эшенә өйрәтә. 1899 елда исә имам һәм ахун вазифасыннан киткән Гыйльман Кәрими аны үзе нигез салган матбаганың җитәкчесе итеп куя. 1900 елда гаиләсе белән Оренбургка күченгән Гыйльман ахун бер иске басу станогы сатып ала. Зур тырышлык куеп, улы Фатих белән алар басмаханәне эшләрлек хәлгә китерәләр. Шунысы мөһим, Кәримиләр гаиләсенең матбугат эшчәнлегендәге бу беренче тәҗрибәләре алдагы

елларда «Вакыт» газетасының, басылачак газета-журналларның үзенә күрә бер репетициясе була.

1905 елгы революциядән соң барлыкка килгән ирек атмосферасы Россия мөселманнарының үсешенә зур мөмкинлекләр ача, яшерен рәвештә формалашкан азатлык идеясе әдәби, иҗтимагый-сәяси эшчәнлекнең тизләнүенә китерә. Бигрәк тә җәдитчеләр дип аталган яңарыш тарафдарлары мәгариф, матбугат, әдәбиятта һәм интеллектуаль тормышта бик мөһим үсеш-үзгәрешләрнең башында торалар. Фатих Кәрими – татар яңарышында мөһим урын алып, Россия мөселманнарына, аеруча Казан төркиләренә иң күп хезмәт иткән кешеләрнең берсе. 1905 елгы революциядән соң, бертуган Рәмиевләр 1906 елның 21 февралендә «Вакыт» газетасын бастыра башлыйлар. 1917 елга кадәрге 11 ел эчендә аның 2309 саны дөнья күрә. Фатих Кәрими «Вакыт» газетасында мөхәррир һәм төп авторларның берсе була. 1907 елда Оренбургта ачылган Этнография музееның Көнчыгыш бүлеген оештыруда катнаша. 1906 елда ул Дәүләт думасының II чакырылышына депутат итеп сайлана.

1905 елгы революция тудырган кыска вакытлы фикер иреге күп интеллектуаллар һәм зыялылар өчен китап бастыру мөмкинлеге бирә. Басма китапка булган зур ихтыяҗ нәшриятлар ачуны да таләп итә. Билгеле булганча, Мөхәммәтзакир Рәмиев 1880 елларда Истанбулда белем ала. 1906 елда ачу мөмкинлеге туган басмаханәнәне алар 25 еллап әзерли. Абыйсы Мөхәммәтшакир Рәмиев 1880 елларда энесенә язган хатларында Истанбулдагы полиграфия эшләрен күзәтеп баруын һәм кирәкле җиһазлар, хәреф литералары сатып алу ягын хәстәрләвен үтенә. Рәмиевләр шундый зур тырышлыклар куеп ачылган «Вакыт» басмаханәсенең җитәкчесе итеп бу өлкәдә тәҗрибәгә ия һәм чорының иң абруйлы язучыларыннан берсе булган Фатих Кәримине билгелиләр.

Фатих Кәрими Думага сайланган Мөхәммәтшакир Рәмиевнең урынбасары һәм мөселман депутатларының киңәшчесе дә булып эшли. Соңрак ул Санкт-Петербургка китә һәм Үзәк мөселман иттифак комитетына сайлана. Шул ук вакытта ул «Вакыт» газетасында катгый стильдә язылган сәяси мәкаләләре белән халыкның мәгълүматын арттыруын дәвам итә. «Вакыт» газетасы форма ягыннан үз чорының иң заманча газеталары дәрәҗәсендә торган һәм Россиядәге төрки халыклар арасында иң күп укылган һәм ышанычлы саналган басма орган була. Фатих Кәриминең Балкан сугышларының барышы турындагы мәкаләләре «Вакыт» газетасында һәм «Шура» журналында басылып, соңрак «Истанбул мәктүпләре» исеме астында тупланып бирелә. Кәрими 1917 елның 1 ноябреннән «Яңа вакыт» исемле газета чыгара башлый. Аннан соң аның мәкаләләре Оренбургта басылган «Эшчеләр дөньясы», «Юл» һәм «Сабан» газеталарында дөнья күреп тора. 1919 елның 2 апрелендә «Эшчеләр дөньясы» газетасында «Карт эшче» имзасы белән язылган мәкаләсе [Kerimî , 2001, s. XI–XII; Гайнуллин, 2000, б. 209–210] аеруча әһәмиятле.

«Вакыт» газетасы татарлар арасында гына түгел, башкорт, үзбәк һәм казакъ халыклары арасында да иң күп укылган прогрессив карашлы басма була [Сабитов, 2000, б. 194]. Ф. Кәрими 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр «Вакыт» газетасында хезмәт куя, 1925 елда Мәскәүгә күчә һәм Советлар Союзы халыкларының үзәк нәшриятында эшли. Совет матбугатында аның төрле мәкаләләре басылып тора, шул ук вакытта ул Көнчыгыш университетында да укыта. Фатих Кәрими, Исмәгыйль Гаспралы идеяләрен кабул иткән татар интеллектуалы буларак, һәртөрле мәгариф чараларында катнаша. Фатих Кәрими 1925 елның гыйнварыннан Мәскәүдә яши, Нариманов исемендәге Көнчыгыш университетында төрек телен укыта [Özkan, 1997; Гайнуллин, 2000, б. 211].

Билгеле булганча, XIX йөз – XX йөзнең беренче чиреге арасында Төркестаннан һәм Идел-Урал төбәгеннән бик күп яшьләр, белем алу өчен, Истанбулга җибәрелә. Сәүдә һәм сәнәгать белән шөгыльләнүче бай һөнәрмәндләр тарафыннан финансланган бу яшьләр Истанбулдагы урта уку йортларында белем алалар һәм Госманлы дәүләте белән төрки дөнья арасында үзенчәлекле мәдәни күпер ролен үтиләр. Нәкъ шул яшьләрнең берсе булган Фатих Кәриминең әдәби һәм фикри дөньясын формалаштыруда Истанбул бик мөһим урын алып тора. Монда белем алу чорында ул очраткан күп кенә госманлы зыялылары аның шәхесе формалашуга бик зур йогынтысы ясый. Язмалары һәм эшчәнлеге белән төрки дөньяның бердәмлегенә һәм бөтенлегенә ирешүдә үзенең дә өлешен керткән Фатих Кәрими моны әсәрләрендә дә ача.

Фатих Кәриминең Анатолия географиясе белән бәйләнеше ике төп ноктада формалаша. Шуларның беренчесе – Истанбулдагы чорының иң яхшы мәктәпләреннән берсе булган Мәктәб-е Мөлкия һәм анда белем алу чоры. Икенчесе – «Вакыт» газетасы хәбәрчесе буларак, Госманлы империясе катнашкан Балкан сугышы вакыйгаларын яктыртып язу өчен, икенче тапкыр Истанбулга килүе. Фатих Кәрими сугыш кырларында алган тәэсирләрен «Вакыт» газетасы укучыларына да җиткереп тора.

Татар әдәбиятында тел ягыннан мәхәллилек юнәлешен яклаган Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимовлар кебек язучылардан аермалы буларак, Ф. Кәрими үз әсәрләрен гадиләштерелгән госманлы төрекчәсен кулланып яза. Ф. Кәриминәң телгә карата күзаллавы формалашуда аның гаиләсенең, аеруча этисе Гыйльман Кәриминең, аның тәрбияләнү рәвешенең, чорның сәяси шартлары һәм белем алу үзенчәлекләренең йогынтысы зур була. Аның әсәрләре Истанбул шагыйре һәм язучыларыныкын хәтерләтә.

Сталин чорында Идел-Урал төбәгендәге бик күп татар зыялылары, руханилар һәм хөрмәтле кешеләр эзәрлекләнә һәм үлем җәзасына хөкем ителә. Бу интеллектуалларның берсе булган Фатих Кәрими 1937 елның 4 августында 67 яшендә кулга алына һәм 1937 елның 27 сентябрендә үтерелә [Юзиев һ.б. 1985, б. 350; Шәрәф, 2000, б. 111].

Фатих Кәрими – XX гасыр башында Көнбатыш стилендә үсеш алган татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе. Хәзерге татар әдәбиятының беренче үрнәкләрен дөньяга китергән язучы аеруча наширлек һәм мәгърифәт эшчәнлеге белән алгы планга чыга. Фатих Кәрими әсәрләрен тикшергәндә, Истанбул йогынтысына аерым басым ясарга кирәк. Белем алу өчен Истанбулга килгән яшьләрнең берсе булган әдип, белемлелеге һәм тәрбиялелеге аркасында чорының алдынгы сәнгать һәм сәясәт даирәләре белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. «Фатих Кәрими белән беррәттән Гариф Кәрими, Камил Кәрими, Йосыф Акчура, Мәрьям Якупова, Гөлсем Камалова, Мәрьям Паташева, Рокыя Юнысова да Истанбулга килүчеләр арасында була» [Минһаҗева, 1996, б. 289].

Фатих Кәримигә югарыда телгә алынган даирәләргә үтеп керүдә танылган татар сәясәтчеләре Габдерәшит Ибраһимов һәм Йосыф Акчура мөһим роль уйныйлар. Шулай итеп, Кәриминең Халидә Әдип Ханым, Әхмәт Агаоглу Әнвәр Паша, Сәит Хәлим Паша, Әмрулла Әфәнде, Абдулла Җәүдәт, Зыя Гөкалп, Саты Бей, Мизанҗы Мурат Бәй кебек чорның күренекле шәхесләре белән танышу мөмкинлеге туа [Kerimî , 2001, s. XIII–XIV].

Татар әдәбиятының һәр жанрында диярлек бик күп әсәрләр язган Фатих Кәрими, журналистика һәм мәгариф эшчәнлеге белән беррәттән, хәзерге татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе булып санала. Авторның «Комедия» (1894), «Хөсит бабай» (1895), «Бер шәкерт илә бер студент» (1899), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1900), «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Мирза кызы Фатыйма» (1901) әсәрләрендә искелек белән яңалык арасындагы конфликт мәктәп-мәдрәсә контрасты аркылы чагылдырыла һәм укучыга аңлатыла. Аның әдәби әсәрләренә өстәп, үзе күргән җирләр турында язган «Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырымга сәяхәт» һәм «Истанбул мәктүпләре» әсәрләре ачык, гади теле, стиленең матурлыгы белән татар әдәбиятында мөһим урын тота.

Автор мөрәҗәгать иткән төп темаларның берсе – хатын-кыз иреге, хатын-кызның иҗтимагый тормыштагы урыны, белем ягыннан артталыгы мәсьәләсе. Бу темаларга күп мәртәбәләр мөрәҗәгать итү – татар җәмгыятендә хатын-кызга яхшы белем бирүнең мәҗбүри булырга тиешлегенә ишарә дә. Фатих Кәрими проблемаларны һәм җәмгыятьнең артта калу сәбәпләрен шик астына куеп кына калмый, чишү юллары табу өчен, тәкъдимнәрен дә әйтә.

Ф. Кәрими гарәп, фарсы, рус һәм француз телләрен бик яхшы белгән. Бер яктан, ул әтисе янында үскән вакыттан алып Мәктәб-е Мөлкиягә киткәнче белем алу чорында гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнсә, икенче яктан, Истанбулда уку аңа госманлы һәм француз телләрен тирән өйрәнергә мөмкинлек бирә. Ул Төркиядә мәгариф системасындагы яңалыкларны, яңа ысул белән эшләгән мәктәпләрне, яңа укыту методларын үзләштерә, әдәби даирәләр белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. Бу яктан Фатих Кәри-

ми традицион (мәдрәсә белеме) һәм Көнбатыш стилендәге белемен үстереп, үзендә үзенчәлекле яңа бер интеллектуаль синтез барлыкка китерә.

## Ф. Кәриминең әсәрләре

**Хикәяләре**

1. Комедия (1894).

2. Хөсит бабай (1895).

3. Бер шәкерт илә бер студент (Басылуы – Казан, 1899; язылуы – 1898. Ул Европа фәне һәм цивилизациясе белән Идел-Уралда өстенлек иткән схоластик белем бирү системасын чагыштырып, иске системаны нык тәнкыйтьләгәне өчен чорның кадимчеләре тарафыннан кяферлектә гаепләнә).

4. Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы (Басылуы – Петербург, 1900; язылуы – 1898).

5. Салих бабайның өйләнүе (Оренбург, 1901).

6. Мәрхүм Гыйльман ахунд (Оренбург, 1904).

7. Мирза кызы Фатыйма (Басылуы – 1901 ел. Әсәр 1896 елда язылган дип фаразлана. Әсәрнең темасы белән Исмәгыйль Гаспралының әтисенең мирза кызына белән өйләнүе арасында охшашлык бар).

8. Солтан гыйшкы (1906).

9. Телсез хатын (1906).

10. Гаяш хәлфә (1906).

11. Хыялмы, хакыйкатьме? (Оренбург, 1908) [Kerimî, 2001, s. X].

**Сәяхәтнамәләре**

1. Аурупа сәяхәтнамәсе (Петербург, 1902)

2. Кырымга сәяхәт (Оренбург, 1904)

3. Истанбул мәктүпләре (Оренбург, 1913)

4. Оренбург сәяхәтнамәсе (Абдулла Баттал Таймас Фатих Кәриминең шундый исемле әсәре булуын әйтә. Ләкин бу әсәр дөнья күрми).

**Фәнни хезмәтләре**

1. Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә I (Казан, 1901).

2. Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә II (Казан, 1901).

3. Тарихе әнбия (Казан, 1902; башлангыч мәктәпләр өчен дәреслек буларак әзерләнә).

4. Мөхтәсар тарихе гомуми (Оренбург, 1911).

5. Рәсемле җәграфия дәресләре (Оренбург, 1919).

6. Иҗтимагый тәрбия (Казан, 1924).

**Газета һәм журналларда эшчәнлеге**

1. «Вакыт» газетасы (Оренбург, 1906 ел, 21 февраль).

2. «Шура» журналы (Оренбург, 1908–1917 еллар).

**Әдәбият**

*Гайнуллин М.* Фатих Кәрими // Фатих Кәрими. Шәхесләребез: фәнни-биографик җыентык / Рәиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. Б. 196–212.

*Госманов М.* Фатих Кәрими // Фатих Кәрими. Шәхесләребез: фәнни-биографик җыентык / Рәиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. Б. 7–14.

*Кәрими Ф.* Мәрхүм Гыйльман ахунд. Оренбург: Мөхәммәт Фатих бин Гыйльман Кәримов басмаханәсе. 1904.

*Минһаҗева И.* Кәримиләр тупланмасына кыскача тасвирлама // Фатих Кәрими. Шәхесләребез: фәнни-биографик җыентык / Рәиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. Б. 288–289.

Русско-турецкий словарь / Ş.S. Aylarovu, A.S. Voskoboyu vd. Moskova: Multilingual Yayınları. 1996.

*Сабитов Т.* Фатих ага Кәримов // Фатих Кәрими. Шәхесләребез: фәнни-биографик җыентык / Рәиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. Б. 193–195.

*Сәлахова Э.К.* Миңлебай авылы мулласы Гыйльман хәзрәтнең мәгърифәтчелек осталыгы // Фәнни Татарстан. 2020. № 1 (25). Б. 71–76.

*Шәрәф З.* Фатих Кәрими // Фатих Кәрими. Шәхесләребез: фәнни-биографик җыентык / Рәиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов. Казан: Рухият, 2000. Б. 74–111.

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 2 т. XIX йөз татар әдәбияты / ред.: Н.Г. Юзиев, Я.Г. Абдуллин, Ш.Ш. Абилов, Г.А. Ахунов, М.Н. Гайнуллин, Н.Г. Гыйззәтуллин һ.б.. Казан: Татар. кит. нәшр. 1985.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 644 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр. 1981. 832 б.

*Çaktak C.* Fatih Kerimî'nin Hıyal Mı? Hakıykat Mi? ve Andan Bundan Eserleri Üzerinde Dil ve Üslup İncelemesi, Gazi Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü, Yayınlanmamış Doktora Tezi, Ankara, 2014.

*Çaktak C.* İsmail Gaspıralı ve Fatih Kerimî'nin Ceditçilik Faaliyetleri // Manisa Celal Bayar Üniversitesi I. Uluslararası Demirci Sempozyumu (12–14 Ekim 2017), I. Uluslararası Demirci Sempozyumu Bildiriler Kitabı. Manisa, 2017. S. 254–259,

*Çaktak C.* Fatih Kerimî'nin Mirza Kızı Fatıyma, Şakirt İle Student Ve Nuretdin Hoca Hikayelerinde Ele Alınan Sosyal Temalar // Gazi Türkiyat. 2018. Sayı 22, S. 39–54.

*Çaktak C.* Tatar Ceditçi Fatih Kerimî'nin Az Bilinen Yönleri // Balıkesir Üniversitesi, Uluslararası Türk Kültürü ve Medeniyeti Kongresi Tam Metin Bildiri Kitabı (TÜRKKÜM 2018). 2018. S. 290–296.

*Çaktak C.* Fatih Kerimî'nin Eserlerinde Kullandığı Dil Üzerine// Eskişehir Osmangazi Üniversitesi, X. Uluslararası Dünya Dili Türkçe Sempozyumu Bildiri Kitabı (16–19 Ekim 2018). 2018. S. 430–437.

*Çaktak C.* Fatih Kerimî'nin 'Ondan Bundan' Adlı Eserinin Fikri Yapısı // Uluslararası Sosyal Araştırmalar Dergisi The Journal of International Social Research. 2019. C. 12, S. 66. S. 36–46.

*Çakmak C.* Tatar Maarif Hayatının Öncüsü: Gılman Kerimi (1841–1902) // Türk Dünyası Dil ve Edebiyat Dergisi. 2020. Sayı 49. S. 87–100.

*Çakmak C.* Ceditçilik Faaliyetlerinde Bir Ömür: Fatih Kerimî // Kardeş Kalemler. 2020. Nisan, Sayı 160. S. 23–34.

*Çakmak C.* Tatar Ceditçi Gılman Kerimi ve Vasiyetnamesi // Pamukkale Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü Dergisi. 2020. Sayı 40. S. 137–147.

*Kerimî F.* İstanbul Mektupları / Hazırlayan: Fazıl Gökçek. İstanbul: Çağrı Yayınları. 2001.

*Kerimî F.* Mirza Kızı Fatıyma Seçme Eserler / Hazırlayan: Cihan Çakmak. Ankara: Gece Kitaplığı Yayınları, 2016.

*Özkan F.* «Kazan Tatarları» // Yeni Türkiye. 1997. Özel Sayı 3, 16. S. 1446–1451.

*Özkan F.* «Fatih Kerimî'nin Türk Kadınına Bakışı» // Erciyes Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü Dergisi. 2006. 20. S. 101–108.

*Saray M.* Gaspıralı İsmail Bey'den Atatürk'e Türk Dünyasında Dil ve Kültür Birliği. Ankara: Türk Dil Kurumu Yayınları, 2008.

***Җиһан Чакмак,*** *Doç. Dr.,*
*Маниса Җәлал Баяр Университеты (Төркия)*
*педагогика факультетының төрек телен укыту*
*методикасы кафедрасы укытучысы*

УДК 821.512.145

***Ф.И. Габидуллина***

# ЗӨЛФӘТ ИҖАТЫНДА РУХИ АЗАТЛЫК ИДЕЯСЕ
## («Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы мисалында)

Цель исследования – определить особенности отражения идеи духовной свободы в творчестве Зульфата на примере поэмы «В сердцах бессмертный дастан» (1980). Научная новизна заключается в выявлении указанной проблемы через призму общечеловеческих ценностей. Особое внимание уделяется идейно-эстетическим особенностям, богатству изобразительных средств анализируемой поэмы. В статье проанализированы сюжетная линия и общая композиция поэмы.

**Ключевые слова:** татарская литература, Зульфат, поэма, эпоха, жанр, прием, идея.

The purpose of the study is to define the peculiarities of reflecting the idea of spiritual freedom in Zulfat's works and especially in his poem «The immortal dastan in the hearts» (1980). The scientific novelty is in revealing of this problem through the prism of common human values. Special attention is paid to ideological and aesthetic peculiarities, wide range of describing means in the poem studied. The article analyzes the storyline and general composition of the poem.

**Keywords:** tatar literature, Zulfat, poem, epoch, genre, method, idea.

XX гасырның икенче яртысында үзенең тирән лиризм белән сугарылган шигырьләре, фәлсәфи эчтәлекле һәм уңышлы гомумиләштерүләргә ия җитди уйлануларга этәрүче поэма-балладалары белән киң танылу алган, шигъриятне яшәү мәгънәсе буларак кабул иткән әдипләрнең берсе – Зөлфәт (Дөлфәт Маликов, 1947–2007). Ул 1970 еллар башында поэзиягә килә һәм тиз арада гаҗәеп халыкчан, аһәңле теле, Такташ һәм Туфаннардан килүче традицияләрне дәвам итүе һәм сүз-сурәт тудыруның яңадан-яңа алым-формаларына мөрәҗәгать итүе белән игътибарны җәлеп итә. Аның «Язмышлар ярында» (1971) җыентыгына Х. Туфан мондый бәя бирә: «Гаҗәп тирән, якты, халык һәм ил турындагы зирәк, акыллы, кайнар, тормышка тирән мәхәббәт белән сугарылган шигырьләр...» [Туфан, б. 4] Шагыйрь иҗат гомерендә әлеге югары бәягә тугры калып иҗат итә, шигърияте белән тарихның аерым сәхифәләрен күз алдына бастыра, халыкның шатлык-борчуларын, теләк-омтылышларын чагылдырып, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атып яши. Алдагы елларда бер-бер артлы шигъри җыентыклары басылып чыга: «Утлы бозлар» (1978), «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995), «Йөрәгемне былбыл чакты» (1999), «Ходай сулышы» (2007).

Тәҗрибәсе арткан саен әдипнең сәнгати фикерләве тирәнәя, фәлсәфилек арта, алгы планга кеше һәм табигать, яшәү һәм үлем,

матурлык һәм кыргыйлык, мәхәббәт һәм нәфрәт, хакыйкать һәм ялган, кешелек һәм галәм һ.б. темалар чыга. Чынбарлыкны бөтен төрлелегендә чагылдыру максатында Зөлфәт халык традицияләренә таяна, мифологиядә һәм фольклорда урын алган образларга, сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Ул файдаланган шигъри алымнар арасында образ-символлар, метафорик сурәтләр аеруча киң урын алып, алар авторның хис-кичерешләрен, фикер-карашларын баетып һәм үстереп җибәрә. Шагыйрьнең һәр китабы күтәп алына, җитди бәхәсләргә, фикер алышуларга китерә. Зөлфәт тиз арада чор поэзиясен әйдәп баручыларның берсе булып танылa һәм иҗаты киң катлам укучыларда теләктәшлек таба. Шагыйрьнең гражданлык һәм фәлсәфи лирикасы кеше бәхете, милләт язмышы, галәм сакланышы кебек җитди мәсьәләләрне үз эченә алуы белән киң яңгыраш ала. Ул яшәп килгән системаның кеше иреген чикләүгә юнәлтелгән эш-гамәлләрен еш кына эзоп теле аша чагылдыра. Иҗаты белән укучысын гасыр ахырындагы үзгәртеп коруларга әзерли.

Зөлфәт иҗатына үзе исән чакта һәм вафатыннан соң да әдәбият белгечләре еш мөрәҗәгать итә, чөнки аның әсәрләрендә поэзиянең үсеш тенденцияләрен ачуга ачкыч табыла, эзләнүләрнең юнәлеше билгеләнә. Төрле елларда шагыйрьнең яңа китабына кереш сүз буларак яисә аларга бәяләмә төсендә, соңрак исә иҗат үзенчәлекләрен ачу максатында Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Н. Нәҗми, Р. Гаташ, М. Әгъләмов, Т. Галиуллин, Ф. Сафин, Д. Заһидуллина, Н. Йосыпова һ.б. язмалары дөнья күрә. Т. Галиуллин шагыйрьнең романтик сурәтлелекне яратып куллануын, шул максатта мифларны, легенда-риваятьләрне иркен файдалануын аерып күрсәтә. Җитди иҗат үзенчәлеген билгеләп, болай дип яза: «...ерак дәвердә туып, безнең чорда да нәфисләгән, сафлыгын югалтмаган халык җыры, халык моңы белән соклана, шуннан ямь, илһам ала...» [Галиуллин, 2002, б. 150]. Бу исә шигырьләренең тел-стиль ягыннан камиллеген үстерә. Д. Заһидуллина фикеренчә, Зөлфәтнең 1970–1980 еллардагы иҗатында «фикер көче һәрчак хисләрнең хаотик-тәртипсез урнашуы, аларның бер чиктән икенчесенә ташланып торуы белән билгеләнә (...) Шагыйрьнең язу рәвеше татар әдәбиятында экспрессионизм агымын үстерә» [Заһидуллина, б. 145]. Әлеге үзенчәлек, чор образын тудыру өчен, шагыйрьнең гаделлек, хакыйкать өчен көрәшне алга чыгаруында, эмоциональ тәэсирлелекне арттыру алымнарына, шартлы формаларга, мифологик сюжетларга мөрәҗәгать итүендә чагылыш таба. Галимә фикеренчә, болар барысы да укучыга хисси тәэсир итү көчен арттыруга хезмәт итә [Заһидуллина, б. 152]. Әдәби мирасын җентекле тикшереп, иҗат портретын эшләгән Н. Йосыпова: «Зөлфәт иҗатының үзенчәлеге һәм новаторлыгы, һичшиксез, шигъри стиленә тоташа: ул символик-метафорик образ-сурәтләрне төрле мәгънә төсмерләренә баетып кына калмый, шулар аша укучыны тәэсирләндерү максатын куя, экспрессия алымына килә», – дип яза [Йосыпова, 2019, б. 250]. Шуның белән бергә, шагыйрьнең экспериментлар белән мавыгуга

караганда, традицияләргә таянуын, халык авыз иҗатыннан килә торган романтик сурәтлелеккә өстенлек бирүен ассызыклап үтә.

Зөлфәт иҗатында лиро-эпик жанрдагы әсәрләр үзгә бер катлам тәшкил итә. Аның «Йөрәкләрдә – үлмәс дастан», «Иске Казан карлыгачы», «Җирдән кайтышлый» кебек поэмалары, «Тимерче турында баллада», «Гармунчы турында баллада», «Кара күбәләк», «Ике ат турында баллада», «Тау яшене», «Фатыйма» кебек әсәрләре күтәрелгән мәсьәләләре, мәгънәви тирәнлекләре һәм әдәби-эстетик эшләнешләре белән татар шигъриятендә лаеклы урын алып, әлеге жанрны үстерүгә, баетуга җитди өлеш кертә.

Зөлфәтнең сәнгати эзләнүләренең җитди бер чагылышы булып «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы тора. Аны тикшереп бәяләү, Зөлфәтнең сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен ачыклау белән бергә, «төрле чорларда яшәгән әдипләр иҗатындагы милли һәм гомумкешелек сыйфатлары чагылышын билгеләү» [Закирзянов, с. 86] мөмкинлеге бирә. Сигез бүлектән торган әсәр кешелек дөньясы, адәм затының яшәү рәвеше, галәмне саклау һәм яклау юлында таяныч булган әхлакый кыйммәтләргә багышлана. Аның нигезендә исә кешенең хыялы, матур омтылышлары, өмет-ышанычы ята. Алар беренче чиратта иҗатта чагылыш табып, бик күпләрнең күңелендә урын ала. Бу урында шуны да искәртеп китик, Зөлфәт һәртөр иҗатны Аллаһтан иңдерелгән сыйфат дип саный һәм аның башлангыч нигезе булган җыр-мәкальләргә, экият-дастаннарга сокланып карый, аларны иҗат итүчеләр алдында баш ия. Шагыйрьнең «Чытырманда былбыл сайрый» язмасы шагыйрь, шигърият, аның бурыч-вазифалары, иҗтимагый кыйммәте турында тулы бер трактат булып тора. Ул болай дип яза: «Шигырь ул – миңа калса, ургылып болганган җиһан өермәсеннән капшап табып алынып, камил тәртипкә салынган, һични какшатмас ритмга салынган, бердәнбер аһәңгә буйсындырылган мәҗүси, кайнар сүзләр яңгырашы. Хәер, һәр шагыйрь моны үзенчә аңлата алыр иде. (...) Яман кеше хакында: «Имансыз!» дип түгел, «Шигырьсез!» дип хөкем чыгарырга кирәктер... (...) Асыл шигърияттән йөз чөергән җәмгыятьтә генә җинаятьчеләр күбәя, гарипләр арта» [Зөлфәт, б. 10–11]. Бу фикерләр аның байтак шигырь-поэмаларында урын ала. «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасында әсәрнең исеменә – көчле позициягә чыгарылган «дастан» төшенчәсе ике мәгънәдә килә: берсе – халык иҗатының бер жанры буларак, җәмгыятьтә булган җитди вакыйгалар уңаеннан иҗат ителгән лиро-эпик әсәр. Текстта ул автор иҗат иткән легенда белән дә ныгытыла. Икенчесе – иҗатка этәргән Хыял, Өмет, Омтылыш буларак, кеше Акылына ышану билгесе. Зөлфәт «дастан» төшенчәсенә «Тамыр гөлләре» (1978) шигырендә дә мөрәҗәгать итә. Анда сүз тайгада киселгән агачларның төп-тамырлары турында бара. *Яна тамырларда алтын дастан, / Дастаннарда – кавем тарихы...* дип, әлеге жанрдагы әсәрләрнең халык тарихын саклаудагы ролен ача.

«Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы язылган вакыт – совет җәмгыятендә торгынлык хөкем сөреп, коммунистик идеология

һәртөрле ирек төшенчәсенә киртә куеп килгән дәвер. Зөлфәт әнә шундый шартларда да рухи азатлык, милләт язмышы мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә, үзенең гражданлык позициясен саклап кала. Күп кенә шигырь-поэмаларында яшәп килгән системадан ризасызлык, үзгәрешләрнең киләчәгенә ышаныч читләтеп, эзоп теле аша яңгырый. Әсәр «үтә шартлы, экспрессив алымнарга таянып, үткән белән киләчәк, Җир белән Күк арасында якынлык эзләүгә корылган» [Галиуллин, 2011, б. 203]. Поэмада бүгенгебезгә янаган куркыныч шартлы-символик образлар ярдәмендә ачыла. Шагыйрь тормыш хакыйкатен «еш кына шартлы формалар аша җиткерә [Заһидуллина, б. 151]. Без тикшерә торган поэманың романтик табигате үк аның хыял дөньясы, бүгенгегә үткән-бүгенге-киләчәк бәйләнешендә килү кебек сыйфатлар белән бәйлелеген күрсәтә. Әсәрнең эпиграфына «Джанни Родари истәлегенә» дигән сүзләр чыгарылган. Аның италияле атаклы әкиятче булуы ук күп нәрсә сөйли. «Кереш» ролен үтәүче беренче бүлектә билгеләп үтелгәнчә, авторны гомере буе айдагы Зөһрә сылу һәм Шәһрезадә, яшәрткеч су һәм патша дәрәҗәсенә ирешкән көтүче, очкыч-тәлинкә һәм ишекне ачтыручы серле Сим-Сим һ.б. турындагы әкиятләр озата бара. Нәкъ менә аларда кешенең көче һәм матурлыгы, батырлыгы һәм гаделлеге, хыялы һәм өмете чагыла, шулар кешене кеше итә, рухын сафландыра, матурлыкка, сафлык-чисталыкка илтә. Шуңа да поэма дәвамында кабатланачак сүзләр яңгырый: *Әкият хисең саумы, кешем, җанда?* Әлеге борчулы авазның сәбәбе бар – *Әкиятне җую – кешелекне җую.* Шул рәвешле автор укучыны төп мәсьәләгә алып килә – җирдә явызлык баш калкыта, дөньяның төрле почмакларында кан-яшь түгелә. Ул җавап эзләп «Чипполино», «Һөнәрчеләр шәһәре» кебек әкиятләр авторы Д Родарига мөрәҗәгать итә. Аның җавабы бер: *Юк, бөекләр түгел, бүген Җиргә / Игелекле җаннар кирәклерәк...* Авторның идеалы булган яшәеш моделенең бер сыйфаты табыла. Моның нигезен бала вакытта тыңлаган әкиятләр тәшкил итә. Әмма бүгенгебездә әкият кысрыклана, аның урынын фән-техника, яңа технологияләр, роботлар ала. Йөрәген йон басканнарның фикере дә еш яңгырый – әкияткә ышанып яшәү нигә кирәк? Боларга бәйле Зөлфәт бала күңелендәге *матурлык* тойгысын саклауны алга чыгара. Ә бит *Һәр сугышның башы / Һәр дәвердә бер үк төрле икән.* Сугышлар әкият китапларын яндырудан башлана, әкият кызының яндырылуы ул – явызлык башлангычы, кешелекнең үз-үзен юк итү юлы, шуны онытмасак иде, дип кисәтә автор.

Яшәешнең кыргый күренешләренә каршы торырдай идеал эзләп, автор Тукай шәхесенә килә. Халык бәхете өчен җанын фида кылган бөек шагыйрь иҗаты үз чорында да, бүген дә дога булып яңгырый. Зөлфәт аның күп төрле сыйфатлары арасыннан *хаклыкка*, гаделлеккә хезмәт итүен аерып чыгара:

*Һәр шигырем минем – утлы догам,*
*Шуның өчен җиргә туганмын –*

*Киләчәкнең «Амин!» дигәненә*
*Туры китер, Хаклык, Догамны!*

Тормыштагы батырлыкның нигезе бала чакта тыңлаган әкиятләрдән килә. Әнә Морис Эрцог пигындагы упкыннан егылып һәлак булган альпинист татар кызы Зәйтүнә Даутова язмышы да безне шунда илтә. Аның гамәле кеше мөмкинлекләрен раслау, үз-үзен җиңү белән бәйле. Әлеге бүлекнең «Биеклек» дип аталуы да биеклеккә ишарә итә: *И биеклек! Табынганым минем! Гүзәл дә син, горур, дәһшәтле дә!* Автор милләттәше белән чиксез горурлана, чөнки аның биеклеккә омтылышы – ул *бу халыкның күтәрелү хисе!* Шул рәвешле альпинист кыз турындагы фикер халык язмышы, аның рухи азатлыкка омтылышы булып үсә. Һәм автор Зәйтүнә исеменнән киләчәк буынга дәшә:

*Юк, үлемем түгел – җиңүем бу,*
*Сөюем бу! Һәм мин соңгы чиктә*
*Дәшәм сезгә: – Газиз гомерләрне*
*Багышлагыз бары биеклеккә!*

Ирек хисе кешелеккә генә түгел, барлык табигать дөньясына хас. Алдагы бүлектә циркта яшәүче арыслан язмышы шуның бер мисалы булып тора. Әлеге арыслан исеменнән сөйләнгән фаҗигале тарих үзе үк әкият булып яңгырый һәм анда ирекка омтылышның мәңгелек булуы чагыла. «Поэмада әкият символы – Алты бархан ыруы турындагы легенда – халык язмышын, бүгенге һәм киләчәк турындагы уйлануларны җиткерүче булып төгәлләшә, вакыйгалар бәйләме еш кына лирик кичерешләр, уйланулар белән аралаша» [Йосыпова, 2011, б. 98]. Әлеге легенданың автор тарафыннан иҗат ителүе дә яңа миф чагылышы булып, поэманың төп идеясе белән турыдан-туры бәйле. Алты бархан ыруының «бер Оазис, бер Зәңгәр Күк һәм бер Чишмә» буенда дөньяга аваз салган Арыслан Бөек Теш һәм бөек Тырнак ярдәмендә *Бөек Ыру, Бөек Чабыш* өчен яратылган. Кешеләр аны читлеккә илтеп ябып, таяк һәм камчы белән үзләренә буйсындырган. Әмма *Хыянәтче кулларыннан / үтерелгән дастан булып* иректе даласы төшләренә керә, онытылмый, җанын яралый. Ерак бабаларыннан килгән ирек авазы йогынтысында Арыслан читлектә кала алмаячагын аңлый. Бу урында патриот-шагыйрь М. Җәлил сүзләре белән аваздашлык чагыла: *Чаян чага үзен соңгы чиктә, / Бөркет ярдан түбән ташлана.* Арыслан үзенең үлемгә дучар ителәчәген белгән хәлдә читлек хуҗасына каршы чыга: *Минем кыргый, минем бөек әкиятне / Үтерде ул – / Минем авыз – сәхнә иде, / һәм сәхнәне хәзер ябам.* Кыргый даланы – бөек әкиятне хәтерләткән ирек хисе әнә шулай бәреп чыга. Авторның әлеге әкияте халкына эндәшүе, күңелендәге ирек хисен барлавы, шуңа омтылышы һәм өмете булып яңгырый һәм ул халык бәхете өчен «читлекне» җимереп чыгарга омтылган, шул юлда һәлак булган бөек улларыбыз-кызларыбыз турында уйланырга этәрә.

Кешелек җәмгыяте Җир шарындагы тынычлыкны бары үзе генә саклап кала ала. Автор аны образлы итеп әкиятне чакыру дип атый: *Тик әйт кенә син тылсымлы сүзне: / «Борын-борын заманда...», – диеп...* Бу сүзләрдә яшәеш көче, тереклек рухы, ирек авазы – барысы да бар. Әмма ул яклауга һәм саклауга мохтаҗ булып, һәркемнең изге бурычы һәм вазифасы булып тора. Әгәр инде әлеге тылсымлы сүзләр оныттылса, *Йокы басар, ерак йолдызларны... / Бу – мәңгелек йокы.* Поэманың «Сак бул!» дигән соңгы бүлеге авторның кисәтүе булып тора. Ул юкка түгел, явызлык дөньясына яшь буын тартылу очраклары еш очрый. Ә бит явызлыкның төсе дә, милләте дә юк. Аңа каршы кешелек дөньясы үзенең *намусын* куйса гына, Җир-Әкиятне бу афәттән саклап калып була. Шуңа да автор бөтен кешелеккә аваз сала: *Сак бул, Намус!* Куркынычның көчле һәр зур булуы кабатлану аша кат-кат белдерелә: *Ау сезоны бара – әкиятнең / Аркасына пычак кем тери?* Әмма күңелдә өмет хисе яши, ул бар, ул исән:

*Канатлы ат чаба җир буйлатып –*
*Азат җан ул – Хыял һәм Өмет!*
*Йөрәгендә – үлмәс дастан – Бәхет!*
*Ул булырга тиеш мәңгелек...*

Шул рәвешле, поэмада чынбарлыктагы ямьсезлек, явызлык күренешләреннән арыну омтылышы авторны кешелек башлангычына, әкиятләрдә урын алган идеалларга китерә. Аерым бүлекләрдә әкиятләрдә якланган һәм сакланган сыйфатлар рәвешендә игелек, хаклык, матурлык, мәхәббәт, намус, омтылыш, ирек, сафлык аерып чыгарыла. Текстта урын алган мифик күзаллаулар, автор тәкъдим иткән легенда әлеге каршылыкны тагы да тирәнәйтә һәм хәл итү юлының рухи азатлык, рухи матурлык белән бәйлелеген ача. Поэмадагы кабатлаулар, символлар, әдәби детальләр автор идеясен бөтен тирәнлегендә һәм хис-кичереш аша укучыга җиткерүгә хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Галиуллин Т.Н.* Тынчу елларның тынгысыз шигърияте // Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 185–216.

*Галиуллин Т.Н.* Шигърият бачкычлары: Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.

*Закирзянов А.М.* Современное татарское литературоведение: достижения, проблемы и перспективы развития // Национальные литературы на современном этапе: научные концепции и гипотезы: круглый стол, посвященный 80-летию создания Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (11 сентября 2019 г.): сб. статей. Вып.1. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 80–88.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–80 нче еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Зөлфәт.* Чытырманда былбыл сайрый // Ике урман арасы: эссе, шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. Б. 7–22.

*Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә символлар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. 120 б.

*Йосыпова Н.М.* Зөлфәт // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 7 т.: 1956–1985 еллар [фәнни мөх. Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов]. Казан: Фолиант, 2019. Б. 248–269.

*Туфан Х.* Кереш сүз // Зөлфәт. Язмышлар ярында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. Б. 3–6.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Алабуга институты доценты*

УДК 821.512.145

***Л.Р. Надыршина***

## РӘМИС АЙМӘТНЕҢ ИҖАТ ДӨНЬЯСЫ

Статья посвящена анализу творчества Рамиса Аймета. Автором выделены ключевые особенности лирики поэта: индивидуализм, оценка бытия через призму дисгармонического мировосприятия лирического героя, доминирование эмоционально-психологического и философского начал, ассоциативность. В статье проанализированы наиболее частотные мотивы и образы, прослежена трансформация образа лирического героя в стихах поэта.

**Ключевые слова:** Рамис Аймет, поэзия, художественный мир, лирический герой, поэтика.

The article is devoted to the analysis of Ramis Aimet's creativity. The author highlights the key features of the poet's lyrics: individualism, assessment of being through the prism of the lyric hero's disharomonic worldview, the dominance of emotional-psychological and philosophical principles, associativity. The article analyzes the most frequent motives and images, traces the transformation of the image of the lyric hero in the poet's poems.

**Key words:** Ramis Aimet, poetry, art world, lyric hero, poetics.

1990 еллар азагында шигъри мәйданга килгән Рәмис Аймәт укучы игътибарына тәкъдим иткән беренче әсәрләреннән үк үзен сентименталь кичерешләрне фәлсәфә белән төреп биргән үзенчәлекле шагыйрь итеп таныта. Психологик-эмоциональ киеренкелек, индивидуальлек, яшәешне лирик «мин»нең дисгармоник күңел дөньясы яктылыгында бәяләү – шагыйрь иҗатын аерып торган төп үзенчәлекләр. Р. Аймәт «җанында мең-миллион хисси тирбәлешләр тулы кешене сурәтләү объекты ясый. Бу сыйфат аның лирик героен үзенчәлекле, башкаларга охшамаган, беркемне дә кабатламаган, бөтен кешелекнең кайгы-шатлыгын үз күңеле аша уздырырга сәләтле шәхескә әйләндерә» [Заһидуллина, б. 32]. Шуңа мөнәсәбәтле, лирик герой экзистенциаль кичерешләр хозурында яши, шушы фәлсәфә кысаларында укылган яшәү – үлем, өмет – өметсезлек бинар оппозицияләре шигырьләрдә сурәтләнгән дөнья үзәгендә тора, яшәешнең караңгылыгы, чарасызлык, төшенкелек, вакыт агышы, үлем көтү һәм башка мотивлар шагыйрь иҗатын иңләп уза. Әсәрләрдә иҗат – газап («Шагыйрь», 1998; «Ритм», 1997), яшәү – җәза («Мин әле тумаган», 1998), яшәү – сагыш («Җәйнең соңгы җыры», 1998; «Сагыш», 1996) кебек экзистенциаль тәңгәллекләр сызлануның төп сәбәбенә әйләнә, яшәеш газабын җаны аша үткәрергә сәләтле лирик геройның күңел халәте кабатлаулар, көчәйтү, градация кебек алымнар ярдәмендә тагын да тирәнәйтелә:

*Җанда, канда –*
*сагыш,*
*сагыш,*
*сагыш...*
*Адым саен сагыш күмелгән.*
*Бу дөньяга яралганмын, ахры,*
*Сагыш учагының көленнән* [Аймәт, б. 79].

Ике гасыр чиге милли сүз сәнгатендә үсеш алган шәхсилек, индивидуальлекнең бер үрнәге буларак, Р. Аймәт шигырьләрендә лирик «мин»нең үз асылын эзләве ассызыклана, «шигырьләрдә ике образ – «мин» һәм ул диалог корырга омтылган яшәеш – үзәктә тора» [Загидуллина, с. 104]. Шагыйрь иҗатындагы бу үзенчәлеккә күренекле әдип Р. Фәйзуллин да игътибар итә, аның «байтак шигырьләрендә Дөнья һәм Мин (бәлки әле Мин һәм Дөньядыр?) төп лейтмотив булып бара» [Фәйзуллин, б. 141], дип билгели. Шушы юнәлештә иҗат ителгән «АкроМИН» (1997), «Мин әле тумаган» (1998), «Автопортрет», «Мәгънә эзлим», «Мин җирләргә төштем» кебек шигырьләрдә укучы лирик геройның иҗтимагый яшәеш кануннарына гына сыешмаган җан хәрәкәтенә, фәлсәфи-метафизик уйлануларына төшенә (*Сынса да канатлар, мин сыймыйм дөньяга, – / Күктә дә, җирдә дә мин яшим* [Аймәт, 2000, б. 13]; *Дөньяларның кайсы читендә мин, / Вакытларның кайсы чигендә, / Гомеремнең кайсы мизгелендә, / Хыялымның кайсы күгендә / Яшим икән?* [Аймәт, 2004, б. 79]), кешедәге илаһи башлангыч турындагы романтик күзаллауларга тап була *(Мин әле Мәңгелек иренендә / Бөрегә төйнәлгән бер Дога* [Аймәт, 2000, б. 73]), шул ук вакытта шәхеснең галәм каршында көчсезлеге, язмыш-тәкъдирне үзгәртеп булмавы турындагы фаталистик нәтиҗә дә сиземләнә:

*...Мин әле тумаган, ә инде*
*Күкләрдә укыйлар җеназа* [Аймәт, 2000, б. 73].

Р. Аймәтнең лирик герое үзен җәмгыятьтән аерып куя, гавам яшәешен хасил иткән матди-көндәлек кыйммәтләрдән азат булып, җир кысаларына сыешмаган рухи яшәешкә омтылу күңел каршылыгына, рухи бәргәләнүләргә, җанны талкыган канәгатьсезлек хисенә китерә. Мондый психологик халәт ялгызлык һәм читләшү мотивлары белән янәшә куела. Гомумән, ялгызлык категориясе Р. Аймәт иҗатын үтәли иңләп уза, бу – поэтик текстларның исемнәрендә дә күренә («Ялгызак», «Ялгызлык», «Ялгыз сандугач», «Соңгы яфрак»), еш кына ул иҗат мотивы белән үрелеп китә, мондый очракта лирик «мин» һәм шагыйрь шәхесе арасында чик югала, ялгызлык газаплы күңел дөньясының аерылгысыз өлеше буларак кабул ителә:

*Мин нәрсә ул?*
*Үтә гомерем*
*Бер ялгыз төнне куып.*

*Таңнарымны каршы алам*
*Шигъремә башым куеп...* [Аймәт, 2000, б. 53].

Эчтәлеге лирик субъектның дөньядан, җәмгыятьтән ваз кичү идеясе, протестыннан гыйбарәт шигырьләрдә («Эзләмәгез мине!», 2000; «Җаным бикле бүген...», 1994; «Хушлашу») читләшү мотивы әйдәп бара, кешелеккә үпкә – хис катламының эчтәлеген хасил итә. Шушы юнәлештә иҗат ителгән «Читләтелү» (2003) әсәрендә шагыйрь әлеге мотивны текстта махсус аерымлап куя, «чит» сүзен уйнату нәтиҗәсендә эмоциональ яңгыраш көчәеп, шигырьнең һәр строфасыннан үпкә-әрнү, ачыну саркый:

*Этәләр һаман ЧИТлеккә –*
*Чоңгыл-тормыш ЧИТенә.*
*ЧИТен ашап, ЧИТен киеп,*
*Йөрәк һаман кителә.*
    *ЧИТәннән ЧИк-кирТә үреп,*
    *ЧИТләшәм дөньясыннан.*
    *Мин – дөньяга, дөнья миңа*
    *Әйтерсең сыймый сыман* [Аймәт, 2016, б. 165].

Лирик геройның моң-сагыш, әрнү, газаплану белән сугарылган экзистенциаль халәте көз, төн хронотоплары, ай, төш, йокысызлык, тынлык кебек символ югарылыгына күтәрелгән образлар ярдәмендә көчәйтелә, автор каләменә хас үзенчәлекле ассоциатив бәйләнешләр барлыкка килә:

*Әрвах Көнгә Төн каберме әллә,*
*Соң сулышы – гомер чигеме?*
*Үз-үзеннән курыккандай, хәтта*
*Караңгылык куя чигенеп.*
    *Агам, агам...*
        *Кая китте Көнем? –*
    *Болытларга кушылып актымы?*
    Тама, тама...
        *Газиз Көн җаныннан*
    *Качып калган соңгы яктылык...* [Аймәт, 2000, б. 91].

Сурәтләнгән дөньяның, хис-кичерешләрнең еш кына капма-каршы чикләрдә тирбәлүе эмоциональ-психологик яңгырашны катлауландыра, ак – кара, көн – төн, үткән – киләчәк, хыял – чынбарлык һәм шулардан оешкан җиһан – лирик «мин» оппозициясе лирик субъектның катлаулы күңел халәтен үзгәрештә күрсәтә. Р. Аймәтнең лирик герое күптөрле хисләр дулкынында яши: ул әле төшенкелеккә бирелә, әле күкләргә омтыла, ярсулы хисләр хозурына бирелә, я булмаса яңадан өметсезлек, билгесезлек упкынында югала. Шушы каршылыклы психологик хәрәкәт шигырьләрдә үзенчәлекле кичерешләр динамикасын нигезли, укучыны да шушы хисләр дәрьясында яшәргә мәҗбүр итә:

*Очасы иде лә – канатлар киселгән,*
*Куырылган канаттан кан тама.*
*Күкләргә карый да, үрелеп-үрелеп,*
*Җан яна...*
*Кемгәдер – тантана...* <...>
*Убылмый таулар да, болытлар – яңгырсыз,*
*Мең тетрәү йөрәктә, мең яшен.*
*Сынса да канатлар, мин сыймыйм дөньяга,–*
*Күктә дә, җирдә дә мин яшим* [Аймәт, 2000, б. 12–13].

Кагыйдә буларак, әсәрләрнең соңгы строфаларында сызлану хиссиятенең көчле позициядә килүе геройның җан газабын көчәйтә, драматизмны тирәнәйтә, ашкыну-омтылышларның юкка булуын тоемларга мөмкинлек бирә, әсәрне шомлы-шөбһәле укылышка көйли. Күңел төпкелендәге хәсрәтле-газаплы уйланулар дулкынында шагыйрьнең лирик герое яшәеш хакыйкатенә төшенә, кешелеккә бәя-мөнәсәбәтен җиткерә, аның кичерешләре, шәхси кысалардан чыгып, гомумкешелеккә юнәлдерелгән фәлсәфи гамьнәр булып формалаша. Әйтик, «Кошмы? Колмы?» шигырендә лирик геройны борчыган төп проблема әсәрнең исемендә үк калкытыла: шигырьнең кеше җанының асылын ачу рухында иҗат ителгән булуына ишарә ителә. Кош образында модификацияләнгән ирек һәм һәм аңа каршы куелган коллык категорияләре төп структур калыпны нигезли: кошлар кавеменнән (димәк, ирекле) булуын аңлап, Ирекkә, биеклеккә – рухи кыйммәтләр зурланган яшәешкә омтылган лирик геройның өметхыяллары чынбарлыкка бәрелеп чәлпәрәмә килә:

*Кошмы?!*
*Кошмы?!*
*Коллар нәселеннән мин, –*
*Әйләнде лә җаным өрәккә!*
*Әйләнде лә җаным өрәккә!*
*Ялварыплар күкләремә баксам,*
*Кыйгак-кыйгак кына ла канат каксам, –*
*Богау чыңы зеңли йөрәктә,*
*Богау чыңы зеңли йөрәктә...* [Аймәт, 2000, б. 11].

Нәтиҗәдә, риторик шәкелдә формалашкан ачынулы уйланулар, кабатлаулар хис дәрәҗәсен көчәйтүче чарага әйләнә, лирик «мин»нең үзен кавем-нәсел белән бәйләп куюы гомумкешелек хәятенә ишарә итә.

«Соңгы өмет» шигырендә очу мотивы шәкелендә үстерелгән ирек төшенчәсе *(Ирек – канат! / Без канатсыз калдык)* турыдан-туры милли контекстта укыла, тарих, хәтер проблемалары белән бер җепкә тезелеп, ирексезлекнең ничә гасырлар милләт бәгырен телгәләгән сыкрау булуын ачыкларга мөмкинлек бирә:

*...Күптән онытылган Ирек хисе*
*Бертуктамый уйный канымда.*

*Бабамнарның әйтер сүзе булып*
*Оран сала көн-төн җанымда.*
*Оран сала...*
*Мәрткә китте дисәм,*
*Кайта кабат, кайта терелеп.*
*Күзләремә минем Ирек бага,*
*Җиде бабам аша үрелеп* [Аймәт, 2016, б. 163–164].

Гомумән, Р. Аймәтнең яңа гасырда иҗат ителгән шигырьләрендә шәхси кичерешләрне гомумкешелек киңлегенә чыгару омтылышы тагын да көчәя, лирик геройның җәмгыятькә, яшәешкә бәясе милли эчтәлекнең беренче планга чыгуына китерә, туган тел язмышы («Туган телем», «Татар каены»), татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге («Тәрәзә», «Кирәк түгел», «Йолдыз ташы», «Чагыштыру», 1998) белән бәйле гамьнәр сагышлы бер моң булып сызыла. Шигырьдән шигырьгә лирик геройның хаксыз-хокуксыз язмышына буйсынган, үткән данына коенып яшәгән милләтенә үпкә хисе үсә, көчәя бара, ачынулы-үкенечле халәт милли тематикага язылган шигырьләрдә төп эчтәлекне хасил итә:

*Кем яздырды юлдан?.. Язмыш чиген*
*Әллә ялгыш үтеп киткәнбез?*
*...Кирәк түгел кеше хокуклары,*
*Кеше түгел инде күптән без!* [Аймәт, 2016, б. 18].

«Адашу» шигырендә әсәр исемендә аерымланган юлдан язу, кыйбла югалту мотивы милләтнең үткәне – бүгенгесе – киләчәге хакындагы уйлануларны бер ноктага туплаучы идеягә әйләнә. Тарих һәм заманны берләштергән чиктәш халәттә күзалланган лирик герой газиз халкының «данлы, шанлы, ханлы чоры»н Болгар, Казан ханлыкларында таба, шушы тарихтан килгән иңрәү авазы шигырьне үтәли иңләп уза, бу импрессионистик образ милләтнең үткәне һәм бүгенгесе аша киләчәккә юнәлгән өзлексез газап булып тәгалләшә, шагыйрь иҗатына хас экспрессия хис дәрәҗәсен көчәйтә, милләт язмышына битараф булмаган укучының күңелен тетрәндерә:

*Иңри кебек җаны бабамнарның,*
*Үрсәләнеп, әрнеп, рәнҗеп тә.*
*Кыйбла эзләп чапкан уйларымны*
*Дисбе итеп тезәм бер җепкә* [Аймәт, 2016, б. 195].

Милләт яшәешен үзгәртә алмаудан туган чарасызлык, шагыйрь әсәрләре өчен традицион ялгызлык мотивы белән үрелеп, лирик геройның моң-сагыш сәбәбенә әйләнә, бүгенгенең ямьсезлеге, караңгылыгы, киләчәкнең өметсезлеге үткәннәр белән яшәү хиссиятен нигезли, ачынулы-үкенүле уйланулар психологик-эмоциональ кичерешләрнең асылында ята. Заманга бәя «шайтан туе» метафорасы рәвешендә реальләшә һәм богаудагы сүз иреге, мескенлек, атмаган таң кебек мотивлар аша тәгалләштерелә. Тарих дисбесенең чиратлашкан ак һәм кара төймәләре лирик герой күңелендә әле киләчәккә

өмет чаткысын сүндерми (*Әле безгә янып яшисе бар? / Шәһит киткән җаннар өчен дә, / Бар җиһанны алсу нурга күмеп / Тумый калган таңнар өчен дә* [Аймәт, 2016, б. 196]), әмма шигырьнең моңлысызланулы хиссият белән сугарылган бетеме өмет рәшәсен ерагайта кебек:

*...Ялгыш кына кинәт орынсам да,*
*Иңрәү килә кебек һәр таштан.*
*Кыргый чорның кыргый кавеме мин*
*Кыйбла эзләп юлда адашкан...* [Аймәт, 2016, б. 196].

Узган еллардан, тарихтан милли хакыйкать эзләү омтылышы XX йөз башы татар сүз сәнгате белән интертекстуаль бәйләнешләр рәвешендә дә формалаша, Тукай, Исхакый, Дәрдемәнд, С. Рәмиев кебек әдипләрнең иҗатына бәйле гыйбарәләр милләтнең бүгенге хәятенә карата борчулы уйлануларны җиткерү чарасына әйләнә («Төш», «Ишетелә Тукай ютәле» һ.б.).

Шагыйрьнең фәлсәфи иҗатында тоемланган моңсулык аның лирик кичерешләр үзәктә торган әсәрләрендә дә әйдәп бара. Нигездә югалту сагышы белән өретелгән мәхәббәт лирикасында бу хиссият үткәннәргә үкенү, китү, хушлашу, аерылу мотивлары аша реальләшә, ялгызы хәтер төпкелләрен кузгаткан лирик геройның күңел дөньясы әсәрләрне сентименталь укылышка көйли («Сукыр тәкә», 1991, 1997; «“Үкенмәм”, димә...», 1992; «Китү», 1997; «Без генәме?», 1997; «Ул төнне дә...» һ.б.). шәхси кичерешләрне дөнья киңлегендә карау хис дәрәҗәсен көчәйтү вазифасына хезмәт итә:

*Без генәме?*
*Әллә дөньяның да*
*Мәхәббәтен җуйган бер мәле...* [Аймәт, 2000, б. 39].

Рәмис Аймәт укучыга тәкъдим иткән беренче шигъри үрнәкләрендә үк үзен сүз-сурәткә гаять игътибарлы, затлы-нәфис каләм иясе итеп таныта, табигый сәләт һәм дөньяны тоемлау үзенчәлеге белән билгеләнгән бу сыйфат татар шигъриятен яңа образлы сурәтләр белән баета, укучыга гаҗәеп тирән лирик кичерешләр дөньясын ача. Тавыш, төс бизәкләренә нигезләнгән импрессионистик сурәтлелек – Р. Аймәтнең иҗат стиленә әйләнгән сыйфат – аның шигъриятен эстетик яктан камилләштерә, *зеңләп өзелгән хыяллар, өметләр, чатнап-чатнап янган йолдызлар, моңын җуйган гармун күрегедәй катып калган дулкыннар* һ.б. шундый образлы сурәтләр әсәрләрне гаҗәеп аһәңлелек белән тулыландыра, лирик-психологик катламга күтелмәгән төсмерләр өсти. Аерым очракларда импрессионистик сурәтләр мөстәкыйль образ дәрәҗәсенә күтәрелә:

*Ә офыкта, кайтаваздай,*
*Көлүеңнең зеңе калды.*
*Мең сер яши, мең могҗиза*
*Авазында һәрбер зеңнең* [Аймәт, 2000, б. 32].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Р. Аймәтнең фәлсәфи-метафизик уйланулар тулы шигырьләрендә экзистенциаль кичерешләр дөньясы, шәхеснең үз-үзен танып белү фәлсәфәсе, лирик субъект кичерешләре фонында яшәешне аңларга омтылуы, шул ук вакытта гомум яшәеш кысаларыннан галәм киңлекләренә тартылуы гаҗәеп синтез барлыкка китерә. Гамьле, сызланучан, уйланучан лирик герой кичерешләре аша автор интеллектуаль укучы белән әңгәмә кора: күпсанлы риторик сораулар, күпнокталар ярдәмендә әйтелеп бетмәгән фикерләр укучы өчен уйланырга җирлек калдыра. Дисбе, ак кәфен, мәңгелекнең яшьле/канлы күзләре, богау чыңы, зеңгелдәп өзелгән хыяллар һ.б. шундый бик күп дини аллюзияләр, символ-метафоралар, мотивлар, бер әсәрдән икенчесенә күчеп, шигырьләр арасындагы чикләрне юа, лирик геройның сагышлы моңын өзлексез итә.

**Әдәбият**


*Аймәт Р.* Шомырт салкыннары: шигырьләр. Казан: Мәгариф, 2000. 111 б.

*Аймәт Р.* Бозлы җилкәннәр: шигырьләр, тәрҗемәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 239 б.

*Аймәт Р.* Айның аръягында: шигырьләр. Казан: Мәгариф, 2004. 191 б.

*Заһидуллина Д.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 7 т. Казан: Фолиант, 2019. Б. 9–35.

*Загидуллина Д.* «Индивидуальная чувственность» как форма самоидентификации лирического субъекта: творчество Рамиса Аймета // Дания Загидуллина. Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. С. 98–107.

*Фәйзуллин Р.* Чикле чиксезлек // Казан утлары. 2005. № 2. Б. 140–142.



***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 801.81

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# СЕБЕРДӘ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ

В статье автор проводит обзор результатов фольклорной экспедиции в Вагайский район Тюменской области, которая была организована Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в 2002 г. Анализируются экспедиционные материалы, записанные автором по татарскому народному творчеству. Разнообразный по своему жанровому составу фольклорный материал из уст татар, проживающих в Сибири, интересен своей тематикой, привлекает богатым содержанием.

**Ключевые слова:** татарский народ, фольклор, вариант, дастан, предание, народные песни.

In the article, the author reviews the results of a special folklore expedition to the Vagai district of the Tyumen region, which was organized by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimova of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2002. Expedition materials recorded by the author on Tatar folk art are analyzed. Diverse in genre folklore material from the mouth of Tatars living in Siberia, is interesting for its theme and attracts with its rich content.

**Keywords**: Tatar people, folklore, variant, dastan, legend, folk songs.

Себер җирлегендә яшәүче татарлар тарихи яктан төрле этник компонентлар кушылмасыннан гыйбарәт. Себердә борын-борыннан көн күрүче җирле халык, XIV гасырдан бирегә күпләп агылган бохаралылар (ягъни Урта Азия төркиләре), төрле чорларда Идел буеннан күченеп килгән татарлар һ.б. бүгенге көндә анда халкыбызның үзенчәлекле бер катламын тәшкил итеп яшиләр. Шуңа күрә Себердә яшәүче татарларның рухи культурасы, аерым алганда фольклоры гаять кызыклы, бай, төрле яклап өйрәнүне сорый.

Себер татарлары иҗаты гасырлар буе галимнәр игътибарын җәлеп итеп килгән. Әле XIX гасыр урталарында ук күренекле галим, академик В. Радлов Себердәге татарлардан җыелган фольклор материалларына үзенең атаклы томнарының берсен [Образцы народной литературы...] багышлаган. Галим бастырып чыгарган әлеге томда урын алган халык иҗаты үрнәкләренең егермегә якыны – эпик әсәрләр. 1984 елда дөнья күргән «Дастаннар» томына [Татар халык иҗаты] кертелгән эпос текстларының күбесе – шушы төбәктә тупланган җәүһәрләр. Чыннан да, Себер – халык иҗатының таҗы булган эпос жанрына карый торган әсәрләрне күпләп биргән төбәк. Атаклы төрки «Алпамыш»ның татар версиясен тәшкил иткән «Алыпмәмшән», гасырлар буена телдән-телгә күчә килгән «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», яисә «Күр углы» вариантлары, «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» һәм, әлбәттә, «Иде-

гәй» үзе иң элек нәкъ менә Себердә яшәүче татарлар арасында киң таралган булган.

В. Радлов яшәгән чорлардан алып бүгенге көнгәчә Себердә яшәүче татарларда да фольклор үзгәрешсез тормаган, әлбәттә. Төрле чорда Х. Ярми, Х. Гатина, Ф. Әхмәтова, Ф. Йосыпов, Д. Рамазанова, И. Закирова, О. Хисамов кебек галимнәр себер татарлары фольклорына игътибар бирә килделәр. Бүгенге көндә дә Себер татарлары иҗаты белән кызыксыну, лиро-эпик һәм лирик фольклор әсәрләрен барлау, бастырып чыгару дәвам итә.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 2002 елда Төмән өлкәсенә фольклор экспедициясе уздырылган иде. Экспедициядә фольклорчы галимнәр Илсөяр Закирова һәм Лилия Мөхәммәтҗанова катнашты. Ике дистә чамасы ел элек биредә алган тәэсирләр бүген дә актуальлеген югалтмаган.

Төмән өлкәсе Вагай районы Казанлы авылына килеп төшкәч тә башкарган иң тәүге эшебез бу авылның астанасы белән танышу булды. Астана – изгеләр зираты. Астанә – фарсы сүзе, «бусага», «сарай ишеге төбе», «төп» дигән мәгънәләрне белдерә [Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, б. 19]. Биредә шундый исем белән аталып йөртелә торган берничә урын бар дип сөйлиләр. Берничә гасыр элек Себергә бохаралылар, ягъни Урта Азия төркиләре күпләп агылган. Аларның бирегә килүенең төп сәбәбе сәүдә-икътисад мәсьәләләре булса, биредә ислам динен таратуда да шул ук бохаралыларның роле зур.

Бохаралылар, бу җирләргә килеп төшкәч, төпләнер урын эзләгәннәр. Җирне казыйлар да чыккан туфракны казылган чокырга кабат күмеп карыйлар икән. Уңдырышлы җирнең туфрагы күпереп, өелеп калырга тиеш булган. Моңа кадәр шундый урын табылмаган, ә Казанлыда исә туфрак казылган чокырына сыймаган, мул булып артып калган. «Уңдырышлы җирләр бу», дип, изгеләр шушында төпләнеп яши башлаганнар (*информант – Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы, 1970 елгы, Казанлы авылы*).

Һәрбер астананың үзенең җаваплы кешесе була. Аны «астана хуҗасы» яисә «астана» дип йөртәләр. Бу кеше изгеләр зиратын карап-тәрбияләп тора, яисә шул эшне оештыра. Астана хуҗасы булу – гади генә йөкләмә түгел, ә Аллаһтан бирелгән әмер, борын-борыннан билгеле бер нәселгә тапшырылган бурыч дип ышана җирле халык. Бу нәсел кешесе астана йоласын үтәп яшәргә, бозыклыктан, явызлыктан, һәртөрле начар уй-гамәлләрдән азат булырга тиеш. Әгәр шушы кагыйдәдән чыкса, аның үзенә генә түгел, нәсел-нәсәбенә бәла килә. Андый очраклар да булган. Халык хәтерли, энәсеннән-җебенә кадәр сөйләп тә күрсәтә. Казанлы астанасы, ягъни астананың төзеклеге өчен җаваплы кеше – Әшрәфҗамал исемле карчык.

Моннан тыш, Төмән өлкәсендәге һәр астананың үз тотемы бар. Әйтик, бу якларда иң олы астана булган Кече Уват (халык телендә –

Малай Уват) каберлегенең символы – Үгез. Казанлыда ул – Каз. Халык үзе моны Бохарадан килгән билге дип аңлата. Бу күпмедер дәрәҗәдә мәҗүсилекне, борынгылыкны чагылдырган күренеш буларак кызыклы.

Төшендә астана тотемын күргән кеше тиз арада астана хуҗасына садака китерергә тиеш икән. Садака итеп тәңкәле акча алына, ул кызыл чүпрәккә төрелә. Шуннан соң гына төш күргән адәм садакасын илтеп тапшыра. Тәртибе шулай. Халыкта моны шык садакасы бирү яки шыкка төю дип йөртәләр. Шык сүзенең «изгеләр каберен караучы» дигән мәгънәсе бар [Әхмәтьянов, б. 497]. Нәзере булса, яисә бәла-каза килсә кеше шыкка төяргә, ягъни астананы караучыга хәер-садака төенләргә мөмкин. Шык садакасын Төмән өлкәсендәге һәр астанага берәрне таратып чыгу гадәте дә бар. Астанага шык садакасы бирү уеңа килсә, аны һичшиксез астана хуҗасына илтеп тапшыру мөһим.

Тарихтан билгеле булганча, XIV гасырдан Көнбатыш Себердә Урта Азиядән килгән мөселманнар – шәехләр мәҗүсиләргә каршы корал тотып көрәшкәннәр. Халык үзе дә: «Бу җирләрдә бик каты сугышлар булган», – дип сөйли. Шәехләрнең кораллы гаскәрләре, исламны инде кабул итәргә өлгергән җирле халык белән берлектә, Себер олысында бохара ханнарының, татар феодалларының һәм, әлбәттә, ислам диненең йогынтысын ныгыту өчен, көрәш алып барганнар. Шушы вакыйгалар нәтиҗәсе буларак, Себердә яшәүче җирле татарлар арасында ислам таралган.

Астаналарга багышланган риваятьләрне һәр йортта беләләр биредә. Күрәсең, изге гореф-гадәтләрне шулай күркәм рәвештә буыннан-буынга тапшыра киләләр. Менә, мәсәлән, *Мөгамәтуллина Мөнәвәрә Җамалетдин кызы (1933 елгы, Сөләйман авылы)* Паеш астанасы турында мондый риваять сөйләде:

«Бохарадан килгән муллалар мондагы халыкны дингә өйрәткәннәр. Аларны саклап килгән солдатлар булган. Әллә ничә йөзләп шундый кеше үтерелеп күмелгән җирне бездә астана диләр. Паеш астанасы – Иртеш аша яхшылар яткан җир. Инде алар кешенең төшенә кереп, үзләрен белдерткәннәр. Бер хатын Паеш астанасын карап торган. Иртән ире торганчы, яланаяк Иртешне атлап чыгып, яхшыларны зыярәт итеп кайта икән. Ире белгәнче, шулай караган астананы. Бервакыт ире күзәтә бара моны. Иртеш аша чыгып та хатынының батмавына исе китә моның. Ире күргәч, хатын балтырыннан бата суга. Шул хәлдән соң, ирем көнләшә дип, астананы нәселендәге башка кешегә тапшыра».

Тәрбияви әһәмияте ягыннан гаҗәеп тәэсирле булып тоелган «Кәтербәт сазлыгы риваяте» дә шул ук бохара «яхшылары»на барып тоташа. Аның «Нугайдагы алтын риваяте» дигән исеме дә бар. Төмән өлкәсенең төрле авылында бу вакыйганы төрлечә сөйлиләр, әмма сюжет, мәгълүмат – бер үк, асылы – үзгәрешсез. Бу риваятьнең Казанлы авылында *Хәлим Харис улы Сәгыйдуллиннан (1949 елгы)* һәм Ту-

гыз авылында *Гөлҗамал Садыйк кызы Шамратовадан (1937 елгы)* ишеткән вариантларының җыелма тексты түбәндәгедән гыйбарәт:

«Малай (Малый, ягъни Кече. – *Л.М.)* Уват белән Большой Уват арасында кырык биш чакрым озынлыктагы, унбиш чакрым киңлектәге күл бар. Аны Олы күл диләр. Тирәвене (тирә-юне. – *Л.М.)* Нугай кыры дип атала. Күл кырында авыл булган. Элекке заманда. Ул вакыт без дә булмаган. Бу күлдә балык тотканнар. Кәтербәт сазлыгы шул күл янында. Анда яхшылар алып килгән алтын күмелгән.

Бервакыт Нугай авылына яшь килен төшкән. Ул килентәшкә күлдән алтын чыгып утырган. Юан (зур. – *Л.М.)* чүген (чуен. – *Л.М.)* булган, имеш. Өч көн рәткә киләте бу килентәш күл буена, өч көн рәткә алтын чыгаты. Анда энҗе-мәрҗәннәр, ат сбруйлары, унике штук алтын ияр булган. Килен моны беркемгә дә әйтмәгән, байлык үземә генә булаты, дигән. Ул килентәш алтынны шулай өч көн уйната икән карап торып.

Инде дүртенче көн баруына чүген казан да юк, алтыннар да юк. Аннан килен авылга кайтып сөйләгән: «Мин сезгә әйтмәгән идем, ул шундый-шундый урында шулай-шулай батып китте», – дигән.

Шуннан бер карт мулланы ияртеп, күл буена барганнар. Мулла китап тотып барган, аннан китап ачкан да әйткән: «Авылдан бер начар кеше чыкты, ул килеп җиткәнче алсак, җитешәбез, өлгермәсәк, алтын төпкә китәр». Алтынны чыгара башлаганнар икән дә, чыгарып бетергәндә генә мулла әйткән теге кеше болар янына килеп җиткән. «Миңа өлеш калдырыгыз», – дип кычкырган. Шуннан алтын төпкә төшкән киткән, тотып кала алмаганнар.

Карт мулла полтар караган (фал ачкан, баккан. – *Л.М.)* һәм әйткән: «Котык токымнан (Коелар нәселе) ак чәчле күк күзле кыз бала туар, күз иясе (уртасы. – *Л.М.)* кызыл булыр. Унсигез яшенә җиткәч, алтын аңа чыгар, ул ала алыр байлыкны», – дигән. «Алтын аңа чыгып утырыр, курыкмаска кирәк. Алтын янына килеп, юан (зур. – *Л.М.)* пычак алып, корбан чалсын», – дип өйрәткән. «Корбан чалганда: «Байлыгым бөтен илгә, миргә булсын», – дип чәнечсен. Ул вакыт алтын батмай», – дигән.

Котык токымда, мулла әйткәнчә, чыннан да ак чырайлы, ак чәчле, күк күзле, күз уртасы кызыл бала туа. Әмма кызга унсигез тулганда аны алтын яткан җиргә – Кәтербәткә алып чыгучы булмый, чөнки әтисе сугыштан кайтмый калган, ә эшнең рәтен белүче башка кеше юк. Шулай итеп, алтын төптә кала.

Мулла тагын әйткән була: «Әгәр дә кыз ала алмаса, Котык токымның җиде буынынача китәр: унсигез елдан унсигез елга шул ук нәселдә шундый ук бала туар. Алтын табылганчы. Җиде буынга җиткәнче алтын табылыр. Котык токымга әйтелгән алтын бу».

Әмма шунысы да бар диләр: «Котык нәселе иманлы, шәфкатьле, изге нәсел булып дәвам итәргә тиеш. Әлеге нәсел кешесенең күңеле гел чиста, керсез булуы кирәк. Комсызларга, затсызларга Нугай алтыны чыкмайты, булмайты». Котык нәселе бүген дә яши, ди, халык

аларның кемнәр икәнен яхшы белә, кызыл күзле, ак тәнле ир бала хәзер уналты яшьтә диделәр.

Югарыда китерелгән бу истәлекне һәм астаналарга багышланган үрнәкләрне тарихи риваятьләр дип билгеләсәк, мифик чыгышлы хикәятләргә боларыннан да күбрәк юлыгырга туры килде. Урман яки Күл иясе адаштырган, яисә, белештермичә, урман иясенә – Йышка өйләнеп харап булган аучылар турындагы хикәятләр – әнә шундый әсәрләрнең бер төркеме. Йыш – Шүрәлегә охшаш образ, әмма аның гадәте кешеләрне кытыклап үтерү түгел, ә калын урман эченә алып кереп адаштыру. Йышка яки Йыш иягә (монысы ир затыннан булган урман иясе) юлыккан кеше, кая барганын абайламыйча, йөгерәатлый урман эченә кереп китә, тәмам хәлдән тайганчы адашып йөри. Шуңа күрә Ияләрнең – урманныкымы ул, күлнекеме, йорт-кура, мунчаныкымы – ачуын кабартырга, аларга ошамаслык начар гамәлләр кылырга, чаманы югалтырга, тыелган эшне кылырга ярамый дип белә халык. Моның шулай булуына дәлилләр китереп сөйлиләр. «Бер сунарчы күлдә йөргән. «Йиргә ятма, йоклама сунарда» дигәнне белсә дә, яткан. Йоклаган. Төшенә өч кыз керә моның. Сине яраттык, диләр сунарчыга, беребезне ал, диләр. Шуннан уянып китә бу, кызны алып кайта, белми Йыш икәнен, шуның белән яшәйте. Үзе сунарга йөри. Бичәсе бу кайтуга тәмледән тәмле ит ризыклары әзерләп куя икән һәм әйтә: «Кайтканда ишекне гел шакып кер, юкса ачуланышырбыз», – ди. Ир шиккә төшә каян алып пешерә, дип. Бервакыт ишекне шакымый кайтып керә дә күрә: хатын аннан бет ала, моннан борча тота да сумсалар, пилмәннәр ясый ди шулардан. «Ишектән кердем, тәрәзәдән чыгам!» – дигән дә чыгып очкан ди ире искәрмәстән кайтып кергәч. Дүрт баласы калган. Токымнары әле дә бар ди. Күзләре канлы, кызыл. Ул сунарчы яшәгән йорт урынына бүтән берәү дә йорт салмаган» (*информант – Мөгамәтуллина Мөнәвәрә Җамалетдин кызы, 1933 елгы, Сөләйман авылы)*.

Җен карчыгы Изурчык белән төне буе җеп эрләүдә ярышкан Кече әби, пәри хатынына кендек әбисе булган корткаякка багышланган мифик риваятьләрне дә Себер татарлары ихластан бирелеп, бик мавыгып бәян иттеләр. Бу үрнәктә Кече әбинең мунча иясе белән ни рәвешле мөгамәлә кылуы бик кызыклы: «Кече әби тәһарәтен алып бетте, бу сүзләрне әйтеп, мунча ишеген каты япты:

– Тимәдегез, тавышланмадыгыз, сүзегез булмады, көмеш суны буямагыз». Кече әби (әбинең кечкенә буйлы булуына ишарә) шул рәвешле мунча иясе белән сөйләшә. Бу – татар мифологиясе өлкәсенә караган, халыкның тормыш-көнкүрешен ача торган кызыклы элемент буларак әһәмиятле.

Аерым бер төркемдә – үлгәннән соң җиде кабер аша чыккан кан эчүче зат – Купканнарга, алар белән бәйле маҗараларга багышланган хикәятләр. Аларны тыңлаганда тын алырга да куркыта, кичке якта урамга чыгарга шикләндерә. «Купкан – бу дөньядан туймый китеп кузгалган кеше пулаты, – дип аңлаталар Себер татарлары. – Кире

кайтып, кешеләрне куркытып йөрите. Каты кузгалып йөри башласа, кешеләргә зыяны арта. Бик азып киткән Купкан кешеләргә тия, аларның канын эчеп йөри башларга мөмкин». Мондый хәл булмасын дип, алдан ук чаралар күрелә икән.

Купканны басу өчен Коръәннән уналты сүрә укый-укый иң элек өч кат зиратны әйләнеп чыгарга кирәк. Шуннан шул ук сүрәләрне киресенә укыйсы. Бер хәрефен дә ялгышырга ярамый. Ялгыштың – беттең дигән сүз, я үләсең, я гомерлеккә гарип каласың. Кем кузгалган, шул алдыңа килеп басканчы укыйсы. Купкан каршыңа килеп баскач, кирәкле аятьне укып, аңа урынына кереп ятарга кушасың. Шулай иткәч, Купкан каберенә кереп ята. Бу эшне укымышлы мулла гына башкара ала икән *(информант – Пахметова Сөлҗамал Ситдыйк кызы, 1926 елгы, Тугыз авылы).*

Таңнан торып, җиде өйнең чүбен себереп алып, аять укып өшкертеп, зиратка алып барып, Купкан чыга торган җиденче кабер тишегенә салсаң да, Купкан басыла, имеш *(информант – Шамратова Гөлҗамал Садыйк кызы, 1937 елгы, Тугыз авылы).*

«Кем кузгалганын белү өчен зиратта каберләрнең комын карап цыккалы гәрәк. Кузгалган кешенең кабере өстендә комы иләктән иләнгән кебек пулаты. Әүвәл син шуны сизеп, кем кузгалуын белсәң, Купкан төнлә төшеңә керәте, беркемгә дә сөйләмәскә кушып, куркыта», – дип сөйлиләр информантлар. Бу дөнья белән теге дөнья арасындагы бәйләнешкә, гаять серле темага караган бу хәбәрләр мавыктыргыч булуы белән җәлеп итә, мифлар дөньясына алып кереп китә.

Әле шундый хәлләр дә булган, имеш, Купканны Коръәннән аятьләр укып басарга муллаларның гына көче җитмәгәч, бик каты кузгалып йөри башлаган берәүнең каберен ачып, башын чапканнар. Ул исә башын култык астына кыстырып йөри башлаган. Ахырда аның күкрәгенә казык какканнар. Аннан соң да туктамаса, андыйны яндыралар икән. Купкан турында сөйләүче ялгыш та аның исемен телгә алмый. Юкса каршыңа чыгуы бар, дип ышаналар *(информант – Рәхмәтуллина Мәүлига Нәгыйдулла кызы, 1902 елгы, Казанлы авылы).* Бу өлкә гомер-гомергә адәм баласында зур кызыксыну уяткан, адәм акылы аңлый алмастай күренешләргә халык үз бәясен биргән, исламга, Аллаһ ярдәменә таянып, мондый күренешләргә җавап тапкан, күңелен шулай юаткан.

«Кая соң ул купканнарыгыз, нигә миңа бер дә очрамады?» – дигән соравыма да аңлаешлы бик матур җавап алдым: «Фәрештәләрең яхшы саклый торган, димәк. Кешене саклаучы фәрештәләр аның күзенә җен-пәриләрне дә, купканнарны да күрсәтмиләр, кешене алардан саклыйлар. Аннан болай артык курыккан вакытта, я бик ашыгып йөрүче кешегә дә андый нәрсәләр күренми. Андыйлар, кабаланып, җеннәрне таптап ук уза. Шуңа күрә бүгенге көндә кул-аягы сынык җеннәр күп һәм алар кешеләргә ачулы» *(информант – Ватутова Флёра Рәхимҗан кызы, 1963 елгы, Казанлы авылы).*

Миф, уйдырмаларга халыкның күңел аклыгы, садәлек сыйган. Юкка гына халык иҗаты аның күңел көзгесенә тиңләнми шул. Түмән өлкәсендә фольклор әсәрләре барлап йөргәндә мин шулар турында уйландым.

Әби-апалар яшь чагында нинди уеннар уйнаулары турында сөйлиләр. «Саргынаем», «Аралап алышмак», «Өзелешмәк», «Тилгән», «Каешлы» дип аталган җырлы-биюле уеннары Казан татарларының «Назалы», «Түгәрәк», «Тамчылы» һ.б. уеннарын хәтерләтә, әмма җыр текстлары, такмаклары, көйләре үзенчәлекле:

«Яшь чакта «Саргынаем» уйный торган идек. Җитәкләшеп басасың да ер ерлайсың бер-береңә такмак-такмак:

Сөләйманнан уң якка
Казанлы авыл – бай авыл.
Сөләйманның складына
Хәтирә туташ каравыл.

Убай юлы, Убай юлы,
Убай юлы канаулыэ
Мин синең сөйгәнең күрдем –
Скрипка танаулы.

Сөләйманның буйдаклары
Аюның табанынтай.
Казанлының буйдаклары
Алманың сабагынтай.

Етәкләшеп түгәрәктә әйләнәсең. Уртада бер пар тора. Такмак бетсә, бу икәү түгәрәккә чыгып өерләнә, янә ике кешене этеп уртага чыгаралар да тагын ерлайлар» *(информант – Шамратова Гөлҗамал Садыйк кызы, 1937 елгы Малай Уват авылы).*

Авыл көенә җырлана торган әллә никадәр кыска җыр язып алынды Себер татарларыннан. Казанлы авылында Мөгамәтуллина Рабига апа Әмин кызыннан (1931 елгы) гына да шундый 80 куплет җыр теркәлде. Карагай авылында Ваби исемле кеше яшәгән, ул сукыр булган, авылдан-авылга йөреп тамак туйдырган. Аны оста импровизатор – такмак чыгаручы буларак хәтерлиләр, такмакларын да онытмаганнар. Ваби 1950 елларда дөнья куйган.

Мөгамәтали мәргән белән Кузы Нияска, аючы Хәйбуллага, Атамыш аучыга багышлап матур-матур кыйссалар сөйләделәр Себердә яшәүче татарлар. Аларда күптән түгел генә шушы җирдә яшәгән кешеләр турында сүз бара, боларның исемнәре халык теленә юкка гына кермәгән. Гаҗәеп батыр, пәһлеван, төз атуда тиңсез оста булганнары өчен онытмый аларны халык. Мөгамәтали мәргән, мәсәлән, яхшылар нәселеннән, ягъни Бохарадан килгән шәехләр токымыннан булган. Халыкта аның оста мәргәнлеге, җитезлеге, батырлыгына багышланган, яисә башка мәргәннәр белән көч сынашулары хакында күп кыйссалар телдән-телгә йөри. Мәсәлән, Мөгамәтали белән күрше авыл

мәргәне Кузы Нияснық төз атуда көч сынашуы турындагы кыйсса хәтердә уелып калды. «Кузы Нияс оста чаңгычы булган. Песнең якларда аучының эте карап өргән агачтан иң яхшы чаңгы ясаганнар. Чаңгы ясарга агач сайлаганда аучының эте кайсы агачка карап өрә, шул агачны аударганнар. Наратның озынына, яшенә, формасына карап эстәгәннәр, эт тә аңа карап өрсә, яхшы саналган. Иң елгыр чаңгы Тугыз авылыныкы яхшылар нәселеннән Кузы Нияста икән. Кузы Нияс чаңгысының эзе калмый булаты. Оца торган чаңгылар булаты. Уват авылыннан Мөгамәтали мәргән белән урманда очрашканнар да көч сынашып карамакчы булганнар болар. Сөйләшкәннәр багып атуга (багып ату – яшертен барып ату. – *Л.М.).* Чаңгылар белән булганнар. Аңны (пошиi. – *Л.М.)* күргәч, Мөгамәтали мәргән мылтык төзәгән аткалы. Шул вакыт Кузы Нияс ботакны сындырган, аңны кацыру өчен, Мөгамәтали мәргән ата алмый калган, аң олагып цыгып кацкан. Шуннан Кузы Нияс аңның артыннан чаңгысында куып житкән дә атып еккан аңны, бугазлаган, аннан кайтып киткән. Кузы Нияс кацып барган аңны чаңгысында куып йитеп атып алган булаты. Өстен чыккан Мөгамәталидән. Мөгамәтали барып караган, моның чаңгы юлы булмаган, эзе күренмәгән. Халыкка кайтып сөйләгән хәлне. Халык шикләнгән Кузы Ниястан, моның суда юынуын көткәннәр. Бер кеше күргән: Кузы Нияснық култык астында канатлары бар икән, юынганда болар күренгән. Кусы Нияс карап торучы кешегә арты белән торса да, аны күргән, кыцкырган: «Беркемгә сөйләмә, сөйләсәң, петәсең!» – дигән. Анық канатын күргән кеше, Кусы Нияс картаеп үлгәч, аны сөйләгән. Шуныңчы сөйләмәгән. Кузы Нияснық оца торган чаңгылары әнә шул каурый-канатларыннан булаты» *(информант – Сәгыйдуллин Хәлим Харис улы, 1949 елгы, Казанлы авылы).*

Ауда йөргәндә хәтәр хәлгә очрап, зирәклеге, батырлыгы, көче аркасында котылып калган Атамыш аучы кыйссасын, берүзе кырык карышлы яралы аюга каршы чыгып җиңү яулаган аючы Хәйбулла бабай турындагысын һ.б.ларны язып алган вакытта Себер татарлары: «Бу булган хәл дип сөйлиләр», – дияргә онытмыйлар. Шунысы кыйммәт: әлеге кыйссаларда халкыбызның героик дастаннарыннан килә торган рух бар. Ул – батырга дан җырлау, анық гадәттән тыш көчле булуын, каһарманлыгын ассызыклау. Мөгамәтали мәргән, Кузы Нияс, аючы Хәйбуллаларга багышланган шактый күләмле бу кыйссалар атаклы «Алпамыш», «Йиртөшлек », «Кадыш Мәргән» һ.б. дастаннар традициясен дәвам итәләр. Әлбәттә, кыйссаларның без язып алганнары әллә ни ерак гасырларга карамый, алай да халык иҗатының бүгенге көнгә, заманга туры килә торган иҗат җимешләре алар. Себердә яшәүче татарларның тормышы кош, җәнлек аулау белән тыгыз бәйләнештә. Менә шушы бәйләнеш аларда батыр аучы-мәргәннәр турында мавыктыргыч әсәрләр барлыкка китергән, һәм иң мөһиме, күргәнебезчә, мондый кыйссалар тел-авыз иҗаты буларак әле дә очрый.

Түбән өлкәсе Вагай районында яшәп ятучы милләттәшләребез белән аралашу татар фольклористикасын яңа эпик образларга,

фольклорга бәйле сюжетларга баетты, туган телебезнең никадәр бай булуына янә бер кат инандырды. Халык иҗаты материаллары бар һәм күп Төмән өлкәсе татарларында. Тарих чоңгылының матди булмаган бик күп рухи байлыкны йота барганлыгы аңлашыла. Алай да халык авыз иҗаты, бүгенге көнгә яраклашып, чагыштырмача яхшы хәлдә әле биредә. Себердә яшәүче татарларның бай тарихы, борынгылыкны саклаган җирле сөйләшләре, гореф-гадәт, йолалары белән бергә телдән-телгә тапшырыла килгән риваятьләре, мифологик хикәятләре, героик дастаннар төркеменә кертерлек кыйссалары, уеннары, җырлары – бүгенге көн фольклорының тиңсез хәзинәләре.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. 2 томда. 2 т. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 568 б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. 2 томда. 1 т. Казан, 1965. 448 б.

Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, собраны В.В. Радловым. Ч. IV. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1872. 424 с.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В.Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр, 1984. 384 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 801.82

***А.Д. Батталова***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ БАСМА ЧЫГАНАКЛАРЫНДА ЧИСТАЙ ТӨБӘГЕНӘ БӘЙЛЕ ТАРИХИ МӘГЪЛҮМАТЛАР ҺӘМ ФОЛЬКЛОР МАТЕРИАЛЛАРЫ (В.А. Казаринов, Е.А. Малов, С.Е. Малов хезмәтләре мисалында)

Открытие Казанского Императорского университета, создание при нем Общества археологии, истории и этнографии способствуют всестороннему изучению истории, этнографии народов Поволжья. Самые первые работы, посвященные Чистопольскому региону, выполняются членами этого общества. В данной статье рассматриваются работы В.А. Казаринова, Е.А. Малова, С.Е. Малова как фольклорные, народоведческие и исторические источники в изучении Чистопольского края.

**Ключевые слова:** Чистополь, татары, мишары, фольклор, текст, жанр, анекдот, поверья, песня, загадка, пословица.

The opening of the Kazan Imperial University and the Creation of the society of archeology, history and ethnography under it contribute to a comprehensive study of the history and ethnography of the peoples of the Volga region. The very first works dedicated to the Chistopol region are performed by members of this society.The works of V. A. Kazarinov, E. A. Malov, and S. E. Malov are examined in the article as folklore, folk studies, and historical sources in the study of the Chistopol region.

**Keywords:** Chistopol, Tatars, Mishars, folklore, text, genre, anecdote, beliefs, song, riddle, proverb.

Казан Император университеты ачылу, аның каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең эшләп китүе Идел буе халыкларының тарихын, этнографиясен һәрьяклап өйрәнүгә этәргеч бирә. Чистай төбәгенә багышланган иң беренче хезмәтләр дә шушы җәмгыять әгъзалары тарафыннан языла. Чистай өязе мишәрләре турындагы беренче хезмәтләрдән В.А. Казариновның 1885 елда Казан Император университетында басылып чыккан «О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии» [Казаринов] дигән мәкаләсен атап үтү урынлы булыр. Бу мәкаләдә автор Чистай өязендә яшәүчеләрнең бер өлеше үзләрен мишәр дип атауларын әйтеп үтә һәм шушы атамага бәйле беркадәр мәгълүмат китерә. Чистай өязендә бу чорда 80 татар авылы булуын, бу авылларда керәшен татарлары һәм Мөхәммәд динендәге татарлар яшәвен ассызыклый. Мәкаләнең икенче өлешендә бу авылларда теркәлгән сүзләр китерелә, аларның татарча, русча яңгырашы бирелә, һәм мишәр һәм татар сүзләрен чагыштырып, алар арасындагы әйтелеш һәм мәгънә аерымлыклары барлана. В.А. Казаринов мәкаләнең өченче өлешендә «Мишәрләр кемнәр алар, алар нинди халык һәм кайларда яши?» дигән сораулар

күтәрә. Автор Казан губернасы халкына багышланган хезмәтләрендә мишәрләр турында аерым сүз булмавын, В.В. Радловның «мишәрләр шул ук татарлар алар», дигән фикере белән бәйләп аңлата.

Казан губернасында, аерым алганда Чистай өязендә яшәүче мишәрләр турындагы фикерләрне Е.А. Маловның 1885 елда, шулай ук Казан Император университеты типографиясендә басылып чыккан «Сведения о мишарях. Историко-этнографический очерк» мәкаләсендә табарга мөмкин [Малов, 1885].

Биредә без хезмәттә урын алган бер үзенчәлекле фактка тукталып үтүне кирәк дип таптык. Е.А. Малов үзенең әлеге язмасында үзенчәлекле ике этноним куллана: берсе – *мишәрләр*, икенчесе – *Мөхәммәд динендәге татарлар*. Әлбәттә, икенче этноним шактый каршылыклы, чөнки мишәрләр дә Мөхәммәд динендә. Шулай булса да Е.А. Малов әлеге ике этник төркемне аерып торучы шактый күп дәлилләр китерергә омтыла. Мәсәлән, мишәрләрнең Мөхәммәд динендәге татарлардан тышкы кыяфәтләре, киенү рәвеше һәм сөйләше белән аерылып торуларына аеруча басым ясый. Без исә бу мәкалә кысаларында, авторның фикер сөрешен саклау теләге белән, Е.А. Малов сайлаган бүленештән тайпылмый, ул кулланган, фән өчен «шартлы» этнонимны саклауны мәслихәт күрдек.

Хезмәттә «Мәзәкләр яки мишәрләр турындагы әкиятләр (мишәр хикәятләре)» дигән исем астында тәкъдим ителгән бик үзенчәлекле фольклор текстлары бар. Башлап шуларга тукталыйк. Ислам догматикасын, гарәп һәм татар телләрен яхшы белгән Е.А. Малов мөселман-татарлар һәм яһүдләр арасында актив миссионерлык эшчәнлеге алып бара: православие динен актив пропагандалау, мөселман руханилары һәм җирле халык белән ачык бәхәс алып баруны беренче планга куя. Миссионерлык эшчәнлегенең төп алымы мөдәррисләр, шәкертләр, гади диндарлар белән аралашудан, ислам илаһияте нигезләрен тикшереп, тыңлаучыларны христианлыкның өстенлегенә ышандырудан гыйбарәт була [Tatarica]. Хезмәттә тәкъдим ителгән фольклор үрнәкләре, мишәрләр турындагы мәгълүматлар Е.А. Маловның халык белән шушындый аралашулары вакытында тупланган. «Казан губернасында Чистай һәм Спас өязендә мишәрләр яши» [Малов, 1885, с. 5]. Мишәрләрнең теле – татар теле, әмма рус теленең тәэсире бик көчле, моннан тыш татар теленең аерым сүзләре дә бик күп. Алар бик каты һәм кычкырып сөйләшүләре белән аерылып торалар, сөйләмдә татар сүзләре белән рус сүзләрен катнаштыралар, [гъ] һәм [къ] авазларын әйтмиләр. Бу үз чиратында, Мөхәммәд динендәге татарларның мишәрләрдән көлүенә сәбәп булып тора [Малов, 1885, с. 5]. Әмма мишәрләр татарларга караганда күпкә акыллырак, игелеклерәк һәм башкаларга хәерхаһлы булулары белән үзенчәлекле, Мөхәммәд динендәге татарлар түбәнсетүле мөнәсәбәтләре белән мишәрләрне кимсетәләр, мишәрләр гаилә көнкүрешендә дә тәртиплерәк, алар татарлар кебек күп хатын алу белән дә мавыкмыйлар, дип билгеләп үтә үзенең хезмәтендә Е.А. Малов [Малов, 1885, с. 5–6]. Е.А. Малов туплаган

фольклор текстларының бер өлеше мишәрләрнең беркатлылыгыннан, наданлыгыннан көлүче мәзәкләр булса, икенче бер өлеше – татарларларның русча белмәүләреннән көлүче хикәятләр. Барлык мәзәкләр дә – тормыш-көнкүреш мәзәкләре. Беренче төр мәзәкләрдә мишәрләрнең куен сәгатенең чылбырын елан итеп кабул итүләреннән, үзе үк салып куйган тунны аю дип куркып атып җибәрүләреннән, карабодай кырын диңгез дип уйлап йөзмәкче булуларыннан, тәрәзәсез өй салып, урамнан иләк белән яктылык ташуларыннан көлелә. Бу типтагы мәзәкләрнең төп персонажлары булган мишәрләр Мөхәммәд динендәге татарлар тарафыннан беркатлы, надан итеп сурәтләнгәннәр. Бу, үз чиратында, XX гасыр башында татарларның ике этник төркеме арасында үзенчәлекле мөнәсәбәтләрнең яшәп килүен күрсәтүче факт буларак та бәяләнә ала. Икенче төр мәзәкләрдә, киресенчә, Мөхәммәд динендәге татарларның рус телен белмәүләренә кимсетүле бәя бирелә. Күренгәнчә, әлеге мәзәкләрне эчтәлегенә һәм сөйләүчесенең кем булуына карап, үзара бирелгән бәяләрне анализлап, милләтебез формалашу процессларында барган этномәдәни бәйләнешләрнең гади генә түгел, үзенчәлекле эчтәлек һәм үзара мөнәсәбәтләр кытыршылыклары белән баруын күрәбез. Әлеге галимнәр туплаган әсәрләр моны дәлилләүче мөһим факт булып чыгыш ясый. Тагын бер кат шуны ассызыклап әйтергә кирәк, В.А. Казаринов һәм Е.А. Малов туплаган татар халык әсәрләре төрле басмаларда дөнья күреп, тарих битләренә уелган. Алар милләтебезнең фольклор мирасын барлау чыганагы гына түгел, ә татар милләте формалашу процессында барган катлаулы күренешләрне дәлилләүче чыганак та.

Инде әлеге әсәрләрнең атрибуциясенә беркадәр туктап китик. Әйтергә кирәк, бер генә әсәрнең дә кемнән, кайсы авылдан, кайчан язып алынуы турында мәгълүмат юк. Шул ук вакытта – җыелган бар материалның галимнәр тарафыннан Чистай һәм Спас өязләре татар авылларына оештырылган экспедиция кысаларында язып алынганлыклары төгәл билгеле [Казаринов; Малов, 1885, с. 7]. Димәк, биредә без дә аларның Чистай өязе татар авылларында тупланган материаллар булуы турындагы фикерне шактый шартлы кулланырга мәҗбүрбез.

Е.А. Малов алга таба үзенең хезмәтен «кемнәр алар мишәрләр?» дигән сорауга төрле фаразлар китереп җавап бирүен дәвам итә һәм Казан татарлары арасында мишәрләр төрек кабиләләре белән рус кабиләренең кушылуыннан килеп чыккан дигән ышану яшәвенә дә туктала. Фикерләрен дәлилләү чыганагы буларак, халык легендаларын, риваятьләрен китерә. Ә мишәр атамасы төрекләрнең туган җирләренә бәйле килеп чыккан дигән фикер барлыгын ассызыклый [Малов, 1885, с. 27]. Әлеге җыентыкта ике ышану безнең игътибарны җәлеп итте. Беренче ышануның эчтәлеге түбәндәгечә. Татар ханнары белән руслар арасында һәрдаим сугышлар барган, көннәрдән беркөнне татар ханы төрек солтаныннан ярдәм сораган. Төрек солтаны күпсанлы гаскәрен җибәргән, алар башта татарлар яклы булып сугышсалар да, беркадәр вакыттан татарларга зыян да сала башлаганнар. Моны

белеп алган хан, аларны үз биләмәләреннән куган. Куылган күпсанлы гаскәр кире солтан җиренә кайтырга курыккан, үзара киңәшләшкәннән соң, гаскәриләр русларга буйсынырга булганнар. Рус падишаһы аларга рус кызларына өйләнергә, рус кызларына төрек солдатларына кияүгә чыгарга рөхсәт биргән. Шул сәбәпле, мишәрләрнең теле рус сүзләре белән бик чуарланган диелә ышануда. Шунысы кызыклы, Е.А. Малов бу ышану эчтәлегенең тарихи яктан бөтенләй расланмавын аңласа да, аның эчтәлегендә хаклык барлыкка ишарә ясый. Икенче ышану болайрак: Истанбулдан гаскәриләрнең, Казан ханы үтенече буенча, Явыз Иван гаскәрләреннән яклау өчен, 1552 елда килүләре, әмма Казан ханына хыянәт итүләре, кире Истанбулга кайтырга куркулары, Россиядә яшәргә калырга Мәскәү императорыннан рөхсәт сораулары һәм биредә төпләнеп калулары турында сөйләнелә. Теркәүче бу ышануның чынбарлыкка якын булуын, төрек һәм мишәрләрнең [къ], [гъ] авазларын кулланмавы, [h] авазының булмавы, икесендә дә бик күп уртак сүзләр булуы белән бәйләп аңлата. Ышану эчтәлегеннән аңлашылганча, мишәрләрнең руслар белән кушылулары турындагы фикердән кискен баш тартыла, мишәрләр телендә актив кулланылышта йөрүче рус сүзләренең күплеген рус милләте белән тыгыз аралашудан күрә һәм алар – төрекләрнең дәвамчылары, дигән нәтиҗә ясала.

Е.А. Малов Мөхәммәд динендәге татарларның мишәрләргә йогынтысы көчле булуга игътибар итә, аларның руслар белән кушылуны кимсетү сыйфатында кабул итүләрен, чукынудан бик куркуларын ассызыклый. Әлеге әсәрләргә бәйле фикерләрен йомгаклаганда, Е.А. Малов, гомумиләштереп, «бу ышанулар белән татарлар мишәрләрне руслардан ерагайтырга, үзләренә якынайтырга теләгәннәр, дигән нәтиҗә чыгара [Малов, 1885, с. 28–35].

ИгътибарыбызныЧистай төбәген XX гасыр башында өйрәнүчеләрнең берсе – Сергей Ефимович Малов иҗатына да юнәлтик. Мәгълүм булганча, С.Е. Малов – күренекле галим-тюрколог, шәрык белгече, дистәдән артык күләмле китап, йөздән артык мәкалә авторы. Аның хезмәтләре Себер һәм Идел буе, Үзәк һәм Көнбатыш Кытай, Монголия, Урта Азия һәм Казакъстан җирләрендә яшәүче төрки халыкларның телен, фольклорын, тарихын һәм этнографиясен тикшерүгә багышланган. Шулар арасында Чистай төбәгендә яшәүче милләтәшләребезнең XX гасыр башына хас сөйләм үрнәкләрен, халык иҗаты әсәрләрен туплаган, бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган җыентык та бар. Тюркологлар өчен С.Е. Малов төрки телләрнең фәнни тасвирламаларын беренче тапкыр тәкъдим итүче буларак билгеле, чөнки ул – күп кенә борынгы төрки язма истәлекләрне тикшереп фәнни әйләнешкә керткән шәхес. Шунлыктан, аның эшчәнлеген бәяләгәндә, төп игътибар тюрколог һәм шәрык белгече булуына [Кормушин, Насилов; Милибанд; Убрятова] бирелә. Кайбер галимнәр исә, мәсәлән, С.М. Абрамзон [Абрамзон, б. 12–25], аны төрки халыкларның этнографиясен өйрәнүче буларак та таныйлар.

С.Е. Малов 5 нче класстан алып (ягъни, 1898 елдан), югары рухи уку йортында – Дини академиядә белем алу чорында да (1900–1904) татар телен өйрәнүен дәвам итә һәм соңгы ике елында Император университеты профессоры Н.Ф. Катанов лекцияләрен тыңлый, әтисе Е.А. Малов белән Казан университеты каршында оешкан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларында даими катнаша. Җәйге каникуллар вакытында С.Е. Малов Казан губернасының Зөя һәм Чистай өязләренә, мишәрләр сөйләшен өйрәнү максатыннан, сәфәргә чыга [Кормушин, Насилов, с. 5]. Сәфәр нәтиҗәсе буларак, ул «Изъ поездки къ мишарямъ» дигән җыентык әзерләп бастыра. Әлеге мәкаләдә без шушы җыентыкка тукталып, анда урын алган, XX гасыр башында Чистай өязендә яшәгән мишәрләргә хас фольклор үрнәкләре турында да сүз алып барырбыз. С.Е. Малов җыентыгының сүз башында, В.А. Казаринов һәм профессор Е.А. Маловның мишәрләр турындагы мәкаләләреннән соң, аның бу як мишәрләре белән кызыксынуы артуын, һәм мишәр сөйләше белән якыннанрак танышу максатыннан, Чистай өязе авылларына баруын аңлата. Җыентыкта бирелгән мәгълүматта гыйльми сәфәрнең 1902 елның 5–14 июнь көннәрендә оештырылуы һәм галимнең Каргалы һәм Дүртөйле авылларында тукталуы әйтелә [Малов, 1904, с. 3]. Автор Чистай мишәрләре сөйләшенең фонетик үзенчәлекләрен санап үткәннән соң, үзе туплаган фольклор үрнәкләрен дә китерә. Тупланмада 20 кыска җыр тексты (аларны автор мишәр җырлары дип атый) һәм аларның рус теленә тәрҗемәсе китерелә. Әлеге җыр текстларын фольклорчы М.Х. Бакиров бүленешенә таянып [Бакиров, б. 160] классификацияләсәк, аларның барысын да лирик һәм көнкүреш җырлары дип атый алабыз. Бер төркеме – мәхәббәт җырлары:

*Урам буйлап син киләсең,*
*Аягыңда Казан калушы;*
*Тауышың – былбыл тауышы,*
*Зифа буйың – диңгез камышы* [Малов, 1904, с. 12].

*Өстәл өстендә шәм яна,*
*Тармак-тармак май тама;*
*Сиксән керпек – ука бөртек*
*Нурлы йөзеңне яба* [Малов, 1904, с. 12].

Бу типтагы җырларда хатын-кызның матурлыгы, чибәрлеге, яшьлеге макталса, икенче бер төркемендә егетләрнең булганлыгы, егетлегенә дан җырлана.

*Абзый синең мыегың –*
*Сәмрух кош канаты;*
*Синең кебек булса булыр*
*Патшаның санаты* [Малов, 1904, с. 13].

Бер төркем җырларда егет белән кызның пар килүе, бер-берсенә тиң булуы турында сүз бара, нәселнең дәрәҗәсе, заты югалмауга

сөенү хисләре чагыла. Текст эчтәлегенә, алардагы мөрәҗәгать объектына бәйле сүз йөртсәк, аларны туй йоласы җырлары дип тә атап була.

*Ике дә була атыбыз,*
*Өч тә була атыбыз;*
*Сезнең белән бергә булгач,*
*Югалмыйдыр затыбыз* [Малов, 1904, с. 13].

Җыентыкта беркадәр урынны мәкаль-әйтемнәр дә алып тора. Фольклор галиме М.Х. Бакиров халык иҗатының үзенчәлекле жанры булган мәкаль-әйтемнәр турында: «Халыкның менталитеты, этник характеры һәм этник аңы аның культурасында да чагылыш таба. Шул исәптән тел һәм образлы-хикмәтле сүз берәмлекләре булган мәкаль-әйтемнәр дә культура билгеләре яки кодлары буларак характерланалар. Чөнки алар, – милләтара һәм гомумкешелек кыйммәтләрен саклау һәм тапшыру чарасы булу белән беррәттән, аерым бер халыкның яшәү рәвешен, милли рухын һәм этник культурасын теге яки бу дәрәҗәдә чагылдыручы калыплашкан модель-берәмлекләр дә», ди [Бакиров, с. 95]. Әлеге афористик жанр әсәрләрен М.Х. Бакиров фикерләренә таянып күзәтсәк, алар аркылы XX гасыр башына хас татар тормышын, үзара мөнәсәбәтләрне беркадәр бәяләргә була. Мәсәлән, *«Бирмәсә дә бай яхшы, ашамасаң да май яхшы», «Байның бозавы, ярлының баласы»* [Малов, 1904, с. 16]. Күренгәнчә, биредә халык арасында яшәп килгән социаль тигезсезлеккә мөнәсәбәт белдерелә. Беришләрендә халык акылында формалашкан яшәү тәртипләре урын алган. Мәсәлән, *«Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы», Яхшы белән йөрерсең, җитәрсең морадка, яман белән йөрерсең, калырсың оятка»* [Малов, 1904, с. 16]. Композицион яктан бәяләсәк алар, башлыча, ике объектның яки күренешнең янәшә бирелүенә нигезләнгәннәр. Шул ук вакытта күренеш яисә сыйфатларның үзара капма-каршы куелуына корылганнары да бар.

Югарыда атап үтелгән җыентыкта табышмаклар да теркәлгән. Төзелешләренә нисбәтле сүз йөртсәк, алар, нигездә, метафорик табышмаклар: *«Кечкенә генә бөкере, бөтен кырны бетерде»* (урак), *«Кечкенә үзе, мең күзе» (уймак), «Сары бия чаптырып сия»* (самавыр) [Малов, 1904, с. 18]. Әлбәттә, әлеге әсәрләрдән дә XX гасыр башында Чистай өязендә яшәгән татарларның телен генә түгел, ә көнкүрешен дә күз алдына китереп була. Шуңа күрә С.Е. Маловның 1904 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан «Изъ поездки къ мишарям» җыентыгында теркәлгән фольклор үрнәкләрен әлеге төбәктә яшәүчеләрнең дөньяга карашын, яшәү рәвешен, рухи кичерешләрен бәяләүдә хаклы рәвештә мөһим бер чыганак буларак бәяли алабыз.

Югарыдагы күзәтүләребезгә нисбәтле фикерләребезне йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәләргә килә алабыз. В.А. Казаринов, Е.А. Малов, С.Е. Маловларның XX гасыр башында Чистай өязенә кергән татар авылларында язып алган материаллары – төрле басмаларда дөнья

күреп, бүген дә актуальлеген югалтмаган әсәрләр. Алар, беренче чиратта, фольклор мирасы булсалар, икенче чиратта, – татар милләте формалашу процесслары барышында этник төркемнәр арасында барган катлаулы эчке каршылыкларны күрсәтеп торучы мөһим фактлар. Шуңа бәйле рәвештә, без бу әсәрләрне татар халкы менталитетын, тарихи процесслардагы үзенчәлекле эчке үсеш-үзгәрешләрне ачыклаучы мөһим чыганаклар дип бәяли алабыз.

**Әдәбият**

*Абрамзон С.М.* Этнографические исследования С.Е. Малова // Тюркологический сборник 1975. М.: Наука (ГРВЛ), 1978. С. 12–25.

*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.

Из истории формирования этнографических групп и диалектов татарского народа: в 2-х частях / сост. и авт. предисловия Ф.Ю. Юсупов. Казань: Ихлас, 2014. Т. 1. Ч. 1. 560 с. (Серия «Памятники научной мысли»).

*Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества Археологии, Истории, Этнографии при Казанском университете. Т. 1У. Казань: Типография Казан. ун-та, 1885 г. 12 с.

*Кормушин И.В., Насилов Д.М.* О жизни и творчестве С.Е. Малова // Тюркологический сборник. 1975. М., 1978. С. 5–11.

*Малов Е.А.* Сведения о мишарах. Историко-этнографический очерк //Известия Общества Археологии, Истории, Этнографии при Казанском университете. Т. IV. Казань: Типография Казан. ун-та, 1885. 79 с.

*Малов С.Е.* «Изъ поездки къ мишарям» (О наречии мишарей Чистопольского уезда). – Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1904. 24 с.

*Милибанд С.Д.* Биобиблиографический словарь отечественных востоковедов с 1917 г. М., 1995. 702 с.

https://tatarica.org/tat/razdely/religiya/hristianstvo/personalii/malov-evfimij-aleksandrovich.

*Убрятова Е.И.* С.Е. Малов – крупнейший исследователь тюркских языков // Календарь знаменательных и памятных дат на 1970 г. Якутск, 1970. С. 18–22.

***Батталова Алсу Дамир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*фәнни оештыру бүлеге баш белгече*

УДК 002

*Г.Р. Мирдиянова*

# МАТЕМАТИКА БУЕНЧА 1917 ЕЛГА КАДӘР КУЛЛАНЫЛЫШТА БУЛГАН ТАТАРЧА ДӘРЕСЛЕКЛӘР

В представленной статье рассматривается один из компонентов татарской книги второй половины XIX – начала XX в., связанный с реформой татарской школы и развитием новометодного образования.

Актуальность темы обусловлена развитием естественнонаучного образования в Поволжье и в Республике Татарстан, в частности. Изучение письменного наследия татар по математическим и естественнонаучным наукам позволит использовать богатый опыт предков в создании новых учебных книг.

Особое внимание в статье уделено рассмотрению рукописного наследия татар по математическим наукам. Освещены фонды Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского КФУ, где хранятся древние рукописи и старопечатные книги.

Автором изучены документы Государственного архива Республики Татарстан, старопечатные издания книгохранилищ научной библиотеки Казанского Федерального университета, Национальной библиотеки Республики Татарстан, Института языка, литературы и искусства АН РТ.

**Ключевые слова:** Татарская учебная книга, татарская учебная книга по арифметике, татарская учебная книга по геометрии, татарская учебная книга по алгебре, новометодное образование татар, мектебе, медресе.

This article investigate one of the components of the Tatar book of the second half of the 19th – early 20th centuries, associated with the reform of the Tatar school and the development of new methodology.

The relevance of the topic is due to the development of natural science education in the Volga region and in the Republic of Tatarstan, in particular. The study of the written heritage of Tatars in mathematics and natural sciences will allow to use the rich experience of ancestors in the creation of new textbooks.

Particular attention in the article is given to the consideration of the manuscript heritage of the Tatars in the natural and mathematical sciences. The funds of the Scientific Library named after N. I. Lobachevsky of KFU, where ancient manuscripts and old printed books are stored. The author has studied the documents of the State Archive of the Republic of Tatarstan, old-printed editions of book depositories of the scientific library of Kazan Federal University, the National Library of the Republic of Tatarstan, the Institute of the Language of Literature and Arts of Academy of sciences of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** Tatar study book, Tatar arithmetic study book, Tatar geometry study book, Tatar algebra study book, new-method education of Tatars, Mektebe, madrassah.

Татар халкы үсешендә мөһим факторларының берсе булып, Урта Идел буенда табигать һәм математика фәннәре буенча белем бирү формалашу тора. Бу төбәктә белем таралуга, барыннан да элек, болгарларның ислам динен кабул итүе зур йогынты ясый. Нәкъ менә

шуннан соң татарларның иҗтимагый-мәдәни тормышында үзгәрешләр башлана. Көнчыгыш мөселман дөньясы илләре, Һиндстан, Кытай һәм Фарсы дәүләте белән тыгыз сәүдә, финанс-икътисади һәм мәдәни элемтәләр Идел Буе Болгарының куәтле дәүләт буларак формалашуына ярдәм итә. Мәдәни элемтәләр, мәктәп һәм мәдрәсәләр челтәре рәвешендә тармаклы мәгариф системасы барлыкка килү төбәккә гарәп-мөселман дөньясының фәнни белемнәре үтеп керүгә, математика һәм табигый фәннәр буенча дөньякүләм танылган үз галимнәребез барлыкка килүгә китерә [Мингазов, с. 5].

Татарстан Республикасы китапханәләре һәм фондларында (Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) саклана торган XVIII–XIX гасырга караган гарәп һәм фарсы кулъязмалары Идел буе татарларының математика фәннәре үсешенә ачык характеристика бирә [Арабские рукописи…]. Әйтик, КФУ фондларында бөек галимнәр арасыннан Әбү Гали әл-Басри (965–1039), Шәмсетдин әс-Сәмәрканди (1250–1310), Насреддин Тусиның (1201–1274) математик трактатларының кулъязмалары саклана. Аларда Евклидның «Геометрия башлангычлары» тәнкыйтьләнгән геометрия законнары тасвирлана. Урта гасырларда әлеге геометрик зурлыклар һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы антик өйрәнүләрне эшкәртү, барыннан да элек, сан төшенчәсен киңәйтүгә кагыла. Евклид китабында каралган теорияләр Урта гасырлар мөселман математикларының игътибарын IX–X йөзләрдә үк җәлеп итә. Әбү Гали әл-Басриның «Китабе фи хәлл шукук уклидәс вә шәрхе мәгәних» фәнни трактатында («Евклидның «Геометрия башлангычлары»ның мәгънәсен аңлату») хезмәтендә туры линияләр, әйләнәләр һәм яссы фигуралар геометриясе буенча яңа мәгълүматлар китерелә; сан үзлекләре карала; өслекләр һәм геометрик формалар өйрәнелә [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 103].

Насретдин Тусиның фән дөньясында «Тәхрире Уклидәс» буларак танылган «Китабе тәхрир ысуле-хәндәсә әл-мәнсуб илә Уклидәс әс-Сури» хезмәтендә комментарийлар һәм өстәмәләр белән Евклид «Башлангычлар»ының тәрҗемәсе бирелә [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 1695]. Анда автор состав мөнәсәбәтләре теориясен җентекләп бәян итә.

Танылган математик Баһаветдин әл-Әмилинең «Хөләсат әл-хисаб фи гыйльме әл-хисаб» («Арифметика асылы») исемле трактатының күпсанлы кулъязмалары аерым игътибарга лаек. Трактатта 10 бүлек бар, анда бөтен һәм вакланма саннар, геометрик формалар һәм яссылыклар мәйданы һ. б. карала [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 979].

Фонд кулъязмаларының нөсхәләре арасында шулай ук Хәсән бине Мөхәммәд ән-Нәйсәбуриның «Әр-рәсем әш-шәмсия фил-хисаб» («Арифметика буенча рисалә шәмсия») исемле мөһим трактаты бар [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 1055] Биредә арифметика нигезләре, бөтен һәм вакланма саннарны исәпләү принциплары, саннарны

дәрәҗәгә күтәрү, фигуралар мәйданы һәм күләме, алгебра методы белән мәсьәләләр чишү, кубик тамыр белән эш итү тасвирлана.

Алгебрада исәпләү Гыйсмәтулла бине Әгъзам бине Габдеррәсүлнең «Дәбит кавагыйд әл-хисаб» («Арифметика кагыйдәләре системасы») кулъязмасында карала [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 98]. Хезмәт биш өлештән тора, анда үз аңлатмалары булган математик кагыйдәләр җыелмасы, арифметика һәм алгебра буенча мәгълүматлар керә.

Борһанеддин әл-Бәдҗәлинең «Мөфид әл-хисаб лил-мөбтәдиррәгыйб» китабы математика нигезләре белән беренчел танышу өчен язылган [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 110]. Аерым бүлекләр кушу, алу, тапкырлау, бүлү, тамыр белән эш итү, пропорциональ саннарга багышланган.

Югарыда телгә алынган әсәрләргә күпсанлы комментарийлар да бар: Шәмсетдин әс-Сәмәркандиның «Әшкәл әт-тәэсис» дип аталган геометрия буенча хезмәтенә [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 820]; Баһаветдин әл-Әмилинең «Хөләсат әл-хисаб» («Арифметика асылы») математик хезмәтенә [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 105]; Хәсән ән-Нәйсәбуриның «Рәсалә шәмсия филь-хисаб» [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 123] һәм Гыйсмәтулла бине Гәбдеррәсүлнең «Дәбит кавагыйд әл-хисаб» [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 113]; Ибн әл-Йәсәминең алгебра буенча «Әл-йәсәминий» шигъри әсәренә [КФУ НБЛ ОРРК, сакл. бер. 1703].

Урта Азия, Төркия һәм Идел буенда язылган һәм бүгенге көндә ТР учреждениеләрендә саклана торган математика фәненә караган әлеге һәм башка кулъязмалар Идел буе татарларында математик фәннәрнең югары дәрәҗәдә үсеш алуын күрсәтә.

XIX йөзнең икенче яртысында татарларда «җәдиди» (яңа методлы) белем бирүне үстерү белән беррәттән, алдынгы татар педагоглары тарафыннан беренче уку китаплары булдыру омтылышлары ясала. Татар мәгарифенең күпбаскычлы системасын булдыру (башлангыч, урта, югары) география, арифметика, геометрия, табигать белеме, гигиена кебек фәннәрнең башлангыч һәм урта мәктәп, астрономия, анатомия, физика, химия, алгебраның югары мәктәп программасына кертелүен, укучыларның яшь дәрәҗәсенә һәм белем бирү нормаларына туры килә торган яңа дәреслекләр төзүне таләп итә. XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, бер-бер артлы башлангыч, урта һәм югары мәктәп өчен табигать һәм математика фәннәре буенча уку китаплары басыла.

Арифметика буенча дәреслек булдыру өлкәсендә беренче омтылыш татар мәгърифәтчесе, тел белгече, язучы, тарихчы һәм этнограф Каюм Насыйри тарафыннан ясалып, 1873 елда ул арифметика буенча «Хисаплык, ягъни гыйльме хисаб кагыйдәләре яки арифметика вә хисаплык мәсьәләләре» исемле уку китабы чыгара [Насыйри, 1873]. Дәреслеккә теоретик кагыйдәләр һәм балаларның образлы фикерләвенә йөз тоткан 100 дән артык кызыклы мәсьәлә кертелгән.

К. Насыйри, кыю новатор буларак, татар телендә арифметика һәм фәнни терминнарга билгеләмә бирә, беренче тапкыр Европа илләрендә кабул ителгән гарәп саннарын кертә. «Хисаплык» дәреслегендә автор төп арифметик гамәлләрне – сумманы («җыю»), аерма («аеру»), тапкырлау («сугу»), бүлүне («бүлү») аңлата, аерым арифметик гамәлләр өчен саннар язу кагыйдәләрен һәм образларын китерә. Бирелгән таблицалар исә материалны яхшырак үзләштерергә булыша. Әлеге хезмәт 1899 елда Казанда басыла. Материалның җиңеллеге, татар терминологиясен куллану, дәреслекнең эчтәлеге аның «Мөгаллимнәрә нәмунә» укыту-методик программасына (1906 һәм 1907 елларда) кертелүенә һәм 2–4 нче сыйныфларның уку планында озак кулланылуына сәбәп була [Мөгаллимләрә..., 1906; 1907].

XIX гасыр ахырында яңа методлы белем бирү үсеше белән бергә, яңа методик дәреслекләр булдыру идеясе бөтен Россия татарлары арасында тарала. Бакчасарайда иҗтимагый-сәяси эшлекле, мәгърифәтче, педагог һәм нәшир Исмәгыйль-бәй Гаспринский татар башлангыч мәктәбе өчен дәреслекләр җитмәүне тоеп, татар грамотасы, арифметика, география, тарих һәм белем бирү нигезләре буенча башлангыч белемнәрне үз эченә алган уникаль дәреслек булдырырга тели. 1889 елда ул «Хаҗәи сыйбъян» («Балалар укытучысы») исемле уку китабы чыгара [Гаспринский, 1889]. Китап-ярдәмлек башлангыч мәктәп укытучысына адресланып, иң элек укучыларны грамотага өйрәтүдә, аннары арифметика һәм табигать белеме буенча башлангыч белем бирүдә таяныч була. Автор фикеренчә, башлангыч мәктәптә уку процессын бала кыска гына вакыт эчендә уку, язу һәм арифметик гамәлләрне үзләштерә алырлык итеп, бик рациональ рәвештә оештырырга кирәк. «Берәр сәгать укудан һәм язудан соң ярты сәгатен арифметикага багышласа, укучы өчен бик файдалы булачак», – ди ул [Гаспринский, 1889, б. 39].

Уку материалына саннарны өйрәнү, аларның дөрес язылышы, 100 эчендә кушу, алу, тапкырлау, бүлү кебек төп арифметик гамәлләр, югарыда күрсәтелгән гамәлләргә гади мәсьәләләр чишү кертелә. Һәр дәрес контроль сораулар белән үрелеп бара. Автор фикеренчә, «Хаҗәи сыйбъян» дәреслеге ярдәмендә Бакчасарайның бер мәдрәсәсе шәкертләре 40 көн эчендә китап укырга, язарга, дин һәм арифметика нигезләрен өйрәнә алган [Гаспринский, 1889, б. 1]. Башлангыч мәктәптә дәресләр алып бару һәм укыту программасын төзү буенча үз идеяләрен И. Гаспринский «Рәһбәре мөгаллимин яки мөгаллимнәргә юлдаш» методик кулланмасында бәян итә [Гаспринский, 1898] һәм аның ярдәме белән Россия империясенең башка мәдрәсәләре дә грамотага һәм арифметика нигезләренә өйрәтү системасын үзләштерерләр дип өметләнә.

Алга таба арифметика «Хаҗәи сыйбъян» уку китабыннан мөстәкыйль предмет– «Хисаб мохтәсәр әгъмале хәмсә вә мәсаиле хисабия» [Гаспринский, 1887] буларак аерылып чыга. Анда арифметиканың 4 гамәле кагыйдәләре тулысынча ачыла, чишү өчен күп мәсьәләләр

бирелә. И. Гаспринскийның арифметика дәреслеге 1915 елга кадәр басыла һәм Бакчасарайда да, Идел буенда да уңыш казана.

И. Гаспринский артыннан татар телендә яңа методлы мәктәпләр өчен дәреслекләр төзү эшенә дин һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Баруди керешә. Ул кыска гына вакыт эчендә фәннең төрле тармаклары буенча «Мәгарифел-исламия» («Ислам мәгарифе») дигән яңа методлы мәдрәсә өчен уку китаплары сериясен чыгара. Циклга арифметика буенча «Нәмунәи хисаб» («Исәпләү үрнәге») дәреслеге дә кергән [Баруди, 1891]. Ул 1891 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Уку әсбабында бай теоретик материал – математик терминнарны билгеләү, саннарның дөрес язылышы, төп арифметик гамәлләрнең аңлатмасы бар. Моннан тыш, ул бик күп мисаллар һәм бурычларны үз эченә алган, кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү таблицалары белән тәэмин ителгән. Шунысы игътибарга лаек, әлеге таблицалар арасында математика буенча гарәп телендәге китапларның күпчелегендә очраган «Әбде бәҗвин» тапкырлау таблицасы аерылып тора. Моннан чыгып, Баруди, үз әсбабын булдырганда, башка авторларның Көнчыгыш телләрендә басылган хезмәтләренә дә мөрәҗәгать иткән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Шулай ук үз китапханәсендәге гарәпчә китапларның традицияләре дә сизелә. «Нәмунәи хисаб» дәреслеге 1891–1903 елларда 4 тапкыр нәшер ителә.

Бер елдан соң шул ук типографиядә Гобәйдулла бине Салихның «Ысулы ситтә лил-хисаб» [Салих, 1892] дип аталган арифметика буенча дәреслеге дөнья күрә, анда шулай ук төп арифметик гамәлләр аңлатыла, класслар һәм саннар разрядлары буенча материал урын ала. Материалны яхшы үзләштерү өчен бик күп мисаллар һәм таблицалар («Бабду баджвин», тапкырлау таблицасы) тәкъдим ителә.

Әлеге тармак буенча дәреслекләр булдыру омтылышы Казанда гына түгел, Санкт-Петербург шәһәрендә дә була. Мәсәлән, 1897 елда татар укытучысы Мөхәммәтфатих Мансурый «Әсбабе хисаб» («Арифметика ысуллары») дәреслеген төзи [Мансурый, 1897]. Ул И. Бораганский типографиясендә басылып чыга. Үзенең эчтәлеге буенча кулланма югарыда телгә алынганнарга охшаган, теоретик һәм практик материалны үз эченә алган.

Сабирҗан бине Габделбәдигъ Әл-Казиленең арифметика буенча дәреслекләре башлангыч һәм урта мәктәпләр программаларын исәпкә алып төзелгән. Әлеге дәреслекләр озак вакыт татар башлангыч һәм урта мәктәпләрендә кулланыла, күп тапкырлар яңадан бастырыла (1914 елга кадәр). Арифметика буенча башлангыч мәгълүматлар аның «Бәдрел-хисаб нам китабының мәсафәи әүвәлеседер» [Габделбәдигъ, 1897], китабында урын алган, анда саннар разряды, төп арифметик гамәлләр темалары ачылган. Әлеге уку китабы 1906 һәм 1907 елларда нәшер ителгән «Мөгаллимнәрә нәмунә» методик кулланмасында башлангыч мәктәпнең 2–4 нче сыйныфларында укырга тәкъдим ителгән китаплар исемлегенә кертелә [Мөгаллимләрә..., 1906; 1907].

Китап текстын рамкаларга урнаштыру, эре шрифт, гарәп язуының берничә төрен куллану, таблицалар урнаштыру, китапны башыннан ахырынача көнчыгыш орнаментлары белән бизәү – болар барысы да әлеге басманы элек төзелгәннәр арасында үзенчәлекле итә.

Урта мәктәптә укыту программасында куллану өчен Сабирҗан бине Габделбәдигъ 3 өлештән торган «Кавагыйдел-хисаб» [Габделбәдигъ, 1902] дәреслеген төзи. Беренче өлештә арифметика турында мәгълүмат, икенчесендә – сан, гади һәм унарлы вакланмалар, зурлыкларны үлчәү берәмлекләре, өченчесендә саннан кубик тамыр алу, санны дәрәҗәдәгә күтәрү, пропорция, туры пропорциональ зурлыклар, саннан процент алу турында төп мәгълүматлар китерелә. Әлеге дәреслек ярдәмендә укучыларны «сконто», «сигорта» һ.б. төшенчәләр белән дә таныштырганнар.

Сабирҗан бине Габделбәдигъ аерым «Гамәли хисаб» (Практик арифметика) [Габделбәдигъ, 1914] методик әсбабын мәсьәләләр чишүгә багышлый. Анда 600 дән артык мәсьәлә урнаштырыла. Казан өязенең Мамул авылында яшәүче Мөхәммәд-Зыя Бәхтиярнең «Кавaнинел-хисаб» («Арифметика кагыйдәләре») [Бәхтияр, 1898] дәреслеге арифметиканың теоретик курсын гына тәшкил иткән дәреслекләргә керә. Әлеге уку китабы Әбү Нәкыйбәт әт-Түнтәри мәдрәсәсендә язылган. Әсәрнең Көнчыгыш стилендә бизәлеше, татар телендә дә, гарәп телендә дә дини эчтәлектәге текстларның күп булуы, гарәп терминологиясен, арифметик гамәлләрне чишү, намаз һәм ураза вакытын билгеләү өчен борынгы таблицаларны куллану – барысы да әлеге дәреслекнең иске методлы мәдрәсә өчен язылуын күрсәтә. Аерым бүлек намаз вакытларын һәм ураза вакыты җитүне аңлатуга багышланган. Дәреслек битләрендә китерелгән «Рубг мөҗиб» («Чирек таблицасы») график схемасы укучыларга төш вакыты башлануны, кояш чыгу, кояшның 12 йолдызлык билгесенә керүен һ.б. билгеләргә ярдәм иткән. Әлеге схема белән эш С. Барудиның «Әл-галәмел-мансур фил-гамәли бир-рубгид-дустур: рубге мөҗәйәбе рәсме» китабында тәфсилләп аңлатылган.

Гомәр Дәүләтъяровның «Мөкәммәл хисаб» [Дәүләтъяров, 1898] уку китабы арифметиканың тулы курсы булып санала. Ул ике өлештән тора. Беренче өлештә, 4 арифметик гамәл турындагы төп белешмәләрдән тыш, комплекслы саннар һәм алар белән гамәлләр турында теоретик материал бирелә. Икенче өлештә вакланмалар һәм унарлы вакланмалар, алар белән гамәлләр, тригонометрия кагыйдәләре, процентлар, урта арифметик саннар, саннарны дәрәҗәгә күтәрү һәм пропорцияләр турында бүлекләр бар. Дәреслектә, кагыйдәләрдән тыш, мисаллар да бик күп. Оренбург губернасы Татар Каргалысы авылыннан Гомәр Габдрахман улы Дәүләтъяров – үз заманының мәгърифәтле шәхесләреннән. Оренбург губернасының яңа методлы мәктәпләренең берсендә математика, астрономия һәм яңа аваз методы белән укыткан. Ул, шулай ук, хатын-кызлар белеме тарафдары

びуларак, Татар Каргалысы авылында хатын-кызлар өчен яңа мәктәп ачу инициаторы да була [Рахимкулова, с. 80].

XX гасыр башында нәшер ителгән башлангыч мәктәп өчен математика буенча тәүге уку китапларының берсе – Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучысы Шаһидулла Вахитовның «Гыйльме хисаб вә аның мәсаиле» («Арифметика фәне») [Вахитов, 1901] дәреслеге. Ул, төп арифметик гамәлләрне ачучы теоретик материалдан тыш, 500 дән артык мәсьәлә һәм мисалны үз эченә ала. Китапның икенче басмасында (1911) төрле зурлыклар һәм вакыт турында мәгълүмат өстәлә, гарәп терминологиясе татар терминологиясе белән алышына.

Ш. Вахитов артыннан арифметика буенча дәреслекләр һәм мәсьәлә җыентыкларын полиграфист, каллиграф, рәссам, көнчыгыш һәм төрки телләр белгече Мөхәммәд Идрисов төзи. Ул – язучы һәм китап сатучы И. Идрисов нәселеннән. М. Идриси Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, «Милләт» типографиясендә (Казан) бер үк вакытта җыючы, гравер, инженер-механик һәм мөдир вазифаларын башкара. Мәскәү, Германия шәһәрләре типографияләрендә квалификациясен күтәрә. Ул махсус башлангыч мәктәп өчен арифметика буенча «Хисаб зиһни» (1905) [Идрисов, 1904] һәм «Хисаб гамәли» (1906) [Идрисов, 1910] дип аталган дәреслек һәм практикум оештыра. «Хисаб зиһни» уку китабында төп арифметик гамәлләр темалары ачылган. Китапта беренче булып параграфлар билгеләнә, «өй эше» төшенчәсе кертелә, саннар һәм номерлар калын шрифт белән аерып күрсәтелә. М. Идрисовның дәреслеге «Мөгаллимнәрә нәмунә» кулланмасында башлангыч мәктәпнең 2 нче сыйныфы өчен тәкъдим ителә. «Хисаб зиһни» 4 тапкыр бастырыла.

1908 елда И.Мостафаның «Мәктәбе ибтидия өчен хисаб кагыйдәләре» [Мостафа, 1908] дигән уку китабы чыгарыла. Анда төп арифметик гамәлләр белән беррәттән, төп үлчәү берәмлекләре һәм зурлыклар, акча берәмлекләре һәм Россия империясендә кабул ителгән акча төрләре турында хәбәр ителә. Геометрик фигуралар турында да мәгълүмат бар. Өйрәнелгән кагыйдәләр мәсьәләләр чишү белән ныгытыла. Дәреслек 1910 елда яңадан нәшер ителә.

Гасыр башында Оренбург укытучысы, язучы Зыя Насыйри «Хисаб мөгаллиме» дигән исем белән башлангыч һәм урта мәктәп өчен арифметикадан уку китаплары бастыра. «Хисаб мөгаллиме: ибтидаи мәктәпләр өчен» [Насыйри, 1908] дәреслегенең беренче өлеше төп арифметика гамәлләренә, «Хисаб мөгаллиме: рөшди сыйныфлар өчен» («Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен арифметика») (1909) дип аталучы икенче өлеше вакланмалар, төп һәм катлаулы саннарга багышланган.

Таҗетдин Ибраһимның «Мөгаллиме хисаб» («Арифметика укытучысы») [Ибраһими, 1908] дәреслекләре бары тик урта мәктәпнең арифметика һәм алгебра программаларын исәпкә алып төзелгән. Дүрт бүлектән торган бу хезмәтнең «Мөгаллимә хисаптан 1 нче җөз:

мәдхәлә кәсер» дип исемләнгән беренче бүлегендә (1908) саннарның төрләре (тулы, вакланма, җөп, так, уңай, тискәре һ. б.), арифметиканың дүрт гамәле, бүленүчене табу, санны дәрәҗәгә күтәрү, төрле зурлык берәмлекләре һ. б.) турында мәгълүматлар китерелә. «Мөгаллим хисаптан 2 нче җөз: кәсер» («Арифметика укытучысы»ның икенче бүлеге: вакланмалар») (1909) вакланмалар темасына багышланган. «Мөгаллим хисаптан 3 нче җөз: тәнасеб» («Арифметика укытучысы»ның өченче бүлеге: пропорцияләр») дип аталган бүлектә пропорцияләр, аларның төрләре, үзлекләре, урта пропорциональ сан, процент турында мәгълүмат бирелә, «кредитор», «бурычлы», «капитал», «вексель», «валюта» һ. б. терминнар аңлатыла. «Мөгаллиме хисаптан 4 нче җөз: рәфгъ вә тәҗзир» («Арифметика укытучысы»ның дүртенче өлеше: санны дәрәҗәгә күтәрү һәм тамыр алу») (1911) дип аталган бүлектә исә дәрәҗәгә күтәрү, квадрат һәм кубик тамыр алу һ.б. турында мәгълүмат бирелә.

Арифметика дәреслекләре арасында шулай ук татар журналисты, нашир һәм төрле фәннәр буенча күпсанлы китаплар авторы Якуб Хәлилинең «Гамәли вә нәзари ысулы хисаптан 2 нче җөз»е дә («Арифметиканың практик һәм теоретик курсы. 2 бүлек») [Хәлили, 1909] бар. Ул атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлый, соңыннан үзе дә шунда укыта. Күп еллар «Сөембикә», «Балалар дөньясы» кебек татар журналларында мөхәррир булып эшли, китап басуда актив катнаша. Бүгенге көндә безгә Якуб Хәлили язган уку китабының икенче өлеше генә билгеле. Бәлки беренче өлеше башлангыч мәктәпкә исәпләнгән булгандыр, әмма без аны таба алмадык. «Гамәли вә нәзари ысулы хисаптан нче җөз» китабында математика буенча урта мәктәп материалы аңлаешлы итеп бирелә: «вакланмалар», «санны дәрәҗәгә күтәрү һәм тамыр алу», «квадрат һәм кубик тамыр алу», «пропорция» темалары аңлатыла. Кушымта рәвешендә төрле темалар буенча 80 гә якын мисал һәм мәсьәләләр бирелә.

1910 елда Габдулла Фәхриның «Гамәли вә нәзари гыйльме хисаб» («Арифметика фәненең практик һәм теоретик курсы») [Фәхри, 1910] хезмәте дөнья күрә. Материалны яхшырак үзләштерү өчен, схема һәм таблицаларның бик күплеге китапның үзенчәлеге булып тора. Кулланма башлангыч һәм урта мәктәпнең барлык материалын үз эченә ала.

Нуриәхмәт Вәлишев һәм Гомәр-Ислам Хәбировның уртак хезмәте – «Хисаб» [Вәлишев, Хәбиров, 1910] шулай ук аерым игътибарга лаек. Анда арифметиканың теоретик һәм практик курсы берләштерелә. Н. Вәлишев озак еллар «Хөсәения» мәдрәсәсендә математика укытучысы булып эшләгән (1908–1924). Мәдрәсә программасын исәпкә алып, ул Г. Хәбиров белән берлектә башлангыч һәм урта мәктәптә сигез елга исәпләнгән дәреслек төзи. Дәреслек өч өлештән тора. Беренче өлеш 100 гә кадәр булган саннар белән гамәлләргә, икенче өлеш – 1000 гә кадәрге саннар, төрле системаларның үлчәм берәмлекләренең үзара бәйләнеше, төзелмә саннарга һәм кубик

тамыр алуга багышланган. Өченче өлештә вакланма кагыйдәләрен, алар белән эш итү, арифметик һәм геометрик прогрессия, пропорция, процент, исәпләү, вексельләр турында мәгълүмат бирелә.

Канцелярия исәпләүләре белән эшләү алымнарын үзенең «Исәпләү кагыйдәләре» [Рәфыйк, 1910] кулланмасында «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучысы Гобәйдулла Габдрахман улы Рәфыйков карый. Китапта канцелярия исәпләүләре белән эшләү буенча теоретик һәм практик материал тупланган.

1912 елда Габделварис Габделкадыйрның «Тәсһилел-хисаб» («Арифметиканы җиңеләйтү») [Габделварис, 1912] дәреслеге чыга. Китап сораулар һәм җаваплар рәвешендә язылган арифметик кагыйдәләрне үз эченә ала. Кагыйдәләр аңлатмалар һәм мисаллар белән бирелгән. Әмма мөстәкыйль күнегүләр өчен мәсьәләләр һәм мисаллар юк.

1875 елда, геометрия буенча беренче уку китабы буларак, Казан университеты типографиясендә көнчыгыш белгече – тюрколог, тел белгече, этнограф һәм археолог, Казан уку округы инспекторы Василий Радлов тарафыннан эшләнгән дәреслек дөнья күрә  [Начальная геометрия...]. Китап урта мәктәп программасы буенча теоретик материалны үз эченә алган. Уку китабы ахырында сызымлы таблицалар урнаштырылган. Бу дәреслек татар укытучылар мәктәпләрендә, әйтик, Оренбург татар укытучылар мәктәбендә кулланылышта булган.

1895 елда Каюм Насыйри тарафыннан татар телендә геометрия буенча уку китабы булдырыла. Элегрәк без аның арифметика буенча уку китабы төзегәнен искә алган идек инде. Табигать фәннәре буенча татарча дәреслекләр җитмәүне һәм балаларның акыл сәләтен арттыруда геометриянең мөһимлеген аңлап һәм әлеге дисциплинаны укытуның 10 еллык тәҗрибәсенә нигезләнеп, К. Насыйри «Истиляхәт гыйльме һәндәсә» («Яхшыртылган геометрия фәне») [Насыйри, 1895] уку әсбабын чыгара. Бу хезмәттә гарәп терминологиясен кулланып, геометриянең башлангыч курсы бәян ителә. Кулланманың кереш өлешендә фәндә кабул ителгән терминнар һәм кирәкле инструментлар исемлеге китерелә. Китапның ахырында бөтен курс буенча булган материалны яхшырак үзләштерергә ярдәм итүче сызымнар һәм схемалар урнаштырыла. «Истиляхәт гыйльме һәндәсә» дәреслеге 2 елдан соң, 1897 елда, Казанда кабат нәшер ителә.

XX гасыр башында татар мәктәпләре өчен геометрия дәреслекләре арасында рус механигы һәм математик, Мәскәү университеты профессоры Август Давыдов китабын да билгеләп үтәргә кирәк. Аны татар теленә Габдрахман Мостафа тәрҗемә итә. Китапның «Мәхтәсәр һәндәсә» [Давыдов, 1907] исемле беренче басмасы 1907 елда дөнья күрә. Кулланмада башлангыч геометрик мәгълүматлар урын ала, «туры сызыклар», «нур һәм почмак», «фигуралар», «өчпочмакның яклар һәм почмаклары арасындагы нисбәт», «пространство», «әйләнә» һ. б. темалар ачыла. Һәр параграфта иллюстрацияләр, сызымнар һәм схемалар бар. Дәреслек урта мәктәпнең 3–4 сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителә.

1908 елда татар журналисты, халык мәгарифе эшлеклесе Габдулла Гыйсмәти геометриясе буенча уку әсбабы нәшер итеңә. 1907–1913 елларда Габдулла Төхвәтулла улы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә табигать фәннәре һәм математика укыта. Ул – татар теле, тарих, табигать белеме һәм геометрия буенча күп кенә яңа методлы дәреслекләр авторы. XX гасыр башында математик һәм табигать фәннәре буенча татар уку китапларының бик аз булуы аны дәреслекләр төзүгә этәрә. Балаларны математика фәннәренә өйрәтүдә геометриянең мөһимлеген аңлап, ул «Гамәли вә нәзари ысулы һәндәсә» («Практик һәм теоретик геометриянең төп нигезләмәләре») [Гыйсмәти, 1908] уку әсбабын төзи. Әлеге хезмәткә нигез итеп рус, төрек һәм гарәп авторларының геометрия буенча китаплары алынган. Теоретик өлештән тыш, биредә бик күп мәсьәләләр китерелә. Кулланманың кереш өлешендә автор геометрияне өйрәнүнең мөһимлеген ассызыклый һәм Ибне Халдун һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең бу фәнне укыту зарурлыгы турындагы сүзләрен дә китерә.

Дәреслеккә геометрия курсының төп темалары кертелгән. Һәр бүлектән соң үз-үзеңне тикшерү өчен мәсьәләләр бирелгән. Күрсәтмә сызымнар һәм схемалар булу материалны яхшырак үзләштерергә ярдәм иткән. Дәреслек 1912 елда нәшер ителгән «Мөгаллимнәрә нәмунә» программасында тәкъдим ителә торган уку китаплары исемлегенә кертелгән [Мөгаллимнәрә..., 1912].

Теорияне генә түгел, ә күнегүләр өчен мәсьәләләрне дә үз эченә алган тагын бер геометрия дәреслеге – Мөхәммәт Рәфыйкый-Каргалыйның «Нәзари вә гамәли һәндәсә: татбикать өчен мәсьәләләр белән» («Теоретик һәм практик геометрия: күнегүләр өчен мәсьәләләр белән») [Рәфикый-Каргалый, 1914]. Әлеге уку китабы шулай ук геометриянең башлангыч белемнәрен, аның төп темаларын, «туры сызык», «почмакларны үлчәү», «параллель турылар», «дүртпочмаклар һәм күппочмаклар», «әйләнә» һ.б. ачып бирә.

Математика фәннәре буенча дәреслекләр арасында алгебра буенча дәреслекне дә аерып карарга кирәк. Алгебра югары татар мәктәбендә уку программасына кергән. Шулай итеп, 1917 елда «Госмания» мәдрәсәсе программасы буенча без бу дисциплинаның уку планына кертелүен күзәтәбез. Аны мәдрәсәнең 3–4 нче сыйныфларында өйрәнгәннәр [Уфадагы беренче..., 1917]. Мондый төрдәге уку китабының беренче төзүчесе Таһир Ильясов була. Тумышы белән Саратов губернасыннан, Таһир Әхмәтҗан улы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала, квалификация күтәрү максатыннан гарәп илләрендә, шул исәптән Мисырда да була. 1907–1922 елларда «Мөхәммәдия», «Хөсәения» мәдрәсәләрендә һәм Көнчыгыш академиядә (Казан) гарәп теле, борынгы һәм заманча гарәп әдәбияты, гарәп математикасын укыта. Көнчыгыш академиясендә профессор вазифасын башкара. Дәреслекнең беренче басмасы 1910 елда Казанда «Гыйльме җәбер» («Наука алгебры») [Ильясов, 1910] исеме астында дөнья күрә. Аңа «алгебраик билгеләр һәм гыйбарәләр», «алгебраик гамәлләр»,

«алгебраик вакланмалар», «дәрәҗәгә күтәрү», «тамыр алу», «тигезләмәләр» һ.б. темалар кергән. Мәсьәләләр чишүгә аерым темалар багышланган. Әлеге уку китабының икенче басмасы 1915 елда чыга.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Татарстан Республикасы фондларында саклanучы математика фәненә караган татар уку китаплары (кульязма һәм басма) Идел буе татарларында математика фәннәренең югары дәрәҗәдә үсеш алуын күрсәтә. XIX гасырның икенче яртысында Идел төбәгендә таралган «җәдиди» юнәлеш татар мәгариф системасына зур үзгәрешләр кертә һәм өр-яңа татар уку китаплары төзүгә ихтыяҗ тудыра. Шуңа нисбәтән, татар мөгаллимнәре алдына математика фәннәренә караган татар телле дәреслекләр төзү бурычы да куела. Алдынгы карашлы татар укытучылары, галимнәре тарафыннан бер-бер артлы математика, геометрия һәм алгебра фәннәре буенча уку китаплары төзелә. Гомумән алганда, 1873 елдан алып 1920 елга кадәр математика фәннәре буенча 64 исемдә һәм 108 басмада 102700 данә тираж белән (24 басма тиражы билгеле) уку китабы нәшер ителә. Алар арасында алгебрадан 2 атама һәм 3 басмада – 2000 данә тираж белән; арифметикадан 46 атама һәм 86 басмада – 86 900 данә тираж белән (18 басмасы билгеле); геометрия буенча 13 атама һәм 16 басмада –11 800 данә тираж белән (3 басмасы билгеле).

**Әдәбият**


Арабские рукописи по астрономии и математике в фондах Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского / сост. М.Н. Идеатуллин; науч. ред. Б.А. Розенфельд. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1987. 46 с.

*Баруди Г.* Нәмунәи хисаб (= Образец счета). – Казан: Казан ун-ты матбагасы, 1891. 24 б.

*Бәхтияр М.* Каванинел-хисаб (= Правила арифметики); наш. М. Бакиров. 1 нче бас. Казан: Казан ун-ты матбагасы, 1898. 88 б.

*Вахитов Ш.* Гыйльме хисаб вә аның мәсаиле (= Наука арифметики. Арифметические задачи) / нашире Г. Хөсәенов. Оренбург: Г.И. Кәримов матбагасы, 1901. 102 б.

*Вәлишев Н., Хәбиров Г.* Хисаб (= Арифметика). Казан: Г. Ибраһимов һәм шәрикәт: И.Н. Харитонов матбагасы, 1910. 52 б.

*Габделбәдигъ С.* Бәдрел-хисаб нам китапның мәсафәи әүвәлеседер (= Начало арифметики). СПб.: И. Бораганский вә ширкәте ташбасмаханәсе, 1897. 80 б.

*Габделбәдигъ С.* Гамәли хисаб (= Практическая арифметика). Казан: «Мәгариф» матбагасы вә нашире, 1914. 88 б.

*Габделбәдигъ С.* Кавагыйдел-хисаб (= Правила арифметики). Кис. 1. Казан: «Мәктәбәтеш-ширкә», 1902. 198 б.

*Габделварис Г.* Тәсһилел-хисаб (= Облегчение арифметики) / нашире Габдерәхим ахун. Казан: «Милләт» матбагасы вә нашире, 1912. 39 б.

*Гаспринский И.* Рәһбәре мөгаллимин яки мөгаллимләргә юлдаш (= Руководство для учителей). Бакчасарай: «Тәрҗеман» газетасы ташбасмаханәсе, 1898. 32 б. Крымско-татар. яз.

*Гаспринский И.* Хаҗәи сыйбиян (= Учитель детей). Бакчасарай: «Тәрҗеман» газетасы басмаханәсе, 1889. 80 б.

*Гаспринский И.* Хисаб: мохтәсар әгъмале хәмсә вә мәсаиле хисабия (= Арифметика: 5 основных действий в сокращенном виде и задачи). Бакчасарай: «Тәрҗеман» газетасы басмаханәсе, 1897. 46 б.

*Гыйсмәти Г.* Гамәли вә нәзари ысуле һәндәсә (= Практическая и теоретическая геометрия). Казан: «Сабах» ширкәте: Казан ун-ты матбагасы, 1908. 60 б.

*Давыдов А.Ю.* Мохтәсар һәндәсә (= Сокращенная геометрия) / тәрҗ. Г. Мостафа. Казан: «Мәгариф» матбагасы вә нашире: И.В. Ермолаева матбагасы, 1907. 83 б.: рәс.

*Дәүләтьяров Г.* Мөкәммәл хисаб (= Полный курс арифметики). Кис. 1. Казан: Бертуган Кәримовлар матбагасы вә нашире: Б.Л. Домбровский матбагасы, 1898. 80 б.

*Ибраһими Т.* Мөгаллиме хисаб (= Учитель арифметики). Казан: Бертуган Кәримовлар матбагасы вә нашире, 1908. 70 б.

*Идрисов М.* Хисаб гамәли (= Практическая арифметика). Кис. 1. Казан: «Милләт» матбагасы вә нашире, 1910. 58 б.

*Идрисов М.* Хисаб зиһни (= Интеллектуальная арифметика). Казан: И.Н. Харитонов матбагасы, 1904. 26 б.

*Ильясов Т.* Гыйльме җәбер (= Наука алгебры). Кис. 1. Казан: «Мәгариф» матбагасы вә нашире, 1910. 136 б.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 103 ар., 104 ар. Абу Али аль-Басри. Китаб фи халл шукук китаб Уклидас ва шарх мааних.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 105 (I) ар., 105 (II) ар. Шарх хуласат аль-хисаб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 1055 ар. Хасан ибн Мухаммад ан-Найсабури. Ар-рисалят аш-шамсия филь-хисаб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 110 ар. Бурханеддина аль-Баджали. Муфид аль-хисаб лиль-мубтадир-Рагиб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 113 ар. Мухаммад ат-Таханави. Шарх дабит каваид аль-хисаб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 123 ар. Шарх ар-рисалят аш-шамсия филь-хисаб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 1695 ар., 107 ар. Насреддин Туси. Китаб тахрир усуль аль-хандаса валь-хисаб аль-мансуб ила Уклидас ас-Сури.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 1703 ар. Мухаммад аль-Мардини. Ат-тухфат аль-Мардиния фи шарх аль-Йасаминийа.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 820 ар., 97 ар., 106 ар. Кади Задэ ар-Руми. Шарх Ашкал ат-тасис.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 979 ар., 2066 ар., 1056 ар., 1200 ар., 3392 ар., 734 ар., 1711 ар. Бахаутдин аль-Амили. Хуласат аль-хисаб фи илм аль-хисаб.

КФУ НБЛ ОРРК. Сакл. бер. 98 ар. Исматулла ибн Азам ибн Абдаррасул. Дабит каваид аль-хисаб.

*Мансурый М.* Әсбабе хисаб (= Способы арифметики). СПб.: И. Бораганский вә ширкщте ташбасмаханәсе, 1897. 30 б.

*Мингазов Р.* Развитие естественнонаучного образования народов в Среднем Поволжье и Приуралье (в период с X до нач. XX века): монография в 2-х кн. Книга 1. Казань: Изд-во ТГГИ, 2001. 408 с.

*Мостафа И.* Мәктәбе ибтидаия өчен хисаб кагыйдәләре (= Правила арифметики для начальной школы). Казан: «Мәгариф» матбагасы вә нашире: И.В. Ермолаева матбагасы, 1908. 44 б.

Мөгаллимләрә нәмунә (= Руководство для учителей) / Казан мөхбире. Казан: Типо-литография Императорского Университета, 1906. 20 б.

Мөгаллимләрә нәмунә (= Руководство для учителей) / нашире К. Хәнәфи. Казан: Ермолаева матбагасы, 1907. 32 б.

Мөгаллимнәрә нәмунә (= Руководство для учителей). Уфа: Кәримов, Хөсәенов вә ширкәте матбагасы: «Шәрык» матб., 1912. 9 б.

*Насыйри З.* Хисаб мөгаллиме (= Учитель арифметики). Казан: Бертуган Кәримовлар матбагасы вә нашире, 1908. 39 б.

*Насыйри К.* Истиляхате гыйльме һәндәсә: [чертежлар] (= Улучшенная наука геометрии: [чертежи]). Казан: Казан ун-ты басмаханәсе, 1895. 24 б.

*Насыйри К.* Хисаплык ягъни гыйльме хисаб кагыйдәләре яки арифметика вә хисаплык мәсьәләләре (= Учебник по арифметике, правила и задачи по арифметике). 1 нче басма. Казан: Казан ун-ты матбагасы1873. 52 б.

Начальная геометрия на русском и татарском языках. Ч. 1. Планиметрия / пер. В.В. Радлов. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1875. 119 с., 7 табл.

*Рахимкулова М.* Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России: страницы истории татарских школ в России. Оренбург: Пресса, 1998. 217 с.

*Рәфикый-Каргалый М.* Нәзари вә гамәли һәндәсә (= Теоретическая и практическая геометрия: с задачами для упражнения). Кис. 1. Казан: Бертуган Кәримовлар матбагасы вә нашире, 1914. 111 б.: рәс.

*Рәфыйк Г.* Счет кагыйдәләре (= Правила счета). Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1910. 22 б.

*Салих Г.* Ысуле силтә лил-хисаб (= 6 основных положений арифметики). Казан: Казан ун-ты матбагасы, 1892. 42 б.

Уфадагы беренче мәсҗид җамигъ хозурындагы мәдрәсәи Госманиянең мөфассал программы (= Подробная программа медресе Гусмания в Уфе) / нашире мәдрәсә идарәсе. Уфа: «Тормыш» матбагасы, 1917. 96 б.

*Фәхри Г.* Гамәли вә нәзари гыйльме хисаб (= Практический и теоретический курс науки арифметики). Казан: И.Н. Харитонов матбагасы, 1910. 181 б. (Юл көтебханәсе; чыг. 12).

*Хәлили Я.* Гамәли вә нәзари ысуле хисаб (= Практический и теоретический курс арифметики). Казан: «Сабах» шир.: И.Н. Харитонов матбагасы, 1909. 78 б.

***Мирдиянова Гөлшан Разиф кызы,***
*Казан федераль университеты*
*Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәсенең*
*Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге китапханәчесе*

УДК 371.334

***Л.Г. Гыйләҗева,***
***Г.В. Һадиева***

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ САЙЛАП АЛУ СИТУАЦИЯСЕНЕҢ АКТУАЛЬЛЕГЕ

В статье рассматривается вопрос «ситуации выбора» как основа ситуативной доминанты обучающегося в новом образовательном стандарте. В статье описываются актуальность использования и проектирования «ситуации выбора» на уроках родного (татарского) языка, предлагаются разновидности учебных ситуаций с конкретными примерами.

**Ключевые слова:** ситуация выбора, личностные универсальные учебные действия, педагогические условия, проектирование урока.

In the article we discuss the issue of the choice situation as the basis of the situational dominant of the student in the new educational process. The choice situation should correspond to the five pedagogical conditions that are analyzed in this article. The article also describes the special moments in designing the «situation of choice» at the lesson of native (Tatar) language, such as students readiness for choice, the pedagogical appropriateness of creating a choice, the arguments of their choice, etc.

**Keywords:** situation of choice, personal universal educational activities, pedagogical conditions; lesson design.

Ситуатив якын килү – яңа белем бирү стандартларын тормышка ашыруда төп таләпләрнең берсе булып тора. Белем бирү процессында уку ситуацияләре – билгеләнгән максатка ирешүнең дидактик чаралары. Бүгенге көндә сайлап алу ситуацияләренең кулланылышы аеруча актуаль. Әлеге эшчәнлекнең үсеше (эчтәлек, метод, ысул, укытуның оештырылу формалары, эшчәнлекнең контроле һәм бәяләрне дә кертеп) укучыны шәхес буларак формалаштыруда әһәмиятле корал булып тора.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары укыту процессында төп игътибарны укучы шәхесенең үсешенә юнәлтә [Гыйләҗева, Һадиева, 2019, б. 72]. Яңа стандартта төп белем бирү программасының үзләштерелү нәтиҗәсе булып универсаль уку гамәлләре [Гыйләҗева, Һадиева, 2018, б. 320] карала, алар арасында исә шәхескә караган универсаль уку гамәлләре мөһим гамәллардән санала. Шәхесне формалаштыру баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлак нормаларын аңлавына һәм кабул итүенә, аның әйләнә-тирәсендәге бар нәрсәгә шәхси караш булдыруга, дөрес һәм аңлы рәвештә сайлый белүгә юнәлтелгән. Ә моңа ирешү өчен уку процессына махсус формалаштырылган уку ситуацияләре кертү сорала.

Сайлау ситуациясе – бер вариантка өстенлек бирү дигән сүз ул. Сайлап алу вариантлары – альтернатива (франц. alter) – «яхшырак,

кирәгрәк дип тапканны яки теләгәнне эзләү, карау яисә аерып алу» [Татар теленең ..., б. 848].

Сайлап алу проблемасы психологиядә [Леонтьев, Пилипко, 1995] хәзерге вакытта гаять актуаль булып тора, чөнки бүгенге көндә күп мәгълүмат булу кешене сайлау алдына куя, монда исә бары тик анык формалашкан кыйммәтләр системасын, сайлауның мөмкин булган нәтиҗәләрен аңлаган кеше генә дөрес фикер булдырырга сәләтле.

Уку ситуациясе – укучыларның укытучы ярдәмендә үзләренең эшчәнлек предметларын табып, аларны төрле уку гамәлләре башкарып өйрәнә, тикшерә торган уку-укыту процессының махсус берәмлеге. Укытучы укучылар алдына проблеманы куеп, куелган проблеманың асылын үзе яхшы аңларга, аны чишү юлларын белергә, шулай ук балаларның ничек җавап бирүләрен фаразларга һәм проблеманың чишелеш юлларын, алгоритмын төзү процессында укучылар алдында туган кыенлыкларда ярдәм итәргә әзер торырга тиеш. Уку ситуациясе өчен эчке (белем һәм күнекмәләр) һәм тышкы (дәреслек, сүзлекләр һ.б.) эш чаралары булу зарур. Укучыларда предмет буенча башлангыч (база) белем, күнекмәләр булу, мөстәкыйль эшләү осталыгын, күтелгән нәтиҗәләрнең әһәмиятлелеген аңлау һәм фикер йөртү конструкциясен үзгәртү сәләте – уку ситуациясенең төп таләпләре. Уку ситуациясе барлыкка килү өчен түбәндәге шартлар булырга тиеш:

– укучы яңа белемнәрне үзләштерү өчен программа материалын яхшы белергә тиеш;

– мөстәкыйль эшли һәм фикер йөртергә сәләтле булырга тиеш;

– проблемалы бирем укучы «ачарга» тиеш булган яңа белемне (теманы) үз эченә алырга тиеш;

– үти алмаган практик бирем нигезендә укучыда яңа теманы өйрәнү ихтыяҗы туарга тиеш;

– укучы көтелгән нәтиҗәләрнең белем һәм күнекмәләр булдырудагы кыйммәтен аңларга тиеш.

Уку ситуациясе укучыларның укытучы белән диалогы аша белемнең иҗади үзләштерелүен тәэмин итә. Әлеге юл танып белү һәм коммуникатив универсаль уку гамәлләрен үстерергә, белем алуның югары сыйфатын булдырырга, укучыларның интеллект һәм иҗади сәләтләрен нәтиҗәле үстерергә һәм актив шәхес тәрбияләргә ярдәм итә. Дәрестә уку ситуациясен тудыру проблемаларын ачыклау, аның чишелеш юлларын табу, мәгълүмат белән эшли белү, башка кешеләрне ишетә һәм тыңлый белү, төркемдә эшли белүгә юнәлтелгән.

Сайлап алу ситуациясен ничек оештырырга? Әлеге төр эшчәнлекне кулланып үткәрелгән дәрес укучылар тарафыннан үзләштерелсен һәм технологик яктан дөрес булсын өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк: «сайлап алу ситуациясе» төшенчәсен билгеләргә, аны булдыру өчен педагогик шартларны ачыкларга, укытучыга үзенең һәм укучыларның эшчәнлек алгоритмын төзергә, укучыларның

индивидуаль һәм коллектив рәвештә сайлап алу шартларын, сайлап алу ситуациясен булдыру өчен кулланыла торган укыту биремнәренең төрле төрләрен тасвирларга һәм системалаштырырга, мәсәлән, тестлар, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлдерелгән биремнәр, рольле уеннар, тикшеренү эшләре. Тест биремнәренең исә түбәндәге төрләре методик яктан уңышлы санала. Тест биремнәренең төрләре һәм мисалларына тукталып китик.

1. **Бер яки берничә дөрес җавапны сайлап алу:** *Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне билгеләгез.*

1) *гамьсез;*
2) *төклетуралларга;*
3) *тәмле;*
4) *китап.*

**2. Бер генә дөрес җавапны сайлап алу:** *Билгеләнгән сүзнең синонимын табыгыз.*

*Аларның* ***саф*** *сулары тәнгә сихәт, җанга шифа булсын, алар турындагы җырлар ерак елларгача яңгырасын.*

1) *пычрак;*
2) *изге;*
3) *тәмле;*
4) *чиста.*

**3. Ачык типтагы биремнәр**: *15 нче җөмләдән әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне табып языгыз.*

Җавап: ___________________________.

**4. Тәңгәллекне булдыру:** *Тәңгәллек урнаштырыгыз.*

| | |
|---|---|
| 1. *Омонимнар* | А. *Яшь – карт* |
| 2. *Синонимнар* | Ә. *(Печән) чаба – (тиз) чаба* |
| 3. *Антонимнар* | Б. *Сөйкемле – мөлаем* |
| 4. *Паронимнар* | В. *Болытлы (көн) – кояшлы (көн)* |
| | Г. *Тугры – туры* |
| | Д. *Орфоэпия – дөрес әйтелеш.* |

**5. Дөрес эзлеклелек урнаштыру**: *Текст барлыкка килсен өчен, тиешле эзлеклелек булдырыгыз.*

А) *Алар Евразиядә һәм Төньяк Америкада яшиләр.*
Ә) *Шуның белән урманга зур файда китерәләр.*
Б) *Бүре – ерткыч хайван.*
В) *Бүреләр авыру хайваннарны тоталар.*

1) *Б, Ә, А, В*
2) *Ә, Б, А, В*
3) *Б, А, В, Ә*
4) *А, Ә, Б, В*

Укыту процессында «сайлап алу ситуациясен» проектлаштырганда, түбәндәге моментларны исәпкә алырга кирәк:

1. Укучыларның сайлап алу эшчәнлегенә әзер булулары. Дәрестә әлеге ситуация белән эшли башлаганчы, укучыларны үз мөмкинлекләреннән чыгып сайлый белергә өйрәтә башларга кирәк, бу исә укучыларда сайлау процессын аңлы рәвештә башкару күнекмәсен формалаштырырга ярдәм итәчәк. Һәр дәрес саен сайлау өчен вариантлар арттырыла. Укучы чишә торган мәсьәләләр, биремнәр катлауландырыла, укучыларның мөстәкыйльлегенә карата булган таләпләр үсә бара.

2. Сайлап алу ситуациясенең педагогик кыйммәте. Әлеге ситуация укытучы тарафыннан дәрестә булырга тиешле бер этап (элемент) өчен генә кертелми, ә билгеле бер максат белән кулланыла. Укытучы сайлап алу ситуациясенең кайсы дәрестә, дәреснең кайсы этабында һәм нинди теманы үзләштергәндә нәтиҗәле булачагын алдан билгеләргә тиеш.

3. Укучыларны сайлауга стимуллаштыру. Бу максат белән укытучы сайлап алырга тәкъдим ителгән һәрбер уку биремнәрен анык итеп аңлата, аларның үтәлешенең әһәмиятлелеген ассызыклый, бәяләү критерийларын күрсәтә.

4. Дәлилләү. Укучыларның ни өчен теге яки бу төргә өстенлек бирүләрен дәлилләп аңлатып бирә алуларын булдырырга кирәк.

5. Сайлауның иреклелек дәрәҗәсен билгеләү. Тәкъдим ителгән ситуациядә сайлауның иреклелек дәрәҗәсе уйланган булырга тиеш.

6. Эшчәнлекнең уңышлылыгы. Уку биремнәренең вариантларын тәкъдим иткәндә, укытучы (әлеге биремнәрне уңышлы башкарып чыгу өчен) укучыларның белем һәм күнекмә дәрәҗәсен билгели белергә тиеш.

7. Хаталар өстендә эш. Укытучы укучының бөтен эшчәнлек процессын анализлап чыгып, хата җибәрелгән этапны «эләктереп», аңа хата җибәрелүенең сәбәбен аңлатырга тиеш.

8. Укучы тәкъдим иткән вариантның чишелеш нәтиҗәләрен бәяләү. Сайлап алынган вариантның чишелеш нәтиҗәләрен бәяләгәндә, соңгы нәтиҗәне генә бәяләп калмыйча, укучының бөтен эшчәнлеген тулаем карап анализ бирү уңышлы булачак. Шулай итеп, балага тәкъдим ителгән сайлап алу хокукы бүгенге көндә белемгә омтылучан, сәләтле, мөстәкыйль, эшкә иҗади якын килеп, дөрес карарлар кабул итә белүче, рухи һәм физик яктан сәламәт, көндәшлеккә сәләтле, нәтиҗәлелеккә омтылучан иҗади шәхесләр тәрбияләргә ярдәм итәчәк.

**Әдәбият**

*Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В.* Туган (татар) тел дәресенең заманча модельләре (белем һәм күнекмәләрне системалаштыру дәресләре) // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах): Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 72–74.

*Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В.* Федераль дәүләт белем бирү стандартлары: башлангыч мәктәптә комплекслы эшләр // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. С. 119–123.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

*Леонтьев Д.А., Пилипко Н.В.* Выбор как деятельность: личностные детерминанты и возможности формирования // Вопросы психологии. 1995. № 1.

***Гыйләҗева Лилия Гыйльметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы*

УДК 78.089.8

*Г.Ф. Юнысова*

# ҖӘҮДӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ
## (композиторның тууына 110 ел тулу уңаеннан)

В статье уделено внимание деятельности композитора Дж. Файзи. С помощью метода сквозного рассмотрения материалов представлен обзор его жизненного и творческого пути. Дана оценка событий его биографии и анализ отдельных музыкальных явлений в контексте современных реалий. При создании работы автор опирался на материалы периодической печати, статьи и монографии по разным вопросам культуры, публикациям самого композитора. В научный оборот впервые введены новые данные из различных архивов.

**Ключевые слова**: Джаудат Файзи, музыкально-сценические произведения, татарский фольклор, фонограф, песенное творчество композитора, музыкальная журналистика, радиопередачи, литературно-художественное наследие.

The article focuses on the composer J. Faizy’s activities. Using the method of cross-cutting materials, an overview of his life and career is presented. An assessment of the events of his biography and analysis of individual musical phenomena in the context of modern realities are given. When creating the work, the author relied on materials from periodicals, articles and monographs on various cultural issues, publications of the composer himself. For the first time, new data from various archives have been introduced into scientific circulation.

**Key words:** Jaudat Faizy, musical and stage works, Tatar folklore, phonograph, songwriting of the composer, musical journalism, radio broadcasts, literary and artistic heritage.

Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты Җәүдәт Харис улы Фәйзи (1910–1973) XX гасырның беренче унъеллыгында дөньяга килгән композиторларның берсе. Татар музыкасын иҗат итүчеләрнең әлеге плеядасына С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Н. Җиһанов керә. Алар милли композиторлар мәктәбен булдыруга үзләреннән зур өлеш керттеләр, тулаем алганда республиканың музыка мәдәниятен торгызуга булышлык күрсәттеләр. Беренче татар балетын иҗат иткән композитор Ф. Яруллин да туган-яшәгән еллары (1914–1943) буенча аларга якын тора. Ул, санап үтелгән музыкантлар белән бергә, Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый[1]. Әмма ул Бөек Ватан сугышы чорында фронтта һәлак булып, тормыштан иртә китүе аркасында, музыка өлкәсендәге эшчәнлеген тулысынча гамәлгә ашырырга өлгерми кала. Бу музыкантларның барысының дөньяга килүләренә гасырдан артык вакыт узды

[1] Н. Җиһанов шушы югары уку йортында белем ала.

инде. Әмма бүгенге көнгә кадәр аларның күп кенә әсәрләре кульъязма хәлендә кала бирә, аларның кечкенә бер өлеше генә компакт-дискларга язылган, шуңа күрә тыңлаучыларның киң даирәсенә түгел, белгечләргә дә аз билгеле. Ф. Яруллинның, А. Ключаревның, З. Хәбибуллинның тормышы һәм иҗаты турындагы хезмәтләр куен дәфтәре форматында 1960, 1962 һәм 1975 елларда нәшер ителде. Әмма Җ. Фәйзи турында хәтта андый китап та юк. Әлеге композиторлар арасында Җ. Фәйзи, мөгаен, күптөрле эшчәнлеге белән аеруча аерылып торгандыр. Бу – совет дәүләтенең иҗтимагый-сәяси тормышына бәйле вазгыять белән дә, аның шәхесенә хас үзенчәлекләр белән дә, үзе эшләгән оешмалардагы вазифаи бурычларының төрлелеге белән дә аңлатыла. Җ. Фәйзи әллә ни озак яшәми, әмма табигате белән гаҗәеп эшлекле кеше булуы аркасында бик күп нәрсәләр эшләп калдырырга өлгерә. Җ. Фәйзи әйләнә-тирәсендәгеләргә үзе турында: «Эшләмәсәм, мин авырый башлыйм», – дия торган була. Ул актив тормыш позициясе, бөтен эштә дә янып торуы белән аерылып тора. Бу хәтта аның төрле комитетлар һәм советлар эшендә катнашуына да кагыла, күпләр өчен аларда әгъза булу – номиналь күренеш[1]. Аның эшчәнлегенең өч өлкәсе бүгенге көнгә кадәр зур кызыксыну уята: 1) музыкаль әсәрләре; 2) матур әдәбият һәм музыка журналистикасы әсәрләре; 3) фольклор буенча хезмәтләре. Ул иң элек беренче татар музыкаль комедиясен иҗат итүче һәм 200 вокаль әсәр авторы буларак билгеле. Бу мәкалә композиторның тормышы һәм иҗатындагы хәлләр-вакыйгалар арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштырып, эшчәнлегенең төп өлкәләрен, аерым әсәрләрен кыскача анализлап, әдәбиятта билгеле бер дәрәҗәдә Җ. Фәйзи буенча бушлыкны тутыру максатын куеп язылды.

Булачак композиторның нәкъ менә балалык һәм үсмерлек елларында төрле сәләт һәм мавыгулары ачыла, соңыннан алар музыкаль эшчәнлектә дә чагылыш таба. Шуңа күрә аның тормышының әлеге чорына мәкаләдә аерым игътибар бирелә. Ул 1910 елның 4 гыйнварында Оренбургта Харис Зариф улы Фәйзуллин гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисе Хөсәения мәдрәсәсендә эшләгән, шулай ук газеталарда мөхәррирлек иткән[2]. Үз заманында Харис Россиядә һәм Төркиядә укыган [Фәйзи, 1987, б. 371]. Мәдрәсә мөгаллиме буларак, ул төрле фәннәр – татар теле, география, тарих, физика, медицина буенча үз авторлыгында яки рус һәм төрек телләреннән тәрҗемә итеп, берничә китап бастырып чыгарган. Җ. Фәйзи рус уку йортларында (Бардин гимназиясе, Т. Шевченко исемендәге мәктәп), М. Калинин исемендәге җидееллык татар мәктәбендә белем эстәгән.

[1] Җ. Фәйзи – ТР Композиторлар берлеге идарәсе әгъзасы һәм рәис урынбасары (1954 –1964), М. Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театрының сәнгать советы әгъзасы, радиотапшырулар һәм телевидение буенча сәнгать советы әгъзасы. Җ. Фәйзи аларга бу оешмалар белән бәйле хезмәтләре өчен сайлана һәм актив хезмәттәшлек итә.

[2] Соңрак Татгосиздатта эшләгән. 1933 елда вафат була.

Әтисе аркасында Җәүдәт Фәйзи туган шәһәрендә күренекле татар язучылары Ф. Әмирхан, Ф. Кәрим, Ш. Бабич, Ш. Мөхәммәтов белән аралашу мөмкинлеге ала. Оренбургта Җ. Фәйзи әдәби иҗат эшенә өстенлек биргән. Бу күп яктан әйләнә-тирә мохит, аралашу даирәсе, шулай ук Фәйзуллиннар нәселендә вербаль (проза һәм шигырь) текстлар язу сәләтенең генетик яктан бирелүе белән аңлатыла. Фәйзуллиннар династиясендә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән иң күренекле шәхес – драматург, шагыйрь һәм публицист М. Фәйзи. Әмма бу нәселнең башка вәкилләре дә публицистик һәм фәнни текстлар, мемуарлар, мәгариф өлкәсенә караган материаллар язып бастыралар[1]. Оренбург җәмәгатьчелегенең игътибарын Җ. Фәйзинең матур әдәбият әсәрләре, аерым алганда, аның 15 яшендә язылган һәм соңрак туган шәһәрендә татар драма театры сәхнәсендә куелган «Күз яшьләре» пьесасы җәлеп итә. Җ. Фәйзи Оренбургтан киткәннән соң да, гомеренең ахырына кадәр әдәби-сәнгать әсәрләре иҗат итүеннән туктамый[2]. 1929 елдан башлап, аның әсәрләрен («Алты бармак» комедиясе, «Хикәяләр» җыентыгы һәм кайбер шигырьләре) бастырып чыгара башлыйлар. Үзенең әдәби сәләтен ул соңыннан музыкага караган эшләрендә дә куллана. Монда «Карәхмәт» һәм «Тапшырылмаган хатлар» опералары либреттоларын (Г. Кутуй повестена нигезләнеп, Җ. Фәйзи музыкасы белән), «Челтәрле яулык» балетын атарга мөмкин. Җәүдәт Фәйзинең музыка белән бәйле иң күренекле әдәби әсәре – «Кызыклы кунаклар» шигъри әкияте (1963 елда Казанда башта татар телендә, аннары 1968 елда Мәскәүдә рус телендә басыла). Ул эчтәлеге буенча – оркестр буенча юлкүрсәткеч, балаларны әлеге коллективның инструментлары белән бик мавыктыргыч формада таныштыра. Мондый форматтагы әсәрләр дөньяда бик сирәк очрый. Аларның аеруча билгелеләре – С. Прокофьевның «Петя и волк» музыкаль әкияте һәм Б. Бриттенның «Путеводитель по оркестру для юношества» әсәре. Берничә дистә еллар дәвамында әлеге өч әсәр Татарстан симфоник оркестрының балалар абонементына кертелде. Инглиз композиторының опусы – чиста музыкаль әсәр, Прокофьев әкияте укучыга һәм оркестрга исәпләнгән, Җ. Фәйзи, дирижерларның үзләренә туры килә торган музыкаль иллюстрацияләр сайларга тәкъдим итеп, әдәби нигез иҗат итә. Соңрак Татарстанның башка музыкантлары тарафын-

[1] Бертуганы Мидхәт Фәйзуллин (медицина фәннәре докторы), композиторның вафатыннан соң, аның турында китап яза, аннан өзекләр вакытлы матбугатта даими басылып тора. Казан дәүләт консерваториясендә белем алган Виктор (бертуганының оныгы), төрле конкурслар лауреаты, Җ. Фәйзи турындагы публикацияләрне инде фәнни нигездә дәвам итә. Башка туганнары да үзләренең күренекле кардәшләре турында сайт булдыру эшенә кушылалар, үзләрендә сакланган материалларны шунда урнаштыралар.

[2] Алар арасында (алда искә алынганнардан тыш): «Моңнар астында» романы, «Ялгышкан» пьесасы, «Аккош» драмасы, балалар өчен «Кырмавы – җан иясе» повесте, 30 шигырь, «Яктылык» поэмасы, ике дистәдән артык хикәя, «Казан яки Безнең заман яшьләре».

нан, «Кызыклы кунаклар» композициясендә бердәм стильгә ирешү максатыннан, Җ. Фәйзи әсәрләренең оркестрлаштырылган фрагментларыннан әлеге әкияткә музыкаль номерлар сайлап алынды. Бу эшне заманча инструментлар составы мөмкинлекләрен исәпкә алып дәвам итәргә кирәк иде.

Оренбургта Җ. Фәйзине кызыксындырган икенче өлкә – музыка сәнгате. XX гасырның 30 нчы елларында ул чын-чынлап шушы өлкә белән мавыгып китә. Бу шәһәрнең музыкаль тормышында Җ. Фәйзинең музыкант буларак җитлегүенә мөнәсәбәте булган ике моментны аерып күрсәтик. Алар җәмгыятьнең өстәмә һәм һөнәри белем бирүне үстерүгә, үзешчән музыка уйнауга, тулаем татар музыка мәдәниятенең торышына мөнәсәбәтле күрсәтмәләре белән бәйле. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Оренбургта XX гасырның беренче чирегендә аерым гаиләләрдә (барыннан да элек зыялы гаиләләрдә) балаларны уку йортларының башлангыч звеноларында да, шәхси тәртиптә профессиональ музыкантларда да төрле музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү традициясе барлыкка килә. Моннан тыш, туганнары балаларга музыка уен кораллары бүләк итә һәм аларда башлап уйнап күрсәтә торган була. Бу, мәсәлән, шул заманда Җ. Фәйзи белән бергә Оренбургта яшәгән композитор А. Ключаревка (виолончельдә, баянда уйнаган), шагыйрь М. Җәлилгә (мандолинаны үзләштергән) кагыла. Җ. Фәйзинең үзенә бәләкәй чагында мандолина тавышы бик нык тәэсир итә. Ул аны беренче тапкыр атаклы язучы Ш. Бабич, аннары мандолиначы И. Һилалов (Илялов) кулында күрә. Харис Зариф улының бертуган сеңлесе (Хәят апа) булачак композиторга һәм аның олы абыйсы Мидхәткә кечкенә мандолина бүләк итә, анда уйнау күнекмәләренә, ноталар өйрәтә. Аннан соң Җ. Фәйзи татар мәктәбендә мандолиначылар ансамбленә (үзенең әйтүенә караганда, «кечкенә оркестр») җитәкчелек итә. Алга таба Җ. Фәйзи буш вакытында бу уен коралын кулына алган (мәсәлән, халык җыры «Каз канаты» темасына вариацияләр) яки ике мандолинада туганнары белән үзенең киң таралган «Урман кызы» җырының көен уйнаган. Әлеге инструменттан тыш, Фәйзуллиннар гаиләсендә скрипка (Җ. Фәйзи аны аларда еш булган атаклы татар композиторы С. Сәйдәшев алып килде дип саный) һәм балалайка да пәйда була. Оренбургта татар спектакльләре антрактларында М. Вәлиевнең фортепьянога кушылып татар халык көйләрен уйнавы аның хәтеренә тирән сеңеп калган[1]. Татар халык көйләрен скрипкада башкара белүе соңрак Җ. Фәйзинең үзенә дә бик нык ярдәм иткән, (истәлекләренә караганда) Түбән Новгород өлкәсендә мөгаллимлек иткәндә хәтта гомерен саклап калган. Бөек Октябрь революциясе алдыннан Оренбург мөселманнары тарафыннан «Музыка һәм драма» җәмгыяте оештырылган. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Оренбургта музыка-агарту киң җәелгән. Бу җәмгыятьнең идарәсенә Җәүдәт Фәйзинең әтисе белән бергә Шәриф

[1] Киләчәктә Мәсәлим Вәлиев – Башкортстан Композиторлар берлегенең беренче рәисе, танылган композитор.

Камал, Фатих Кәрими, Заһид Нуркин кебек күренекле мәдәният эшлеклеләре кергән. Аларның тырышлыгы белән 1918 елда төрки халыклар вәкилләре өчен «Шәрык музыка мәктәбе» ачылган. Ф. Кәрими билгеләп үткәнчә, бу уку йортын җәмәгатьчелек үзенә күрә бер елга итеп караган, аның ярдәмендә кечкенә Көнчыгыш музыкасы күлен зур сәнгать океаны белән тоташтырырга теләгән [Оренбургның…]. Татар халык җырларының әүвәлге нота басмаларының берсе шулай ук Оренбургта әлеге җәмгыять тарафыннан чыгарылган. Шушы мәктәптә Җ. Фәйзи һәм аның энесе Х. Терегулова-Булатовада[1] фортепьянода уйнарга өйрәнгәннәр. Дөрес, бу шөгыль озак дәвам итмәгән, чөнки мәктәп нибары бер-ике ел яшәгән. Уку йортына бу вакытта киләчәктә күренекле татар композиторы булачак С. Сәйдәшев мөдирлек иткән. Оренбургта яшәгән башка кешеләр кебек үк, Җ. Фәйзи дә С. Сәйдәшевне марш жанрында пьесалар уйнаучы («Тукай маршы» һәм «Хәйбуклин») духовой оркестрның трубачы буларак исендә калдырган. Шәһәрнең бөтен җирендә (шул исәптән ачык һавада да), гади тыңлаучыларда һәм белгечләрдә кызыксыну уятып, татар халык җырлары яңгыраган. Кечкенә генә оркестр композиторлар (З. Яруллин) әсәрләрен, труппа спектакльләре концертларында һәм антрактларда фольклор музыкасы эшкәртмәләрен уйный. Ул фронт бригадаларыннан чакырылган артистлардан тора.

Ә Россиянең танылган фольклорчысы А. Затаевич (бу елларда шулай ук Оренбургта яшәгән), төрле халыкларның, барыннан да элек казакъларның, шулай ук татарларның музыка үрнәкләрен җыю белән шөгыльләнгән һәм әлеге эшкә яшьләрне дә (мәсәлән, соңыннан күренекле композитор булган А. Ключаревны) тартырга тырышкан.

1925 елда Җ. Фәйзи гаиләсе Казанга күченә. Монда ул өч елдан соң 2 нче урта мәктәптә тулы гомуми белем алып чыга. Татарстан башкаласында аның техник чаралар белән мавыгуы ачык күренә. Ул Оренбургтагы кебек үк фоторәсемгә төшерүен дәвам итә, һәм аның белән гомеренең ахырынача шөгыльләнә. Аның фотолары шул ягы белән кызыклы: Җ. Фәйзи күбрәк үз заманының танылган әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләрен төшерергә тырыша. Аларда ул, мәсәлән, Казанда – язучы Ф. Әмирханны, ә Уфада (зур булмаган коллектив составында мәдәни программа белән баргач) шагыйрь Ярлы Кәримне соңгы юлга озату процессын гәүдәләндергән. Җ. Фәйзинең иҗади мирасын саклау комиссиясе соңыннан үз планына, һичшиксез үтәлергә тиешле бурычларның берсе буларак, аның фотоархивының тасвирламасын язуны юкка гына кертмәгән. Мәктәп елларында ул радиоһәвәскәрлек белән дә кызыксына башлаган. Бу темага мәгълүмат бик аз булуга карамастан, үзенә һәм дусларына радиоалгычлар җыйган. Искә төшерсәк, Казанда радиостанция нәкъ шул ук вакыт-

[1] Татар музыка белгечләре арасында югары музыкаль белемгә ия булу турында беренче дипломны (Мәскәү дәүләт консерваториясен тәмамлый) нәкъ менә Х. Терегулова ала.

та – 1927 елда ачыла. Бу эшне җиренә җиткерүдә язучы, җәмәгать эшлеклесе Ш.Усмановның тырышлыгы зур була. Җ. Фәйзи аның белән мәктәптә үзе җитәкләгән радиотүгәрәк аша таныша. Радиокомитетта Җ. Фәйзигә кайвакыт танылган җырчыларга, аерым алганда А. Измайловага, фортепьянода кушылып уйнарга туры килгән. Ул шулай ук үзе генә дә (соло) чыгышлар ясый. Шуңа күрә ун елдан соң аның радиокомитетка музыкаль тапшырулар мөхәррире сыйфатында эшкә килүе закончалыклы күренеш була. Җәүдәт Фәйзинең рационализаторлык сәләте соңрак аның фонограф белән эшләвендә чагылыш таба. Ул фоноваликларны язмалардан чистартуның яңа ысулын уйлап таба, бу аларда яңа музыкаль материалларны теркәргә мөмкинлек бирә. Фольклор экспедицияләре вакытында әлеге ысулның файдасы күп булган, валикларны үзең белән азрак алырга мөмкинлек туган, фонографның зурлыгын һәм авырлыгын исәпкә алсак, сәяхәтләрдә багаж сизелерлек кимегән. «Фонографны көйләдем. Валикларны үзем уйлап тапкан ысул белән чистартым. Эдиссонның исен китерерлек булмады булуын, шулай да эшкә ярарлык булып чыкты» [Фәйзи, 1973, с. 15]. Җәүдәт Фәйзинең әлеге мавыгулары, шулай ук аның төрле техник җайланмаларны (тегү машиналарын, дивар сәгатьләрен) төзәтүе, электр үткәрүе, ишек кыңгыраулары куя белүе аркасында, әти-әнисе (бигрәк тә әтисе) малаен техник яки инженер итеп күрергә тели. Җ. Фәйзи берничә тапкыр бу белгечлекләрне бирүче техникумнарга укырга керергә дә омтылыш ясый.

Җ. Фәйзи Казанның мәдәни мохитенә башы-аягы белән чума. Бу да аның иҗади үсешенә бик нык ярдәм итә. Ул Татарстан һәм Россиянең танылган әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең төп контингенты (мәсәлән, В. Маяковскийны) белән таныш була, аларның күбесе белән ул шәхсән аралаша. Танышырга сәбәп чыгып кына тора: егет нәшриятта эшләүче әтисе янында еш була; театрга (шул исәптән, музыкаль куелышларга, мәсәлән, «Сания» операсына, «Наемщик» спектакленә) йөрергә ярата; үзе дә иҗат белән шөгыльләнә.Ул әдәбият-сәнгать әсәрләре язуын да туктатмый һәм, шуңа бәйле рәвештә, Г. Кутуй, Һ. Такташ кебек танылган шагыйрьләргә һәм язучыларга бәяләмә сорап мөрәҗәгать итә. Төрле җыелышларда, әдәби-музыкаль кичәләрдә ул үз эшкәртүендә фортепьянода татар халык җырларын, шулай ук С. Сәйдәшев әсәрләренең көйләрен уйный. Чыгышлары, әлбәттә, күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Студент елларында ук Җ. Фәйзи берничә вакытлы матбугат органы белән хезмәттәшлек итә. Бу аңа танылган кешеләр белән җиңел танышырга һәм аралашырга мөмкинлек бирә. Вакытлар узу белән Җ. Фәйзи язмаларында төп игътибарны музыка сәнгате мәсьәләләренә юнәлтә башлый. (Бу турыда кара: [Файзуллин, с. 46–51].) Соңрак аның матбугатта «Музыка, башкаручы, тыңлаучы» дигән баш астында басылган язмалар циклы (Татарстан яшьләре, 1968) укучыларда зур тәэсир калдыра. Татарстанның танылган музыка белгече Г. Кантор республика вакытлы матбугатына күзәтүендә болай дип билгеләп үтә: «Начиная с 1940-х годов, складывается круг

профессиональных музыкантов, постоянно пишущих о музыке в Казани (анализируется периодика на русском языке). Эти критики, музыковеды, композиторы в течение нескольких десятилетий сохраняли творческую активность и являлись бесспорными неформальными лидерами казанской музыкальной публицистики» [Кантор, с. 282]. Ул алар арасына Җәүдәт Фәйзине дә кертә.

Горький өлкәсе Ишә авылында[1] бер ел укытучы булып эшләгәннән соң, 1929 елда Казан университетына Совет хокукы факультетына укырга керә, аны 1933 елда тәмамлый (бу вакытта инде бу уку йорты мөстәкыйль институт була). Институтта аны аспирантурада һәм гыйльми секретарь итеп калдыралар[2]. Юрист белгечлеге буенча укуы һәм шул ук вакытта әдәбият һәм музыка белән мавыгуы Җ. Фәйзине вакытвакыт дөрес юнәлеш сайлау-сайламавына шикләнеп карарга да мәҗбүр итә. Бу җәһәттән Җ. Фәйзинең Уфада шагыйрь М. Җәлил белән очрашуы (02.08.1930) бик зур роль уйный, ул аның белән Оренбургтан ук таныш була. М. Җәлил аның музыка белән шөгыльләнүен хуплый, ә саубуллашканда әле генә Мәскәүдә нәшер ителгән «Иптәшкә – теләктәшкә» исемле кечкенә генә шигырьләр җыентыгын бүләк итә. Анда түбәндәге юллар бар: «Җәүдәт! Без – бөек көрәшнең иң авыр фронтындагы яшь фронтовиклар. Мин җырым белән, син – музыка белән, барыбызга да уртак булган шушы позицияне яклarбыз. Көрәшләргә көчебезне берләштерик. Шул бердәмлеккә үрнәк итеп шушы төргәкне бирәм. Иптәшең – теләктәшең – М. Җәлил» [Центр...][3].

Җ. Фәйзи тарафыннан иҗат ителгән беренче җырларның (бигрәк тә Һ. Такташ сүзләренә «Урман кызы» һәм «Байрак тегәбез») уңыш казануы аны ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан музыка училищесына алып килә. Ул композиция (педагогы В.Виноградов) һәм музыка тарихы буенча дәресләр ала. В. Виноградов «Урман кызы» җырын бизәүдә актив катнаша (җырның беренче нота язмаларында гармонизатор буларак аның фамилиясен куялар). Болар барысы да Җ. Фәйзинең музыкаль иҗатны сайлавына стимул була. Нәтиҗәдә, 1934 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студиясе оештырылу сәбәпле, Җ. Фәйзи республика хөкүмәте тарафыннан әлеге студиянең уку-укыту бүлеге мөдире итеп җибәрелә һәм аның композиторлар төркеменә кертелә (1938 елның ахырына кадәр шунда

[1] Ул тормышының әлеге чорын «Авыл укытучысы көндәлеге» повестенда чагылдыра.

[2] Җ. Фәйзи алга таба да алган профессиясе, юрист коллегалары белән бәйләнешләрне өзми. Бөек Ватан сугышы елларында ул адвокатлар коллегиясенә алуларын сорап гариза яза һәм ике урында берьюлы эшли [Багаутдинов, с. 125]. 1950 елда, Музыкаль фольклор кабинеты директоры вазифаларын үтәгәндә, Җ. Фәйзи көндәлегендә үзенең бу эшне эшли алуына шикләнеп каравын белдерә. Әмма ул адвокатлык һәм суд тикшерүләре белән фәнни тикшеренүләр арасында аналогияләр таба. Бу аның үз-үзенә ышанычын арттыра.

[3] Гарәп графикасындагы текстны кириллицага Г. Ибраһимов исем. ТӘһТИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Л.Ш. Гарипова күчерде.

эшли). Белгечлеге буенча ул Б. Шехтерда укый һәм өлешчә Г. Литинскийдан консультацияләр ала.

Мәскәүгә киткәнче үк (ә анда бигрәк тә) җыр аның иҗатында беренче әйдәп баручы жанрга әйләнә, һәм ул аннан гомер буе аерылмый. Аның җырларына лирик һәм патриотик, гражданлык яңгырашы хас. Лириканы еш кына «Урман кызы», «Кызыма» җырларындагы кебек эчкерсез, йомшак көй яки «Миләүшә»дәге кебек – гүзәл скерцо тәшкил итә. Җ. Фәйзи җырлары совет җыр сәнгате контекстында туа. Моны төрле тематикага һәм төрле буяулар белән язылган әсәрләрендә күрергә мөмкин. Мәсәлән, 50 нче еллар ахырында Л. Зыкина башкаруында Г. Пономаренконың «Оренбургский пуховый платок» җыры (В. Боков сүзләре) зур популярлык казана. Җ. Фәйзи иҗатында аңа «Оренбург шәле» (С. Хәким сүзләре) җыры туры килә. Татар тыңлаучылары арасында шундый ук популярлык казанган лирик җыр беркадәр халык рухында. Бу – җырчы Ф. Сөләйманова башкаруында аеруча күренә. Композиторның туган шәһәренә дә мәхәббәте һәм хөрмәте биниһая зур була.

Җ. Фәйзи беренчеләрдән булып Һ. Такташ һәм Г. Тукай шигырьләренә җырлар язган дигән фикер бар. Һ.Такташка нисбәтән моның белән килешергә дә мөмкин, әмма Тукай шигъриятен тәүге мәртәбә көйгә салып С. Габәши («Юаныч» җыры) яңгырата. Ләкин Җ. Фәйзи бу шагыйрьнең сүзләренә иң якты, уңышлы һәм әлегә кадәр популяр җырларның берсен – «Бәйрәм бүген»не яза. Ул әлеге жанрдагы Г. Тукай сүзләренә иҗат ителгән күп кенә музыкаль әсәрләрдән (халык һәм профессиональ) шат күңелле, дәртле һәм көчле характерда булуы белән аерылып тора. Билгеле бер дәрәҗәдә ул халык җыры «Пар ат»ка якын. Аларны хәрәкәтчән темп, төп ритмик фигура ε. ξ берләштерә. Еллар узгач, Җ. Фәйзи язган бу әсәрнең йогынтысы Р. Еникеевның «Яңгыр» җырында (Г. Тукай сүзләре) чагылыш таба. Аларны музыканың күтәренке характеры, пунктир ритмы гына түгел, башламдагы көй фразасының якынлыгы да бәйли.

Пар ат




Бәйрәм бүген




Яңгыр



Җ. Фәйзинең «Бәйрәм бүген» җырының мондый позитив рухына аның җыр иҗатының гражданлык, патриотик яңгырашка ия икенче тармагы йогынты ясаган булса кирәк. Композитор Казан чорында ук мондый җырлар иҗат итә башлаган, ә Мәскәүдә аларның саны шактый арткан. Бу җәһәттән студиянең, Мәскәү консерваториясендәге мондый әсәрләр иҗат иткән укытучылар (Б. Шехтер, В. Белый, А. Александров) иҗатының тәэсире сизелә. Бу җыр авторларының барысы өчен дә күптән түгел генә тәмамланган гражданнар сугышы вакыйгалары һәм каһарманнары, шулай ук якынлашып килүче сугышларны алдан тоемлау иҗатка стимул була[1]. Җ. Фәйзи иҗатындагы «Комсомолка Гөлсара», «Гөрләсен безнең җыр», «Кавалерия җыры» шундый җырларга керә. СССР, республика тормышындагы (бигрәк тә героик пландагы) вакыйгаларга җырлар-кайтавазларны композитор гомере буе иҗат итә. Марш жанрындагы беренче җырлары (аларны поход яки строевой җырлар дип тә атыйлар) Мулланур Вахитов («Мулланур»), Бөек Ватан сугышы геройлары Газинур Гафиятуллин («Газинур батыр турында җыр») һәм Зоя Космодемьянская («Зоя турында баллада») турындагы балладалар, Россия пролетариатының беренче юлбашчысы турындагы монолог («Күңелем Ленин белән сөйләшә») алыштыра. Җәүдәт Фәйзи язган шундый җырларның күбесе бүгенге көндә дә мелодика ягыннан кызыклы. Аларның тексты (башка күренекле совет композиторларының шундый ук җырларындагы кебек) Бөек Октябрь революциясеннән соңгы гражданнар сугышы, Кызыл Армия белән бәйле, төрле профессия ияләренә багышланган темаларга кагыла. Шуңа күрә алар шул чор Советлар иле һәм Татарстандагы вакыйгаларның үзенчәлекле музыкаль елъязмасы буларак жанр тарихында калдылар. Кешеләрне һәрвакыт борчыган мәңгелек сюжетларга (мәхәббәт, дуслык, тормыш турында фәлсәфи уйланулар) язылган җырлар тормышчанрак булып чыга. Җ. Фәйзинең җырлары берничә тапкыр бүләкләргә лаек була. «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (С. Хәким сүзләре) 1953 елда Татарстананың Мәдәният министрлыгы, Композиторлар һәм Язучылар берлекләре тарафыннан уздырылган иң яхшы җыр конкурсында икенче премияне яулый. Бу чарага профессиональ һәм үзешчән композиторлар язган 100 гә якын әсәр җибәрелә. 1967 елда Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына Хор җәмгыяте, Профсоюзларның өлкә Советы һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы инициативасы белән «Советский человек – творец прекрасного» девизы астында иң яхшы җырга конкурс үткәрелә. Җ. Фәйзинең «Казан кызы» җыры (Г. Зәйнашева сүзләре) ул вакытта 3 нче премияне ала. Иң зур бүләккә – «Исендә тот, иптәш!» вокаль циклы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә Җ. Фәйзи 1966 елда лаек була.

---

[1] Бу совет кинематографында чагылыш таба. Моның бер үрнәге – Бөек Ватан сугышы башланганчы ук төшерелгән «В шесть часов вечера после войны» фильмы.

Җ. Фәйзинең балалар өчен язган җырлары татар җыр сәнгате өчен яңалык була. Студиянең әдәби бүлеген җитәкләгән М. Җәлил белән берлектә Җ. Фәйзи XX гасырның 30 нчы елларында балалар өчен бик күп җырлар иҗат итә һәм аларны «Балалар альбомы» дип исемләнгән циклга берләштерә. Алар балалар аудиториясендә зур популярлык казана.

1939 елдан Җ. Фәйзи Казанда яши. Ул төрле оешмаларда төрле вазифалар башкара. 1939 елдан 1942 елга кадәр радиокомитетта (Татрадио) музыкаль редактор була, мәдәни-агарту эшчәнлеге белән актив шөгыльләнә. Җ. Фәйзи яшь кадрларны әлеге учреждениедә эшкә җәлеп итәргә омтыла (мәсәлән, соңыннан музыкаль тапшырулар мөхәррире, Татарстан Композиторлар берлеге секретаре булган З. Хәйруллинаны). Ул җырчы Зөләйха Хисмәтуллина, Флера Сөләйманова, керәшен җырларын башкаручы Раиса Тимофееваның иҗатта карьерага ирешүләренә ярдәм итә. Җәүдәт Фәйзигә алар барысы өчен дә рәхмәтле. З. Хисмәтуллинаның тууына 50 ел тулу уңаеннан үткәрелгән кичәдә юбиляр болай дип билгеләп үтә: «Гомеремнең юл башында композитор Җәүдәт Фәйзи булды. Ул минем музыкаль сәләтемә игътибар бирде. Укырга җибәрде. Бәхетле язмышым өчен аңар баш иям. Мең рәхмәт» [Хәйруллина]. Ул оештырган радиотапшыруларның (бигрәк тә халык иҗаты һәм аның башкаручылары белән бәйле) темалары музыкаль публицистика жанрында эшләнә. Җ. Фәйзинең «Музыка кичәләре» китабын музыка турындагы радиотапшыруларның басмада чагылышының таҗы дип санарга мөмкин, анда автор татар телендә җиңел, мавыктыргыч формада музыка сәнгате турында сөйли, кушымтага үзе төзегән кечкенә генә терминологик сүзлекне дә өсти. 1940–1941 елларда радиокомитетта эшләү белән беррәттән, Җ. Фәйзи Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижер булып эшли. Чөнки әлеге вазифаны башкаручы төп хезмәткәр – композитор С. Сәйдәшев 1941 елда Мәскәүдә узачак татар теле һәм әдәбияты декадасын әзерләү өчен чакыртып алына. Мондый эш белән бәйле рәвештә, Җ. Фәйзи төп игътибарын драма театры спектакльләренә музыка язуга юнәлтә. Бу эш 1937 елда ук «Ташкыннар» пьесасын (авторы Т. Гыйззәт) музыкаль бизәүдән башланып китә. Г. Камал исемендәге театрда эшләгәндә, композитор Н. Исәнбәт пьесасы буенча «Хуҗа Насретдин» комедиясенең музыкаль бизәлешен эшли, ул тамашачыларда һәм тәнкыйтьчеләрдә хуплау таба. Җ. Фәйзи үз гомерендә төрле актерлар коллективлары: курчак театры, Республика күчмә театры өчен 30 спектакльгә музыка яза. Әмма музыкаль номерларның күп өлеше Г. Камал исемендәге театр өчен иҗат ителә. Менә аларның кайберләре: «Ташкыннар», «Шәмсекамар», «Шүрәле», «Таймасовлар», «Үги кыз», «Җиз кыңгырау», «Бергә – гомергә» һәм башкалар. Спектакльләрнең күп кенә музыкаль фрагментлары, мәсәлән, «Фатыйма арышлары», Басыйр җыры – «Җырга салып җибәргән хат» («Тормыш җыры»ннан), «Яшә, Хуҗа Насретдин»,

«Сәлви җыры» («Хуҗа Насретдин»нан), Гайнавал җыры («Ташкыннар»дан) мөстәкыйль рәвештә тарала. «Гайнавал җыры»н үз вакытында танылган җырчылар З. Басыйрова (Г.Камал исемендәге театр артисткасы), Г. Сөләйманова башкара. Бүген ул безнең замандаш җырчылар Эльнар Сабирҗанов һәм Алия Карачурина, Айдар Габдинов, Айгөл Бариева репертуарына да кергән. Җ. Фәйзинең мәшһүр әсәрләре исемлегенә Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы белән бәйле рәвештә язылган Гөлшәһидәнең лирик җырын да («Гөлшәһидә җыры») теркәргә кирәк.

Ләкин аңа тыныч кына эшләргә насыйп булмый, чөнки композиторны мәдәният эшлеклеләре бригадасы составында (музыкант Рөстәм Яхин, язучы Гамир Насрый да керә) окоплар казырга җибәрәләр. «Литературная газета»да язучы Г. Кутуйның (телгә алынган бригаданың җитәкчесе) «Эшче һәм композитор» исемле мәкаләсе басылу аркасында гына, татар музыкасының иң яхшы сәхнә әсәрләре өстендә эшләвен дәвам итү өчен, Җ. Фәйзине кире Казанга кайтару мөмкин була. Нәтиҗәдә, 1941 елның гыйнварында республика Югары Советы рәисе Г. Динмөхәммәтов тәкъдиме белән Җ. Фәйзи яңадан Казанга кайта.

Җ. Фәйзи татар сәнгатендә музыкаль комедия жанрын тудыручы булып санала. Аның тарафыннан шундый өч әсәр («Башмагым», «Акчарлаклар» һәм «Идел буенда») язылган. Беренчесе – «Башмагым» арада иң уңышлысы булып чыга. Комедиянең оркестровкасын Ф. Витачек эшли (Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты партитурасының беренче варианты да аныкы), ул сугыш елларында әнисе Е. Гнесина-Витачек белән Казанга эвакуацияләнә, музыка училищесында укыта. Җ. Фәйзинең калган ике комедиясенең сәхнәдә озак уйналмавын либреттоның кимчелекләре, сюжет линиясенә тискәре бәя бирү белән бәйлиләр. «Акчарлаклар»да җыр номерлары артык күп булу сәбәпле, хәрәкәтнең тоткарлануын ассызыклыйлар. «Идел буенда»да уйлап чыгарылган конфликтлылык табыла (гәрчә бу музыкаль комедия 1950 елда СССР Дәүләт премиясенә тәкъдим ителгән булса да). Әмма бу комедияләрдән аерым музыкаль номерлар озак еллар популярлык казана. Алар арасында: Шәмси ариозосы, Зәйтүнә ариясе, Зәйтүнәкәй җыры, Зәйнәп, «Кәккүк», Фәйрүзә ариясе («Акчарлаклар»), Рәмзия ариозосы («Идел буенда»).

Язучы Т. Гыйззәт «Башмагым» либреттосына нигез итеп башкорт авторы Х. Ибраһимовның шул ук исемдәге пьесасын ала. Х. Ибраһимовның бу әсәренә музыканы үз вакытында композитор С. Сәйдәшев язган, әмма бу комедиячел спектакльнең музыкаль бизәлеше генә булган. Җ. Фәйзи исә музыкаль жанрдагы мөстәкыйль әсәр тәкъдим итә. Совет чоры энциклопедияләрендә, танылган режиссерларның хезмәтләрендә аны опереттага кертәләр. Бу спектакльне СССРда үз көчләре белән сәхнәгә кую нәтиҗәсендә, шулай ук М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры гастрольләре аша (мәсәлән, 1965 елда Әстерханда һәм Волгоградта) күп шәһәрләрдә беләләр. Гастрольләр

вакытында репертуардагы классик әсәрләр белән беррәттән Җ. Фәйзинең «Башмагым», Ә. Бакировның «Тальян моны» музыкаль комедияләрен, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетын һәм Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсын да күрсәтәләр. Җ. Фәйзи музыкасы (беренче чиратта, «Башмагым»ныкы), композитор үзе берничә фактор аркасында ерак чит илләрдә дә билгеле була. Бөтенсоюз радиосының чит илләргә хәбәрләр бирүче махсус радиостанциясе 1950–1960 елларда әлеге музыкаль комедияне инглиз, немец һәм француз телләренә тәрҗемәдә әледән-әле яңгыратып тора. Җ. Фәйзинең башка әсәрләре Казан университетында белем алган кайбер чит ил студентлары ярдәмендә таныла. Мәсәлән, Корея Халык Демократик Республикасына Татарстан филармониясе артистлары делегациясе (аның составында Азия һәм Африка илләре белән теләктәшлек комитеты әгъзасы буларак Җ. Фәйзи да булган) килү уңаеннан рәсми кабул итү вакытында бу илнең Мәдәният министрлыгы хезмәткәре (КДУны тәмамлаган) «Урман кызы»н җырлый. Шушы ук җырны РСФСРның халык артисты җырчы Ф. Насретдинов та зур уңыш белән Кытайда, Бирмада һәм Вьетнамда гастроль сәфәрләре вакытында башкара.

Җ. Фәйзи турындагы информацияне төрле чит ил басмаларында бастырганнар. Аерым алганда, Венгриядә үзе исән чагында ук аның хакында һәм башка композиторлар (Н. Җиһанов, Р. Яхин) турында мәгълүматлар урын алган китап нәшер ителә.

1944 елда Татарстан сәнгать эшләре идарәсе тарафыннан Җ. Фәйзи Татар дәүләт филармониясенең директоры һәм сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә, анда ул 1947 елга кадәр эшли һәм иҗат белән шөгыльләнү өчен ялга китә. 1949 елдан 1951 елга кадәр ул Музыкаль фольклор кабинетын җитәкли. Ул ябылганнан соң, яңадан филармониягә сәнгать җитәкчесе итеп чакырыла. 1959 елда иҗат белән шөгыльләнү өчен ялга китү сәбәпле, ул аннан тагын китә. Бу ике оешмада эшләү Җәүдәт Фәйзинең игътибарын хор өчен әсәрләр булдыруга юнәлтә, ул яшь дирижер-хоровиклар, мәсәлән, татар композиторларының әсәрләрен хор өчен эшкәртү белән шөгыльләнә башлаган Әзһәр Абдуллин белән таныша. Соңыннан Ә. Абдуллин аңа 1969 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Татар композиторларының 10 әсәре» дигән хор өчен эшкәртмәләр җыентыгын) бүләк итә. Анда Җ. Фәйзинең солистлар һәм хор өчен язылган «Яз шатлыгы» җыры да кертелгән була. Әлеге учреждениеләрдә Җ. Фәйзи эшенең нәтиҗәсе татар халык җырларының эшкәртмәләрен тудыруда да чагыла.

Алар арасында: «Ай, дуслар», «Ачма тәрәзәңне!», «Идел суы», «Матур булсын», «Рамай», «Сагынам», «Яшә, республикам!», «Кошлар кебек», «Рәйхан» һ.б. Халык сүзләренә Җ. Фәйзи үз музыкасын да иҗат итә. Аларга «Бондюг көе», «Иркәм», «Рекрутлар җыры» җырлары, «Шәмсекамәр» спектакленнән музыкаль номерлар (Разияның икенче җыры, Шәмсекамәрнең бишек җыры) һәм башкалар керә. Хәтта украин халык җыры сүзләренә нигезләнгән әсәр дә бар («Ике лачын»).

Музыкаль фольклор кабинетында эшләгәндә Җ. Фәйзи Татарстанның төрле районнарына һәм аннан читкә (Пермь, Әстерхан, Төмән, Оренбург һәм Тобол өлкәләренә) экспедицияләр оештыра, Казанның эре заводлары һәм фабрикалары эшчеләренең язмаларын туплый. Җ. Фәйзи үзе теркәгән халык музыкасы үрнәкләрен 1973 елда «Халык җәүһәрләре» җыентыгында бастырып чыгара. Аңа хәзерге (шул заман өчен) 235 фольклор үрнәге кертелгән. Ул – информантларны сайлау, язу һәм расшифровкалау шартлары ягыннан караганда, җитди фәнни хезмәт түгел (кайчак материалны теркәү процессында ул хәтта аңлы рәвештә үзгәртелгән). Әмма бүген дә ул үзенең кыйммәтен югалтмаган һәм белгечләрнең игътибарын элеккечә җәлеп итә.

Алга таба да Җ. Фәйзи халык башкаручылары белән актив кызыксына. Ул, алар белән очрашу өчен, яшәгән урыннарына бара, үзешчән сәнгать смотрларында жюри рәисе яки әгъзасы буларак катнаша. Экспедицияләрдә Җ. Фәйзи музыканы фонографка яздыра, аны композиторга кайчандыр танылган баянчы Ф. Туишев бүләк иткән була. Экспедиция барышында Җ. Фәйзи язмаларны тыңлый һәм ноталарга сала, шуннан соң фонографны алдагы көйләрне теркәү өчен «чистарта». Шулай итеп, күп нәрсә техник сәбәпләр аркасында юкка чыгарыла. Әлеге язмалы фоноваликларның бер өлеше әлегә кадәр сакланган. Фольклорчы М. Нигъмәтҗанов шундый тугыз язманың ноталы расшифровкасын ясады, ул аларны 1970 елда татар халык җырлары җыентыгында бастырып та чыгарды. Аның нота транскрипцияләре Җ. Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» китабына кертелгән расшифровкаларыннан аерыла. Җ. Фәйзинең композиторлар цехына керүе фольклор үрнәкләре җыентыгының кайбер язмаларында һәм комментарийларында чагылыш тапты. Мәсәлән, Җ. Фәйзи яздыру барышында информантларның үзләреннән әсәрләрнең төп нөсхәләренә үзгәрешләр керттерә. «Актаныш басмалары», «Матур булсын» кебек җырлар – шуның үрнәге. Кайбер очракларда җырның ритмы һәм, димәк, жанры да үзгәрә. Җ. Фәйзи җырларына комментарийларда башкаручылар турында тулы мәгълүмат юк, анда аларның туган көне һәм әтисенең исеме төшереп калдырылган, аның каравы социаль чыгышы (һөнәре, шөгыль төре) турында мәгълүматлар бар, бу үткән гасырдагы сораштыру өчен хас күренеш (XX гасырның 70 нче елларына кадәр). Фольклор үрнәгенең килеп чыгышы һәм таралу тарихы турындагы мәгълүматлар да кызыклы. Моннан тыш, Җ. Фәйзи композиторларның кайсысы (үзен дә кертеп) теге яки бу халык җырын үз әсәрләрендә файдалануын яки аны эшкәртүен, профессиональ җырчылардан аны кемнең беренче булып үз репертуарына кертүен дә билгеләп барган. Җ. Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» җыентыгы 1987 елда яңадан басылып чыга. Анда наширләр татар халык музыкасы турындагы теоретик өлешне, китапның өченче бүлегендәге шигъри текстларны кыскартканнар. Эчтәлектә фольклор әсәрләре ноталарының төп нөсхәләре төрле критерийлар – тематика, алфавит тәртибе, жанрлар буенча системалаштырылган. Яңа басмада тематик

группировка гына калдырылган. Аның каравы, Җ. Фәйзинең туган көненнән башлап 1933 елга кадәрге тормышын колачлаган «Күңелем кыллары» исемле автобиографик язмалары кертелгән. Мемуарларының беренче китабын композитор 1970–1971 елларда тәмамлый. Аның әлеге халык музыкасы үрнәкләре җыентыгына турыдан-туры катнашы юк, әмма Казан белән Оренбург шәһәрләренең (бигрәк тә музыкаль) мәдәнияте, Җәүдәт Фәйзинең тормышы һәм иҗаты буенча әдәбияттагы бушлыкны күпмедер дәрәҗәдә тутыра.

Җ. Фәйзинең теоретик фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмый. Ул татар халык музыкаль иҗаты жанрлары классификациясен тәкъдим итте, әмма үзенчәлекле характерда булуы аркасында ул белгечләрнең игътибарын җәлеп итмәде. Ләкин вакытлар узу белән этномузыкологлар кайбер мәсьәләләрдә, аерым алганда, кайбер конкрет җырларга (мәсәлән, «Сарман») мөнәсәбәттә, Җ. Фәйзи карашларына таяна башладылар.

Ахырда шуны билгеләп үтәсе килә: Җ. Фәйзи мирасының күп өлеше әлегә кадәр билгеле түгел һәм төрле архивларда таралып ятуын дәвам итә. Композитор вафат булганнан соң, аның иҗади мирасын саклау комиссиясе төзелде. Аңа З. Хәйруллина (комиссия рәисе, Татарстан Композиторлар берлеге рәисе), музыка белгече Г. Касаткина, композиторлар Б. Мулюков һәм И. Шәмсетдинов, дирижер-хоровик Ә. Абдуллин, шагыйрьләр һәм язучылар Г. Минский, С. Хәким һ.б. кергән. Ике өлештән торган чараларның бишьеллык планы булдырылды: 1) музыкаль әсәрләр, фоторәсемнәр, язышуларның тасвирламасын төзү; 2) төрле материаллар бастырып чыгару, композитор турында монография әзерләү. Планлаштырылганнарның бик аз өлеше генә гамәлгә ашырылды: 1987 елда «Халык җәүһәрләре» фольклор җыентыгының яңа басмасы нәшер ителде [Фәйзи, 1987]. Аңа «Күңелем кыллары» истәлекләренең беренче өлеше дә кертелде. Бу комиссия планлаштырган бөтен эшләр бүгенге көнгә кадәр актуаль. Аларга Җ. Фәйзинең экспедицион язмаларының фонографик валикларын цифрлаштыруны һәм алардагы фольклор үрнәкләрен заманча технологияләр кулланып күбәйтүне, бастырып чыгаруны өстәргә кирәк. Шулай ук композитор фондындагы фоторәсемнәрдән альбом эшләргә кирәк. Боларның кыйммәте Татарстанның музыка мәдәнияте кысаларына гына сыймый. Композиторның истәлеген мәңгеләштерү буенча барлык гамәлләрне Г. Ибраһимов исем. ТӘһТИ архивында һәм ТР Милли музее фондында саклаучы материалларга таянып башкарырга мөмкин.

### Әдәбият

*Багаутдинов Ф.Н.* Композитор и юрист (Джаудат Файзи – Джаудат Харисович Файзуллин) // Багаутдинов Ф.Н. Музы и право. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. С. 117–129.

*Кантор Г.* Казань-музыка – XX век. Исследовательские очерки: Изд. дом «Титул-Казань», 2009. 424 с.

Оренбургның моңлы егете // Казан утлары.1987. № 9. Б. 183.

*Национальный* архив РТ. Фонд Р-6663. Оп. 1. Д. 2.

*Фәйзи Җ.* Җырлар эзлим... // Казан утлары. 1973. № 1. Б. 147–160.

*Фәйзи Җ.* Күңелем кыллары // Фәйзи Җ. Халык җәүһәрләре. Күңелем кыллары. Татар халык көйләре. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 199–381.

*Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре. Күңелем кыллары. Татар халык көйләре. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 392 б.

*Файзуллин В.* Литературно-просветительская деятельность Джаудата Файзи // Музыковедение. 2010. № 9. С. 46–51.

*Хәйруллина З.* Тибрәндерде күңел кылларын: [Композитор Җәүдәт Фәйзи тур.] // Шәһри Казан. 2000. 22 дек.

Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Фонд 140.

***Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 793.3

***Н.Д. Мусина***

# ТАТАР БИЮЕ ЭТНОХОРЕОЛОГИЯСЕ БАРЛЫККА КИЛҮ:
## Фольклористиканы үстерү контекстында Гай Таһиров тикшеренүләре

Статья затрагивает область исследования этнохореологии, изучающей этнический танец, проблемы и перспективы её развития, охрану танца как нематериального культурного наследия. Особое внимание уделяется опыту изучения этнического танца татар первым татарским балетмейстером Гаем Тагировым, труд которого положил начало татарской этнохореологии, одного из научных направлений национальной фольклористики. Впервые анализируется татарский фольклорный танец, представляющий хореографическую культуру народа середины XX века, и рассматривается с ориентацией на современные критерии этнохореологии. В результате работы определены направления, по которым исследователи могут продолжить изучение первого базового труда по этническому татарскому танцу, опираясь в дальнейшем на его результаты при разработке новых тем изучения татарского танцевального фольклора.

**Ключевые слова:** этнохореология, татарский танец, фольклористика, Гай Тагиров.

The article touches upon the research field of ethnochoreology, which studies ethnic dance, problems and prospects for its development, the protection of dance as an intangible cultural heritage. Special attention is paid to the experience of studying the ethnic dance of the Tatars by the first Tatar choreographer Gai Tagirov, whose work laid the foundation for Tatar ethnochoreology, one of the research fields of national folklore. For the first time, the Tatar folklore dance is analyzed, representing the choreographic culture of the people of the middle of the 20$^{th}$ century, and is considered taking into account the modern criteria of ethnochoreology. As a result of the work, the directions were determined in which researchers can continue the study of the first basic work on ethnic Tatar dance, relying further on its results when developing new topics for the study of Tatar dance folklore.

**Keywords:** ethnochoreology, Tatar dance, folklore studies, Gai Tagirov.

Этнохореология – фольклористиканың этник биюне өйрәнүче фәнни юнәлеше, аны шулай ук традицион, халык, фольклор биюе, ягъни халык арасында туган һәм яшәгән бию дип тә атыйлар. Ул халыкның пластик-бию телен дә чагылдыра. Россиядә этнохореология XX гасыр башында Ленинград шәһәрендәге Сәнгать тарихы дәүләт институтында барлыкка килә: беренче мәртәбә Рус Төньягына экспедицияләр оештырылып, тикшеренүләр үткәрелә. Аларның нәтиҗәсе буларак, В. Всеволодский-Гернгроссның «Крестьян биюе» [Всеволодский-Гернгросс, 1928] дигән хезмәте дөнья күрә. Институт тарафыннан оештырылган кыр тикшеренүләре нәтиҗәсендә бу

төбәкнең әлеге чордагы традицион хореография культурасының торышы бәяләнә.

Совет чорында этнохореография буенча беренче хезмәтләр XX гасыр урталарында пәйда була. Этнохореология барлыкка килгән һәм үсеш алган чорда Т.А. Устинованың 1976 елда басылып чыккан «Рус биюе лексикасы» дигән тикшеренүе гомумиләштерү характерындагы хезмәт булып тора. Эмпирик материалда этнохореографик тикшеренү ракурсы 1980 елларда үсә башлый. Этнохореология өлкәсенә үзеннән зур өлеш керткән тикшеренүчеләр арасына Аркадий Андреевич Соколовны кертергә мөмкин» [Мациевский, с. 54]. Сиксәненче елларда мәдәният югары уку йортларында фәнни эшчәнлек юнәлешләренең берсе булган СССР халыклары биюләрен өйрәнү буенча тикшеренү эшенә юнәлтелгән югары хореографик белем бирүгә нигез салынганнан соң, этник бию актив рәвештә өйрәнелә башлый. Бу чорда аутентик бию фольклоры җыела, анализлана, халык биюе формалары буенча классификацияләнә, аның функциональ үзенчәлеге өйрәнелә. Этнохореология фәнни мәктәбе һәм аның тикшеренү өлкәсе формалаша. Хәзерге вакытта ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Традицион биюнең барлыкка килүе, үсеше:

• биюнең генезисы (килеп чыгышы);

• календарь һәм көнкүреш йолалары контекстында биюне тасвирлау;

• бию традицияләренең үзара йогынты ясашуы (этносара бәйләнешләр);

• теге яки бу этномәдәни популяциянең бию жанрлары һәм формалары барлыкка килүнең мәдәни-тарихи үзенчәлеген тикшерү һ.б.

2. Этносларның бию культурасын тикшерү теориясе һәм методологиясе:

• биюнең морфологиясен (бию формаларын, структурасын, элементларын) тикшерү;

• биюнең семантикасын (төрле тарихи этапларда биюнең мәгънәсен) тикшерү.

Узган гасыр, һичшиксез, этнохореологиянең фәнни юнәлеш буларак үсеше турында сөйли, ләкин Россиядә һәм аның төбәкләрендә хәл ителергә тиешле проблемалар көн тәртибеннән алынмый. Фольклористиканың үтә нык катлаулы юнәлеше бу, һәм төрле сәбәпләр аркасында бүгенге көнгә кадәр аның фәнни тикшеренүләрне үстерерлек масштабы юк. Шул ук вакытта халыкның мәдәни мирасы буларак бию һәм этнохореологиянең әһәмиятен ЮНЕСКО халыкара оешмасы да ассызыклый, ул 2003 елда Халыкара хокук режимлы документ – Матди булмаган мәдәни мирасны саклау турында конвенция кабул итә. Матди булмаган мәдәни мирас (милли мәдәниятнең җыр, бәйрәм, йола, кыйсса, музыка, костюм, бию һ.б. жанрлары) халыкның төрле чорларда төрле буыннары тарафыннан тудырылган һәм төрле стильләрдәге иҗаты булып тора. Матди булмаган мәдәни мирас буларак биюне саклауның төп нигезләмәләрен Венгрия Фәннәр академия-

сенең Музыка белеме институты этнохореологы, ЮНЕСКО каршындагы Халыкара традицион музыка советының этнохореология буенча тикшерү төркеме президенты Ласло Фельфёлди белдерде: «Охрана» нематериального культурного наследия означает принятие мер с целью обеспечения жизнеспособности нематериального культурного наследия, включая: его идентификацию, документирование, исследование, сохранение, защиту, популяризацию, повышение его роли, его передачу, главным образом, с помощью формального и не формального образования, а также возрождение различных аспектов такого наследия» [Фельфёлди, с. 18]. Венгрия һәм Төркия күп унъеллыклар дәвамында Конвенциядә бәян ителгән система буенча биюне матди булмаган мәдәни мирас буларак саклау белән җитди шөгыльләнә. Ул мирасның әлеге төрен барлыкка китерүдә мәгарифнең, фәнни тикшеренүләр, мәдәни эшчәнлек һәм бию сәнгатенең өлеше зур булуны күздә тотып эш итә.

Россиядә мондый система төзелмәгән. Традицион биюне өйрәнү, саклау, үстерү – әлеге этапта Россиядә һәм төбәкләрдә иң катлаулы проблемаларның берсе:

• этнохореологларның даими нигездә эшләүче фәнни лабораторияләре булмау;

• белем бирүнең барлык дәрәҗәләренең титул милләт биюе буенча үзара бәйләнешле программалар – белем бирүнең барлык дәрәҗәләре өчен мәҗбүри уку дисциплинасы белән тәэмин ителмәгәнлеге;

• районнардагы махсус урта һәм югары уку йортларының һәм мәдәният бүлекләренең хореография фольклоры буенча тикшеренү эшләренә юнәлеш тотмавы;

• профессиональ сәнгатьтә куллану өчен һәркем файдалана алырлык архив материаллары булмау һәм башка күп нәрсәләр киләчәк буыннарны халыкның бию сөйләме турындагы мәгълүматтан гына мәхрүм итеп калмый, ә аның тарихи-сәнгати хәтеренең юкка чыгуына һәм профессиональ сәнгатьтә кризиска китерә.

Татар халкының этник биюе, аның пластик бию сөйләме – диаспораларда һәм локаль этник төркемнәрдә кабатланмас колоритка ия якты күренеш. Һәм ул XX гасырда үзенең төп яшәеш юнәлешләре – фән, сәнгать, мәгариф, авыл мохитендә гамәлдә булу – буенча шактый зур үсешкә ирешә. 2017 елда дәүләт дәрәҗәсендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында»гы законның төбәк өчен әһәмияте гаять зур булды. Ул 2018 елның гыйнварыннан гамәлгә ашырыла башлады. Аны, халык иҗатының иң катлаулы төре буларак, этник биюне исәпкә алып тормышка ашыру, татар биюенең этнохореологиясен үстерү, яклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен уңай нәтиҗәләр бирер.

Фольклористиканың фәнни юнәлеше буларак, татар бию фольклорын өйрәнүне тикшергәндә, аның аеруча күп хезмәт куюны сорый торган юнәлеш булуын билгеләп үтәргә кирәк. Ул этнохореологлар

коллективыннан гаять зур көч куюны таләп итә. Алар, кыр тикшеренүләреннән тыш, халык биюләрен җентекләп документлаштырырга, документларны (фильмнар, фотосурәтләр, интервьюлар, көйләрнең ноталары, билгеле бер система буенча бию язмалары) архивларда сакларга, биюләрне, «мәдәни текстлар» буларак, системалы рәвештә кәгазьдә бастырып чыгарырга, аларның структур типологиясен төзергә, индивидуаль, импровизация жанрларында бию тудыру законнарын билгеләргә, традицион биюләрнең тарихи катламнарын, региональ бүленешен билгеләргә һ.б. тиеш.

Этнохореологлар башкарган тикшеренү эшенең катлаулылыгы шулай ук биюнең күпкомпонентлылыгы белән дә билгеләнә. Ул җыю һәм теркәүне үз эченә алган беренче этапта ук, бию белгечләренең җентекләп эшләве белән беррәттән, музыка белгече, этнограф, авыз иҗатын өйрәнүче һ.б. галимнәрнең дә хезмәтенә мохтаҗ, чөнки биюнең халык арасында яшәве музыкаль аккомпанемент, җыр, инструменталь музыка, милли кием, бәйрәмнәр, йолалар белән аерылгысыз бәйләнгән.

Бүгенге көндә Татарстанда даими системалы нигездә эшләүче галимнәр – этнохореологлар коллективының фәнни лабораториясе юк. Фәнни потенциал Татарстан Республикасында, Россиянең гаять зур территорияләрендә һәм БДБ илләре диаспораларында яшәүче татар халкының бию фольклоры масштабларына бөтенләй туры килми, бу өлкәдәге белгечләр саны бармак белән генә санарлык. Бу уңайдан Венгрия Фәннәр академиясе этнохореологлары төркеме һәм Төркиянең Эгей университетының төрек фольклор биюе бүлегенең эшен мисалга китерергә мөмкин, алар республиканың барлык төбәкләрендә һәм башка илләр белән чиктәш территорияләрдә бию фольклорының яшәешен даими өйрәнәләр, тарихи үсеш процессында андагы үзгәрешләрне күзәтәләр, картага төшерәләр [Озбильгин, с. 41].




Венгрия Фәннәр академиясе йөз еллар дәвамында венгр этник биюләрен өйрәнеп, иң талантлы биючеләрнең берсенең иҗатын гомере дәвамында (берничә ел аралык белән) яздырып барып һәм шуңа багышланган масштаблы хезмәт бастырып, бөтенләй яңа баскычка күтәрелә. Әлеге басмада ир-ат аутентик фольклоры үсеше һәм индивидуаль, импровизация жанрларында бию тудыру бәян итела (фотоны карагыз).

Әлеге китапта бию этник биюне теркәүдә Венгрия этнохореологлары кабул иткән Лабанотация системасы ярдәмендә яздырылган.




XX гасыр дәвамында татар биюе этнохореологиясе нинди юл үткән? Мәсьәләнең тарихына мөрәҗәгать итеп, беренче татар балетмейстеры Гай Таһировның ролен ассызыклап үтәргә кирәк. Ул татар халкы мәдәниятенә бәяләп бетергесез өлеш керткән, киләчәк буыннар өчен профессиональ сәнгатьтә татар биюен өйрәнү, саклау һәм үстерү юлларын билгеләгән.

Татарларның традицион биюен өйрәнүне ул хореография сәнгатенә гашыйк егет, Татар сәнгать техникумы студенты, 1926–1927 елларда Мәскәү, Оренбург, Бохара, Әстерхан, Түбән Новгород, Омск, Чиләбе, Петропавловск шәһәрләрендә Татар дәүләт академия театры (ТДАТ) гастрольләрендә катнашучы буларак башлап җибәрә. Театр гастрольләре кайда гына узмасын, Г.Х. Таһиров «илебезнең теге яки бу төбәгендә яшәүче татарларның бию фольклоры белән кызыксынган, охшашлык һәм аерымлыклар тапкан, драма театры сәхнәсендә кирәк булуы ихтимал һәр нәрсәне исендә калдырган» [Горшков, с. 4]. Г. Таһировның үз халкының биюе белән кызыксына башлавы Сәнгатьләр тарихы институтында барлыкка килгән совет этнохореологиясе белән һичничек бәйләнмәгән. Г.Х. Таһиров, ТДАТның драма артисты булганнан соң, татар биюләренең фольклор нигезенә




Венгрия Фәннәр академиясе этнохореология коллективының биюләрнең структур типологиясенә, аны тудыру законнарына, этник хореография яшәешенең тарихи катламнарын ачыклауга багышланган хезмәте




Фәннәр докторы, Төркиянең Эгей университеты Төркия дәүләт консерваториясенең төрек фольклор биюе бүлеге укытучысы Мехмет Оджала Озбильгинның китабы

таянып, спектакльләргә хореографик күренешләр куя һәм аларда үзе дә катнаша. Татар бию фольклоры белән эшләүдә ул сайлаган юнәлешнең дөреслеген Мәскәүдә үзган Бөтенсоюз милли иҗат олимпиадасы да раслый, «анда «Сания» операсы һәм К. Тинчуринның «Ил» драмасы күрсәтелә, икесенә дә биюләрне Г. Таһиров куя» [Горшков, с. 5].

Татарстанда, татарларның этник биюе белән шәхсән Гай Таһиров кына кызыксынып калмый, республика җитәкчелеге дә халык иҗаты өлкәсендә актив тикшеренүләр башлап җибәрә, татарлар яшәгән төрле төбәкләргә экспедицияләр оештырыла. 1931 елда халыкның музыкаль, вокаль һәм хореографик иҗатын җыю буенча беренче фольклор экспедициясе була. Гай Таһиров комплекслы фәнни экспедиция составында татарларның бию фольклорын өйрәнә башлый. Әлеге тикшеренүләре аның «100 татар фольклор биюе» дип аталган хезмәтенең нигезенә ята. Бу монография – этнохореограф Таһировның 1930–1970 еллардагы этнографик экспедицияләр материаллары белән эшләү нәтиҗәсе. Фольклор биюләренең төп өлеше XX гасырның 40–50 нче елларына карый, алар татар биюен сәхнә өчен эшкәрткәндә һәм аннан соң һәвәскәр коллективлар, Татар дәүләт драма театры, опера һәм балет театры һәм Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен хореографик әсәрләр иҗат иткәндә чыганак ролен үтиләр.

Гай Таһиров әлеге китапта традицион татар биюен беренче мәртәбә терки. Бу – аның этнографик экспедицияләр материалларын расшифровкалау һәм яздыру буенча күп елларга сузылган хезмәте нәтиҗәсе. Анда теркәлгән үрнәкләр Татарстан районнарының гына түгел, Урал һәм Себердәге Пермь, Свердловск, Оренбург, Кемерово өлкәләре татарларының бию фольклоры белән танышырга мөмкинлек бирә.

Һөнәре буенча тикшеренүче булмаса да, Г.Х. Таһиров этнохореография буенча беренче хезмәтләрне әзерләгән кешеләр арасына кергән. Һәм татар этнохореологиясенә үзеннән зур өлеш керткән. Беренче татар балетмейстеры татар халкының этник биюен өйрәнүче тәүге тикшеренүче була. Татар мәдәниятенең барлыкка килүендә һәм үсешендә аның күпкырлы эшчәнлеге гаять зур роль уйный. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында

уздырылган Халыкара фәнни-гамәли конференциядә татар этник биюе турындагы фәнгә, Татарстанның хореография сәнгатенә һәм мәгарифенә Гай Таһиров керткән өлешнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы тагын бер тапкыр ассызыкланды [Народный танец...].

Гай Таһировның хезмәтенә хәзерге заман этнохореологиясе позициясеннән чыгып караганда, анда яздырып алып теркәлгән фольклорның татар халкының пластик бию теле турындагы фән өчен әһәмиятле эмпирик материал булуын билгеләп үтәргә кирәк, традицион бәйрәмнәр һәм йолалар белән бәйләнеш турында мәгълүмат, фәнни анализ булмаса да, фольклорның өске катлавын гына тәшкил итсә дә, ул бүген дә башка чыганакларга алыштыргысыз.

Аның хезмәтендә фольклор биюләренең тасвирламалары аеруча мөһим. Алар әлеге төбәкләрдә XX гасыр урталарында татарларның этник биюенә хас үзенчәлекләрнең бердәнбер дәлиле булып тора һәм биюнең үзенчәлекле рәсемнәрендә, гәүдә, кул торышы һәм пластикасында, хәрәкәтләрне, йөрешләрне техник башкару үзенчәлекләрендә, кызлар һәм егетләр биюе манераларында, парлы биюдәге үзара мөнәсәбәтләрдә, бию динамикасында, темплар үзенчәлегендә, ритмика рәсемнәрендә, музыка һәм җыр аккомпанементында һ.б. чагылыш таба.

Гай Таһиров кыр тикшеренүләре вакытында халыкның этник төркемнәрен, аларның бию үзенчәлекләрен тасвирлауны читкә куеп, пластик бию телен, төрле төбәк татарлары костюмын күзәтә, истә калдыра, үзенчәлеген ассызыклый. Аның белемнәре хезмәтләрендә чагылыш таба һәм Г. Таһиров иҗат иткән «Казан кунаклары» якты композициясенең нигезенә ята. Анда татар халкының Казан, Бондюг, Касыйм, Оренбург, Себер, Әстерхан татарлары кебек төрле төркемнәре күрсәтелә. Аларның һәркайсы «үзенең бию телендә сөйли» – биюнең үзенчәлегенә һәм кабатланмаслыгына басым ясаган һәм гаҗәеп бию мозаикасын тудырган үзенчәлекле буяулар куллана. Бу композиция татар халкының биюен өйрәнергә, сакларга һәм үстерергә тиешле киләчәк буыннарга чакыру буларак кабул ителә.

Г.Х. Таһиров монографиясендә материаллар кыр тикшеренүләре үткәрелгән еллар буенча хронологик тәртиптә бирелгән. Ялгыз башкарылган биюне тәкъдим иткән информантлар бер генә тапкыр телгә алынганда, районнар, авыллар, өлкәләр аталган [Тагиров, с. 14, 16, 17]. Язып алганда сүз ярдәмендә тасвирлау методы эшкә җигелә, аның асылы музыка такты, темпы, үлчәве нигезендә бию хәрәкәтләрен, бию рәсемнәрен билгеле бер тәртипкә китерү һәм яздырудан гыйбарәт. Бу ысул хореографлар тарафыннан кабул ителә, чөнки хореография бүлекләре булган махсус урта һәм югары уку йортларына биюне яздыруның башка системасы кертелмәгән була, бу – Россиядә һәм элеккеге Советлар Союзы илләрендә тикшеренү эшләре алып барганда авырлыклар тудыра.

Күп гасырлар дәвамында биюне яздырып алуның универсаль системасын булдырырга омтылалар. Хореография сәнгатенең үсү тарихы

аның акрынлап камилләшеп, бал биюләренә, балет спектакльләренә, этник хореографиягә кагылуы турында сөйли. Г. Таһиров фольклор һәм сәхнә биюен теркәгәндә, В. Верховинц [Верховинец, 1919] һәм Е.М. Марголис [Марголис, 1950] кебек хореографлар системасына таяна. Төрле халыкларда Рудольф фон Лабанның «Лабанотейшен» (1926) һәм Рудольф һәм Джоан Бенешларның биюләрне теркәү ысуллары (1956) киң таралган. Бию яздыру буенча белгечләр әзерли торган этнохореология институты ачылды. Әйдәп баручы труппаларның штатында «хореологлар» бар, алар яңа куелышларны терки баралар [Балет, с. 209]. Венгрия һәм Төркия, этнохореология өлкәсендә зур казанышларга ирешкән илләр буларак, күп дистә еллар дәвамында әлеге системаларны уку йортларында өйрәнү, экспедицияләр вакытында үз халыкларының этник биюен теркәү, кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча хезмәтләр бастыру өчен файдаланалар, биюнең – матди булмаган мәдәни мирасның бай архивларын булдыралар.

Безнең илдә бию яздыру буенча җитди авторлык системаларының берсен 1940 елда әрмән галиме Србуи Лисициан эшләгән. Театр һәм хореография фольклорын тикшерүче бу галим Бөек Ватан сугышы (1941–1945) алдыннан «Хәрәкәт язмасы (кинетография)» [Лисициан, 1940] китабын чыгара, әмма сугыш аны уку-укыту процессына кертергә комачаулый. Шулай булуга карамастан, Европа телләрендә хәрәкәтләрне яздыру буенча чыккан барлык китапларда да галимнең эшенә сылтамалар китерелә [Бадмаева, с. 13]. XX гасырның 80 нче елларында СССР Фәннәр академиясенең Этнография институты өлкән фәнни хезмәткәре М.Я. Жорницкая җитәкчелегендә этнохореологлар фәнни мәктәбе барлыкка килә. Шуңа бәйле рәвештә 1970–1980 елларда С.С. Лисицианның фәнни хезмәте белән кызыксыну көчәя. Аның укучылары – Башкортстаннан Л.И. Нагаева, Калмыкиядән Т.Б. Бадмаева – үз хезмәтләрендә С. Лисициан системасына таяналар, кинетограммаларда бию фольклорын теркиләр. Кинетограммаларның график системасы биюне, аның хореографик лексикасын анализлаганда аеруча мөһим, кеше гәүдәсенең хәрәкәтен күләмле итеп күп кенә яссылыкларда күрергә мөмкинлек бирә. Т.Б. Бадмаева, информатика белгече белән берлектә эшләп, әлеге тема буенча мәкалә язганнан соң, компьютерлаштыру гасырында аны практикага кертү перспективасын да ассызыклый [Алексеев, Бадмаева, с. 14].

Г. Таһиров монографиясендә татар биюен өйрәнүчеләр өчен кирәкле мәгълүматлар булмавы объектив сәбәпләр белән аңлатыла. XX гасыр урталарында аның тарафыннан теркәлгән бию фольклоры башлангыч дәрәҗәдә бию морфологиясен тикшерергә, хореографик формалар буенча классификация ясарга, бию семантикасын, аның лексикасын һәм рәсемнәрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Гай Таһиров, 1917 елгы революциягә кадәр халык арасында яшәгән борынгы татар биюенең тарихи үзенчәлекләренә кагылып, исламның сәнгатькә, шул исәптән биюгә, тискәре мөнәсәбәттә булуына игътибар бирә. Бу биюнең үсешен тоткарлый, башкару киңлеген чикли,

массачыл биюләрне булдырмый. Чөнки «катнашучылар саны күп булган биюләрне күреп алырга җиңел, ә бу ахыр чиктә биюче өчен авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин була» [Тагиров, с. 11]. Ислам басымы астында биюнең яшәеш өлкәсе акрынлап тарая, әмма халык яраткан җырларын һәм биюләрен саклап кала һәм ял сәгатьләрендә, бигрәк тә көзен һәм кышын үткәрелгән кичәләрдә аларны яратып башкара. Сабан туйларында, рекрутларны солдат хезмәтенә озатканда һәм «муллалар вә тәкъва халык йөрмәгән» җыеннарда музыка, җыр һәм бию зур урын алып тора [Тагиров, с. 12].

Яңа совет чорында халык иҗатын үстерүгә карата гаепләүләр, тыюлар юкка чыга, бу бию культурасында, башкару манерасында яңа күренешләр, яңа хореографик формалар тууга этәргеч китерә. Яшьләрдән язып алынган фольклор материалы башкару үзенчәлекләрен бәян итүдә чагылыш таба. Авторның керешендә яздырып алынган биюләрнең кыскача характеристикасы, аларның гомумстилистик үзенчәлекләре бирелгән, «бу биюләрнең тере, зур эчке темпераментка ия, башлыча уен характерында» булуы ассызыкланган. «Шаярту элементлары, биюдәге партнерны алдау теләге аларның характерлы үзенчәлеге булып тора». Хатын-кыз һәм ир-ат биюен башкару манерасы татар кызы һәм татар егетенең характерын, темпераментын күрсәтә, парлы биюдә пластик бию теле аша аларның үзара мөнәсәбәтләре ачыла: «Кызлар йомшак итеп, оялып, тыйнаклык күрсәтеп, яшертен генә көязләнеп бииләр, хәрәкәтләре киң түгел, сикермичә шуып кына баралар кебек. Егетләрнең биюе дәртле, актив һәм гайрәтле, аларның хәрәкәтләре чарланган, җиңелчә сикерүләр һәм акцентлы тыпырдаулар күп. Кызлар белән биегәндә, егетләр үзләрен ышанычлы, горур тота» [Тагиров, с. 13].

Гай Хаҗи улы Таһиров – профессиональ белемле артист, балетмейстер, фольклор үрнәкләрен теркәү буенча зур хезмәт башкарса да, этнохореологлар кулланган күп кенә терминнарны бөтенләй белми диярлек. Ул татар аутентик фольклорының хореографик формаларына билгеләмә бирми. Биюләрне тасвирлаганда башкаручыларның составына ишарә иткән исемнәр дә санала: ялгыз бию, өчле бию, алты пар, парлы сигезле бию яки уен, әйлән-бәйлән, төрле кушылма биюләр: уенлы бию, әйлән-бәйләнле бию, әйлән-бәйләнле уен, әйлән-бәйләнле уенлы бию, әйлән-бәйләнле уен, уен, биюле уен, уенлы әйлән-бәйләнле бию. Материалны анализлау шуны билгеләп үтәргә мөмкинлек бирә: фольклор үрнәкләренә характеристика биргәндә «әйлән-бәйлән» сүзе күбесенчә хореографик формага бәйсез рәвештә, мәйдандагы катнашучыларның түгәрәккә басып урнашу яки хәрәкәт итү рәсеме булган биюләрдә кулланыла. «Уен» сүзе күбрәк теркәлгән фольклор исемнәрендә урын ала. Автор биюдә пар сайлау, парны алмаштыру, ярышып пар табу мөмкинлеген уен хәрәкәтләре итеп карый.

Материалда биюне *пляска* һәм *танец* (бию. – *Тәрҗ.*) дип бүлү юк, аларның аермалары билгеләнмәгән. Ә бүген тикшеренүчеләр моңа бик нык игътибар итәләр, аларның үзенчәлекләрен һәм аермаларын

ассызыклыйлар. Барлык фольклор үрнәкләрен бию (танцы) дип атыйлар. *Танец* һәм *пляска*, бу хореографик формалар арасында нинди уртаклык һәм аермалар бар соң?

XVII гасырда «танец» сүзе пәйда булганчы, Россиядә элек-электән «пляска» сүзе кулланылышта йөргән, әмма *танец* акрынлап термин буларак калыплашкан. «В феодальной России понятие «пляска» было шире, чем понятие «танец», т.к. включало все разновидности пляски: обрядовую и необрядовую, профессиональную и непрофессиональную, массовую, групповую, парную, сольную, а также пляску различных социальных, профессиональных и локальных общественных групп» [Фомин, с. 62]. А. Афанасьева һәм А. Соколов-Каминский төзегән терминологик сүзлектә этнохореологларның фәнни хезмәтләрен анализлау нәтиҗәсендә түбәндәге билгеләмәләр бирелгән: **«Пляска –** древнейший вид традиционной народной хореографической культуры. Двузначность термина «танец» обусловила определённые сложности в соотнесении танца с пляской: а) пляска – раздел танца, его ранняя форма, и в этом качестве термины синонимичны, хотя объём их, тем не менее, различен (танец включает пляску, но не исчерпывается ею); б)пляска противостоит танцу. Противопоставляются здесь отсутствие авторства – сочинённости, стихийность–регламентированности, импровизационность – закреплённости текста [Афанасьева, Соколов-Каминский, с. 211]. **«В фольклорном танце** сосуществуют пласт традиционных народных танцев и образцы более поздние, в известной мере, вторичные, испытавшие сильное влияние городской, фабрично-заводской культуры» [шунда ук, б. 213]. Алда әйтелгәннәрне искә алып һәм шәхси тәҗрибәгә таянып, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: *танец (бию)* киңрәк һәм заманча төшенчә, ул *плясканы* да үз эченә ала. Биюнең композициясе үз структурасында регламентланган, анда биючеләрнең урнашуы һәм күчеш-хәрәкәтләре рәсемдә канунлаштырылган, хореография тексты расланган. *Пляска* стихияле булуы, импровизациясе белән аерылып тора, ул – биюченең биюдә ачылуы, аның милли сөйләме. Ул, ялгыз башкару буларак, мөстәкыйль яши. Өлешчә канунлаштырылып, парлы һәм күмәк биюгә керә. Гай Таһиров, яздырып алынган фольклор композицияләрен биюләр дип атап, галимнәрнең билгеләмәләренә, нәтиҗәләренә һәм безнең тәҗрибәгә каршы килми.

Г. Таһиров тарафыннан теркәлгән фольклор татар халкының совет чорындагы, атеизм заманындагы бию иҗатын чагылдыра. Бу вакытта яшьләргә дин әһелләре тарафыннан бернинди тыюлар һәм гаепләүләр юк, җыр һәм бию ирекле үсеш кичерә, уеннарда, күңел ачуларда, кичәләрдә рәхәтләнеп җырлыйлар, бииләр. XX гасыр урталарында татар яшьләренең бию фольклорында яңа иҗтимагый укладның үзенчәлекләре чагыла: мәгълүмати алгарыш, сәнәгать техникасы, тормышны кабул итүгә оптимистик караш, хезмәт эшчәнлеге, табигать матурлыгын, кызларны мактау, гашыйкларның үзара мөнәсәбәте, иҗади фикерләү. Соңгысы бию рәсемнәре һәм аның лексикасы аша

хореографик образларда гәүдәләнә. Халык арасында яшәгән биюләрнең исемнәре дә шул хакта сөйли:

• механизмнар: Станок, Кайчы, Пычкы, Түгәрәк пычкы;

• музыкаль аппарат: Патефон;

• хезмәт процессы: Шәл бәйләдем, Бау ишү, Тимерчеләр;

• торак пункт исемнәре: Мортаза биюе, Карабайлы (авыл атамасы), Ленинград – Мәскәү;

• кыз һәм егет исеме: Әпипә, Зәлидә, Гөлбану, Карабәк, Зариф;

• уен мисалларында пар сайлау, партнёрлар алмашыну: Сөйгән ярымны сайлыйм, Кулларымны сиңа бирәм, Яңа уен, Терсәк, Сайлап алам, Пар сайлау;

• катнашучылар саны: Парлы сигезле, Кара-каршы сигезле, Сигезле, Өч таган (өч кеше), Дүрт таган (дүрт кеше), Дүртле бию, Өчле бию, Алты пар, Парлы уеннар, Парлы биюләр;

• бию рәсеме, кулларны тоташтыруның, кул хәрәкәтенең образлы чагылышы: Түгәрәк бию, Йолдызым, Чылбыр, Көмеш капка, Почмаклар, Кызыл йолдызчык, Комсомол күпере, Бизәкле почмаклар, Кул чабып бию;

• биюдә төп атрибут: Чыра (шәм) яндыру, Яулык салу, Самавырлы бию, Яулык бирешле бию;

• җырның исеме, җыр текстының фрагменты: Зәңгәр чәчәк, Йолдызым, Дулкын, Алмагачлар, Чия чәчәк атканда, Сөйгәнең ник килмәде, Өзеләдер үзәгем;

• туган як табигате: Лысьва елгасы ярында, Басма аша, Урам аша, Су буенда;

• кыйммәтле металлар: Алтын, көмеш;

• чиратлап ялгыз биюне берләштерүче гамәл: Чакыру;

• вакыт һәм женси-яшь үзенчәлекләре: Борынгы кызлар биюе, Яшүсмерләр биюе.

Татарстан һәм Россия төбәкләре авылларында яшәүче татар яшьләренең этник биюе җыр һәм инструменталь аккомпанемент белән синкретик бердәмлек тәшкил итә, һәм ул шулай теркәлгән дә. Түбән Тагил, Курган шәһәрләрендә, Чусовой, Лысьва заводларында һәм Пермь өлкәсенең шахтерлар поселокларында шәһәр мохите яшьләренең бию фольклоры, нигездә, музыка уен коралларында уйнау астында (җырламыйча гына) башкарылган биюләрдән гыйбарәт. Тикшерүче дә аларны шул рәвешле теркәгән.

Теркәлгән хореографик фольклор тасвирламасында биюләрнең семантикасы, биючеләрнең күчеш-хәрәкәт юнәлешенең мәгънәви әһәмияте, саннар символикасы чагылыш тапмаган. Этнографлар һәм сәяхәтчеләр, удмуртларның йолаларын һәм алар белән бәйле биюләрне тасвирлаганда, XIX гасыр әдәби чыганакларында боларны билгеләп үткәннәр. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында Б. Гаврилов удмуртларның өч санының тылсымлы көченә ышануы кияү йортына килгән кәләшне өч яулык-бөркәнчек белән ябу йоласында чагылыш табуын искәртә [Гаврилов, с. 49]. Чөнки бер генә яулык бәхетсезлек вәгъдә

иткән. Туй йоласының кайбер биюләре дә өч тапкыр башкарылган, шул исәптән ялган кәләш биюе дә (кәләш киеменә киенеп ул өйгә өч тапкыр бии-бии кергән) [шунда ук, б. 61].

Ерак үткәндә күчү юнәлеше билгеле бер мәгънәгә ия булган. Татарстан Республикасының Кукмара районы галимнәре һәм информантлары XX гасырның 80 нче елларында биюдә һәм йолада катнашучыларның күчү юнәлешләре символикасын билгеләделәр. Әлеге районда яшәүче удмуртларның туй йоласында биюдә катнашучыларның сәгать угы юнәлешендә – «кояш буйлап» түгәрәктә хәрәкәт итүе яшәүне, тормыш агымын аңлаткан, ә «кояшка каршы»сы – үлемне. Көнкүрештә өстәл өстендәге савыт-сабаны да «кояш буйлап», бу гамәлләргә тылсымлы мәгънә салып урнаштырырга кирәк булган[1]. Йырпыдсётон дип аталган искә алу йоласында анда катнашучылардан биючеләрнең түгәрәге корбанга китерелгән хайванның сөякләре салынган тырыс тирәли «кояшка каршы» хәрәкәт иткән [Владыкин, Чуракова, с. 114], шулай ук корбанга китереләчәк ат өстендә зиратны урап үткәннәр [Атаманов, Владыкин, с. 143].

Тылсымлы им-том функциясен үтәгән «өч» санының символик мәгънәсен башка халыкларның да, мәсәлән, башкортларның [Нагаева, с. 71], молдаваннарның [Флоря, с. 38], әрмәннәрнең [Петросян, Хачатрян, с. 25] төрле йолаларында очратырга мөмкин. Бу христианлыкка һәм мөселманлыкка кадәрге чорларда гамәлләрне өч тапкыр кабатлауның барлыкка килүе турында сөйли.

Биюнең семантикасын аңлау күзлегеннән караганда, Г.Х. Таһиров тарафыннан Пермь өлкәсе шахтерлар поселогы клубында язып алынган фольклор үрнәкләренең исемнәре кызыксыну уята: «Өч таган», «Дүрт таган». Алар, автор фикеренчә, биюдә катнашучыларның санын күрсәтә [Тагиров, с. 55, 56]. Хәрәкәт, адымнар, аларның символикасы белән бәйләнеш ачыкланмаган, әмма бу яңа заманда биюләрнең исемнәренә генә күчеп, буыннар аша тапшырылырга мөмкин тарихи архаиклыкны кире какмый. Мондый нәтиҗәләргә без әрмән халкының йола фольклоры биюләрендә өч адымнан торган фигуралар булуга таянып килдәбез. Аның борынгы традицияләре һәм семантикасы турында Ж. Хачатрян болай дип яза: «В общественных танцах этот тип движений исполнялся в начале обряда как память о предках» [Хачатрян, с. 54]. Дүрт адымнан торган икенче бер бию фигурасы, уңга таба да һәм сулга таба да икешәр адым атлауны аңлата. Уң һәм сул төшенчәсе ир-ат һәм хатын-кыз белән һәм туй йоласы биюләрендә алар башлангычының мәҗбүри тигезлеге белән бәйле, «аларда бары тик ир белән хатын гына катнаша алган.

«100 татар фольклор биюе» китабында Г. Таһиров тарафыннан тәкъдим ителгән материал аның хореографик формаларын ачыклау буенча тикшеренүләр үткәрергә мөмкинлек бирә. Әмма формалар буенча классификация ясаганчы, «хореографик форма» терминының нәрсә

[1] Информант Л.И. Михайлова, 1937 елгы. Татарстан Республикасы Кукмара районы Иске Оча авылында туган.

аңлатуын аңларга кирәк. Балет белгече Л.А. Линькова билгеләмәсе буенча, «Хореографическая форма – это замкнутые устойчивые структуры, в рамках которых осуществляется развитие танцевальных тем. Хореографические формы свойственны всем видам танца. Однако каждому присущи свои, оригинальные формы» [Линькова, с. 62].

Фольклор биюләре формаларын аерган классификация билгеләре төрле халыкларда, мөгаен, төрледер, әмма әрмән биюләрен өйрәнгәндә Ж. Хачатрян [Хачатрян, с. 52–60] китергәннәрен, безнеңчә, этнохореологлар кыр тикшеренүендә информантлар белән аралашканда кулланырга тиеш, чөнки алар этник биюнең семантикасын тирәнтен аңларга ярдәм итә:

• катнашучыларның төп (өстенлекле) көчү юнәлеше;

• бию фигураларының характеры (гади, катлаулы) һәм аларның ярашуы;

• башкаручылар саны һәм әлеге санлы символиканың семантикасы;

• биючеләрнең җенесе һәм яше;

• бию фигурасының төре.

Гай Таһиров тарафыннан теркәлгән фольклор үрнәкләренең структур төзелешен анализлау нәтиҗәсендә без татар биюенең түбәндәге төп хореографик формаларын (чама белән) аерып күрсәтә алабыз: биюле уен, әйлән-бәйләнле бию, бию, пляска. Бу формаларның һәркайсына хас үзенчәлекләрне, аларның тематик юнәлешен һәм структур төзелешен мисаллар китереп тасвирлау аерым тикшеренүләр үткәрүне таләп итә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, безнең тикшеренү Г. Таһировның «100 татар фольклор биюе» дигән хезмәтен өйрәнү буенча тулы һәм соңгы нәтиҗәгә дәгъва итми. Китерелгән фольклор материалын этнохореологиянең заманча критерийлары күзлегеннән чагыштырма анализлау методын кулланып, без нибары XX гасыр урталарында теркәлгән хореографик фольклор белән эшләүнең мөмкин булган юнәлешләрен генә билгеләдек. Әлеге материал белән эш иткәндә һәм татар биюе этнохореологиясенең яңа темаларын эшләгәндә, галимнәр өчен бию традицияләренең үзара йогынты ясашуы (этносара бәйләнешләр), бию морфологиясен (бию формаларын, структурасын, элементларын) тикшерү кебек перспективалы юнәлешләрне күрсәтергә мөмкин.

**Әдәбият**

*Алексеев А., Бадмаева Т.* Компьютинг танца vs нейрокомпьютинг танца // Нейрокомпьютеры: разработка, применение. 2014. № 4. С. 69–71.

*Атаманов М.Г., Владыкин В.Е.* Погребальный ритуал южных удмуртов // Материалы средневековых памятников Удмуртии. Устинов, 1985.

*Афанасьева А.Б., Соколов-Каминский А.А.* Краткий терминологический словарь // Народный танец. Проблемы изучения: Сб-к науч. трудов. СПб: ВНИИИ, 1991.

*Бадмаева Т.Б.* Основные аспекты профессиональной компетенции этнохореографов // Танец в диалоге культур и традиций: материалы VI Международной научно-практической конференции. СПб.: СПбГУП, 2016. 100 с.

Балет: энциклопедия. М.: СЭ, 1981. 623 с.

*Верховинец В.* Українська хореографія: Теория україньского народного танцю. Київ, 1919. 149 с.

*Владыкин В.Е., Чуракова Р.А.* Йырпыдсётон в поминальном ритуале удмуртов // Музыка в свадебном обряде финно-угров и соседних районов. Таллин, 1986.

*Всеволодский-Гернгросс В.Н.* Крестьянский танец // Крестьянское искусство СССР / Гос. ин-т истории искусств. Т. 2: Искусство Севера. Л., 1928. С. 235–246.

*Гаврилов Б.* Произведения народной словесности, обряды и поверья вотяков Казанской и Вятской губерний. Казань, 1880.

*Гаврилов Б.* Поверья, обряды и обычаи вотяков Мамадышского уезда. Урясь-Учинского прихода // Труды IV арх. съезда. Казань, 1891. Т. 2.

*Горшков В.Н.* Народный танец в творчестве Гая Тагирова // Тагиров Г.Х. 100 татарских фольклорных танцев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. С. 4.

*Линькова Л. А.* О драматургии балета // Музыка и хореография современного балета: Сб. статей. Вып. 3. Л.: Музыка, 1979. С. 40.

*Лисициан С.С.* Запись движения (кинетография). М.: Искусство, 1940.

*Марголис Е.М.* О записи танца. М.: Искусство, 1950. 130 с.

*Мациевский И.В.* Вклад А.А. Соколова в становление отечественной этнохореологии // Вестник Академии русского балета им. А.Я. Вагановой № 1 (54), 2018.

*Нагаева Л.И.* Танцы восточных башкир. М., 1981.

Народный танец и хореографическое искусство: материалы Международной научно-практической конференции, посвящённой 110-летию Гая Тагирова / сост. Э.М. Галимова, А.Р. Фардеева. Казань: ИЯЛИ, 2017. 184 с

*Озбильгин М.О.* Современные народные танцы в Турции: типы традиционного танца с взаимными культурными влияниями // Традиционная танцевальная культура народов Урало-Поволжья: исследование, образование, искусство, бытование / сост. Н.Д. Мусина; науч. ред. Р.М. Валеев, Р.Р. Юсупов. Казань: ИИЦ «Культура», 2013. 254 с.

*Петросян Э., Хачатрян Ж.* Армянский народный танец. М., 1980.

*Тагиров Г.Х.* 100 татарских фольклорных танцев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988, 160 с.

*Устинова Т.А.* Русский народный танец. М.: Искусство, 1976. 152 с.

*Фельфёлди Ласло.* Танец как нематериальное культурное наследие // Традиционная танцевальная культура народов Урало-Поволжья: исследование, образование, искусство, бытование / сост. Н.Д. Мусина; науч. ред. Р.М. Валеев, Р.Р. Юсупов. Казань: ИИЦ «Культура», 2013. 254 с.

*Флоря Э.* Танцевальный фольклор: Функциональные и структурные особенности // Музыкальная культура Молдавской ССР. М., 1978.

*Фомин А. С.* Понятие «танец» и его структура // Народный танец. Проблемы изучения: Сб-к науч. трудов. СПб.: ВНИИИ, 1991.

*Хачатрян Ж.К.* Принципы классификации по форме армянских народных плясок // Народный танец. Проблемы изучения: Сб-к науч. трудов. СПб.: ВНИИИ, 1991.

***Мусина Надежда Дмитриевна,***
*М.А. Балакирев исемендәге Балалар сәнгать мәктәбенең хореография бүлекчәсе педагогы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 81′28

***Намазали Мустафаев***

# БОРЫНГЫЛЫКНЫ САКЛАГАН ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

***(академик Мамедага Ширалиев истәлегенә багышлана)***

Данная статья посвящена жизни и научной деятельности выдающегося азербайджанского ученого-языковеда, доктора филологических наук, основоположника и главного редактора всесоюзного научно-теоретического журнала «Советская тюркология», созданного в 1970 году, Мамедаги Ширали оглу Ширалиева. Фундаментальные исследования М. Ширалиева, связанные с развитием азербайджанской диалектологии, получили высокую оценку многих международных организаций не только на всесоюзном, но и на мировом уровне. Автор статьи подробно описывает главные этапы научной деятельности данного ученого.

**Ключевые слова:** Мамедага Ширалиев, языкознание, азербайджанская диалектология, диалект, азербайджанский язык.

This article is devoted to the life and scientific activities of Mammadagi Shirali oglu Shiraliyev, an outstanding Azerbaijani linguist, doctor of philological sciences, founder and editor-in-chief of the all-Union scientific theoretical journal «Soviet Turkology», created in 1970. M. Shiraliyev’s fundamental research related to the development of Azerbaijani dialectology was highly appreciated by many international organizations not only in the Soviet Union, but throughout the world. The author of the article describes in detail the main stages of the scientific activity of this scholar.

**Keywords:** Mamedaga Shiraliyev, linguistics, Azerbaijani dialectology, dialect, Azerbaijani language.

Академик Мамедага Ширалиев 1909 елның 13 сентябрендә Азәрбайҗанның борынгы Шамахы шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта белемне Бакуның 18 нче мәктәбендә ала. 1927 елда Азәрбайҗан дәүләт университеты (1930 елда Педагогия институтына үзгәртелә) көнчыгыш факультетының тел бүлегенә укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, Азәрбайҗан ССРның Агдам районына укытучы итеп эшкә җибәрелә.

Агдам шәһәренең Агрохимия техникумында хезмәт эшчәнлеген башлап җибәргән М. Ширалиев 1931–1933 елларда азәрбайҗан теле укытучысы, шулай ук техникумның уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. Нәкъ менә шушы елларда ул борынгылык эзләрен саклаган диалектлар һәм сөйләшләр турындагы фән белән тирәннән кызыксына башлый.

Үзенең «Төрки телләр тарихы өчен яңа диалект мәгълүматлары» дигән мәкаләсендә академик М.Ш. Ширалиев болай дип яза: «...Зур тел белгечләренең, язма истәлекләр телен анализлаганда, телнең

бәхәсле мәсьәләләрен диалект материалларына мөрәҗәгать итеп хәл итүләре очраклы түгел». Һәм шуңа күрә ул Россиянең күренекле шәркыятче галиме П.М. Мелиоранскийның түбәндәге фикерен һәрвакыт югары бәяли: «...современные диалекты сохраняют часто, как показало уже неоднократное наблюдение, многие формы и слова, недошедшие до нас в сравнительно новых письменных источниках, представляют таким образом драгоценное часто незаметное пособие для понимания и отчасти лингвистического разбора наиболее древних памятников».

Яшь галим Кавказ арты территориясендә һәм Азәрбайҗан районнарында төрле экспедицияләрдә актив катнаша, диалектлар һәм сөйләшләр турында материаллар җыя, азәрбайҗан һәм кавказ телләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләр проблемалары белән кызыксына.

М.Ш. Ширалиев та, аның иптәшләре – талантлы яшь галимнәр А. Дамирчизадә һәм М. Гусейнзадә дә Азәрбайҗанның танылган тел белгече Бәкер Чобанзадәнең аспирантлары булалар, остазлары аларның тел белеменең төрле өлкәләрендәге фәнни эзләнүләренә юнәлеш биреп тора. Бу галим соңыннан репрессиягә эләгә.

1941 елның маенда М. Ширалиев үзенең «Баку диалекты» дигән фундаменталь тикшеренүен тәкъдим итә. Ул төрки диалектларны һәм сөйләшләрне өйрәнүгә багышланып, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен языла, соңыннан галим тарафыннан тудырылган азәрбайҗан диалектологиясе фәненең нигезенә ята.

Үзенең фәнни эшчәнлегендә ул милли кысалар белән генә чикләнми, ә тәвәккәллек күрсәтеп, фәнни тикшеренүләре белән халыкара мәйданга атлый. 1941 елда М. Ширалиев «Азәрбайҗан теленең диалогы һәм сөйләме» дигән мәкаләсен яза, анда беренче тапкыр, географик принципка таянып, азәрбайҗан теле диалектларының фәнни классификациясен тәкъдим итә. Бу мәкалә азәрбайҗан галимен бөтенсоюз дәрәҗәсендә күрсәтергә, азәрбайҗан теленең диалектлары һәм сөйләшләре белән кавказ телләре арасындагы үзара бәйләнешкә галимнең мөнәсәбәтен ачыкларга, совет тюркологиясенең алга таба үсешенең төп проблемаларын билгеләргә мөмкинлек бирә. Тәкъдим ителгән классификация 1959 елда UNESCO тарафыннан нәшер ителгән «Fundamental türcice» китабында чагылыш таба.

Әмма фашистлар Германиясенең СССРга каршы сугыш ачуы аркасында, яшь галим үзенең күп кенә фәнни планнарын тормышка ашыра алмый кала. Сугыш чорының гаять зур кыенлыкларына карамастан, бөтен совет халкы белән бергә, Азәрбайҗанның тылдагы күп кенә фән, мәдәният һәм сәнгать әһелләре дә Ватанны яклау өчен бөтен тырышлыгын куя. 1942 елда М.Ш. Ширалиев Азәрбайҗан дәүләт университетына эшкә күчә. 1942–1945 елларда ул – азәрбайҗан тел белеме кафедрасы мөдире һәм филология факультеты деканы, ә 1945 елдан – Азәрбайҗан дәүләт университеты проректоры булып эшли.

Совет халкы өчен фаҗига тулы бу чорда да ул үзенең фәнни эшчәнлеген туктатмый. 1942 елда галимнең «Азәрбайҗан диалектологиясе» китабы басылып чыга, анда беренче тапкыр азәрбайҗан диалектлары һәм сөйләшләренең аваз составы һәм фонетик күренешләрнең, аларның морфологик үзенчәлекләренең тасвирламасы бирелә, аларның әдәби телдән аермалары характерлана.

1943 елда, СССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Югары мәктәп эшләре буенча Бөтенсоюз комитетының Югары аттестация комиссиясе тарафыннан Мамедаги Ширалиевка филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсе һәм профессор исеме бирелә. Тылдагы тырыш хезмәте өчен, профессор М. Ширалиев «Кавказ оборонасы өчен» (1944), «Бөек Ватан сугышында хезмәт батырлыгы өчен» (1946) медальләре белән бүләкләнә.

1945 елда Азәрбайҗан Республикасы тормышында зур вакыйга була. Бу вакытта Азәрбайҗан дәүләт университеты белән янәшә Фәнни үзәк оештырыла һәм эшли башлый. 1945 елның 27 мартында Азәрбайҗан ССР хөкүмәте Азәрбайҗан Фәннәр академиясен раслый. Бу чорда, 1945–1946 елларда, профессор М.Ш. Ширалиев Азәрбайҗан дәүләт университетында проректор вазифаларын башкара.

1947 елда М.Ш. Ширалиев «Азәрбайҗан теле диалектларын өйрәнү» дип исемләнгән яңа мәкаләсен бастырып чыгара, анда беренче мәртәбә азәрбайҗан теле диалектлары һәм сөйләшләре белән кавказ телләре арасында үзара бәйләнеш проблемалары яктыртыла, азәрбайҗан телендә кыпчак элементларының булуын раслау юнәлешендә берничә яңа факт китерелә. Шул ук мәкаләдә галим совет тюркологиясенең кайбер алга таба үсеш проблемаларын билгели, тел тарихын өйрәнүнең мөһимлеген ассызыклый. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, галимнең әлеге мәкаләсе совет һәм чит ил монографияләрендә үзенең лаеклы урынын ала. Профессор М.Ш. Ширалиев исеме Азәрбайҗанда гына түгел, аннан читтә дә билгеле була.

1949 елда профессор М.Ш. Ширалиев Азәрбайҗан ССР Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы итеп сайлана һәм шул ук елда Тел институтының беренче директоры итеп билгеләнә. Шунысы әһәмиятле, аның «Баку диалекты» монографиясе 1949 елда аерым китап булып дөнья күрә һәм соңыннан яңадан басыла. Бу китапка бәяләмәсендә СССР Фәннәр академиясе академигы Н.К. Дмитриев болай дип язган: «М. Ширалиева с полным основанием можно назвать основателем азербайджанской диалектологии, стоящей на уровне современной науки».

1950 елда профессор М.Ш. Ширалиев азәрбайҗан теле диалектларын һәм сөйләшләрен чагыштырма планда өйрәнә башлый. Үз тикшеренүләренең нәтиҗәләрен ул «Азәрбайҗан теле диалектларын өйрәнү» (фонетик материалда) дигән фәнни хезмәтендә тасвирлый.

Бу уңайдан казакъларның зур телче галиме, Казакъстан Республикасы Милли академиясе академигы Ш. Сарибаевның фикере кызыклы: «Казакъ диалектологиясендә каршылыклы мәсьәләләр күп,

шуларның берсе – диалектлар классификациясе. Азәрбайҗанның күренекле тюркологы М. Ширалиев төрки дөньяда бу максатны билгеләде», – дип яза ул.

1951 елда Фәннәр академиясенең Әдәбият һәм тел белеме институтында профессор М.Ш. Ширалиев җитәкчелегендә беренче тапкыр диалектология бүлеге төзелә һәм танылган галим аның тәүге җитәкчесе була.

1953 елда Болгария Халык Республикасы хөкүмәте чакыруы буенча профессор М.Ш. Ширалиев София шәһәрендәге Изге Климент Охридский университетына эшкә күчә, анда 1953/1954 уку елында төрек филологиясе кафедрасын җитәкли. Монда галим төрек авылларында студентлар тарафыннан җыелган материаллар нигезендә «Төрек филологиясе», «Тел белеменә кереш» дигән берничә хезмәт яза. Ул аларны болгар студентларына лекцияләр укыганда файдалана. Бу хезмәтләр хәзер дә Софиянең Изге Климент Охридский университетында кулъязма хәлендә саклана.

Азәрбайҗан теле диалектларын һәм сөйләшләрен өйрәнү белән беррәттән, профессор М.Ш. Ширалиев азәрбайҗан әдәби телен, милли әдәбиятны үстерү проблемаларына аерым игътибар бирә. Үзенең хезмәтләрендә ул XIX гасырда – XX гасыр башында әдәби тел өчен барган көрәшне ачарга омтыла. Мәсәлән, 1956 елда профессор М. Ширалиев «Азәрбайҗан ССР ФА хәбәрләре»ндә «1905 елгы революция һәм азәрбайҗан әдәби теленең халыкчанлыгы өчен көрәш» исемле мәкаләсен бастыра. «Совет чорында Азәрбайҗан әдәби телен үстерү мәсьәләсенә» дигән икенче мәкаләсендә (1957) хәзерге азербайҗан әдәби теленең үсеш юллары гәүдәләндерелә.

Моннан тыш, ул бөек азәрбайҗан шагыйре М.А. Сабирның әдәби иҗатына мөрәҗәгать итә һәм «Сабир теле турында язмалар» хезмәтен яза, анда, шагыйрь теленең гомумхалык теле һәм диалектлар белән үзара бәйләнеше нигезендә, кыскартылган формада XX гасыр башы әдәби теленең характерлы үзенчәлекләрен ачып бирә.

Профессор М.Ш. Ширалиевның азәрбайҗан диалектологиясе үсеше белән бәйле фундаменталь тикшеренүләрен күп кенә халыкара оешмалар бөтенсоюз дәрәҗәсендә генә түгел, дөнья күләмендә югары бәяли. Әйтик, 1957 елда дөньякүләм танылган галим делегат сыйфатында Төрек Лингвистика җәмгыятенең VIII корылтаенда (Türk Dil Kurumu) катнаша, анда әлеге җәмгыятьнең мөхбир әгъзасы һәм мактаулы әгъзасы итеп сайлана.

1952–1960 елларда профессор М.Ш. Ширалиев Азәрбайҗан ССР ФА И. Нәсими исем. Әдәбият һәм тел институтының диалектология бүлеге мөдире һәм бер үк вакытта Азәрбайҗан дәүләт университетының азәрбайҗан тел белеме кафедрасы профессоры вазифаларында эшли. 1960–1968 елларда М.Ш. Ширалиев И. Нәсими исем. Әдәбият һәм тел институтын җитәкли, ә 1968 елның февраленнән Азәрбайҗан ССР Фәннәр академиясенең Иҗтимагый фәннәр бүлеге академсекретаре була.

Профессор М.Ш. Ширалиевның фундаменталь эшләренең берсе – 1962 елда басылган «Азәрбайҗан диалектологиясе нигезләре» дигән хезмәте [Ширалиев, 1962]. Бу китап – диалектларны күп еллар дәвамында өйрәнү нәтиҗәсе. Ул азәрбайҗан диалектлары һәм сөйләшләренә хас үзенчәлекләргә тирән теоретик анализны, аларның специфик һәм уртак сыйфатларын үз эченә ала. Биредә азәрбайҗан диалектлары башка төрки телләр белән чагыштырып яктыртыла. 1962 елда профессор М.Ш. Ширалиев Азәрбайҗан ССР Фәннәр академиясе академигы итеп сайлана һәм шул ук елда аңа «Атказанган фән эшлеклесе» исеме бирелә. 1969 елда ул И. Нәсими исем. Тел белеме институтының беренче директоры итеп билгеләнә. Бу вакытта институтта аның җитәкчелегендә «Төрки телләр диалектологиясе мәсьәләләре» дигән җыентык әзерләнә һәм басыла башлый, ун ел дәвамында ул уңышлы гына нәшер ителә. Үзенең диалектологияне үстерү өлкәсендәге монументаль фәнни хезмәте өчен академик М.Ш. Ширалиев 1972 елда Азәрбайҗан ССРның Дәүләт премиясенә лаек була.

Академик М.Ш. Ширалиев Советлар Союзында гына түгел, дөньяның төрле илләрендә узган халыкара конференцияләрдә, симпозиумнарда һәм конгрессларда совет һәм азәрбайҗан фәнен актив рәвештә популярлаштырган. Беренче диалектологик атласны һәм азәрбайҗан теле сүзлеген төзү дә академик М. Ширалиев исеме белән бәйле. Ул географик тел белеме юлы белән төрки телләрне өйрәнү идеясенең авторы да була.

СССРның иң зур тюркологларының берсе, СССР Фәннәр академиясе академигы А.Н. Кононовның «Совет тюркологиясе» журналында басылган «Мамедага Ширали оглы Ширалиев» дигән мәкаләсендә: «...Изучение тюркских языков методом лингвистической географии вплоть до 50-х годов оставалась одним из самих слабых звеньев в тюркологии», – дигән фикер үткәрелә [Кононов, с. 124].

1960 елда ук М.Ш. Ширалиев «Яңа этапта азәрбайҗан диалектологиясе» дигән мәкаләсендә азәрбайҗан теленең диалектологик атласын төзүнең фәнни нигезләрен һәм юлларын бәян итә һәм чагыштырмача тиз арада аны китап итеп бастырып чыгаруга да ирешә. Төрки телләрнең диалектологиясе мәсьәләләре буенча Бакуда узган Бөтенсоюз киңәшмәсендә нәкъ менә шуңа күрә дә диалектологик атлас төзү эшенә тулаем җитәкчелек итү академик М.Ш. Ширалиевка (1965) тапшырыла. Азәрбайҗан диалектологлары 20 ел эчендә академик М.Ш. Ширалиев җитәкчелегендә 128 картадан торган «Азәрбайҗан теленең диалектологик атласын» төзеп бастырып чыгаруга ирештеләр (1980).

Азәрбайҗан галимнәренең тюркология үсешенә зур өлеш кертүен исәпкә алып, шулай ук совет тюркологиясен алга таба үстерү максатларында СССР Фәннәр академиясе Президиумының «Совет тюркологиясе» бөтенсоюз журналын чыгару турында» карары кабул ителә. Аның максаты: тюрколог галимнәрнең көчләрен берләштерү, идеяләр алмашу һәм тәҗрибә, тикшеренүләр нәтиҗәләре белән уртаклашуны

тәэмин итү, төрки телләрнең башка телләр белән үзара бәйләнеше проблемаларын яктырту, төрки халыклар арасындагы күпгасырлык әдәби һәм мәдәни багланышлар турындагы материалларны бастырып чыгару һ. б. Һәм, әлбәттә, әлеге бөтенсоюз фәнни-теоретик журналының баш мөхәррире итеп академик М. Ширалиев билгеләнә. Журнал 1970–1987 елларда басыла. Шушы вакыт аралыгында бу басманың 100 дән артык саны дөнья күрә.

М. Ширалиев үзенең озак еллар дәвам иткән эчтәлекле фәнни-педагогик эшчәнлеге белән Азәрбайҗан мәгарифен үстерүгә зур өлеш кертә. Әйтергә кирәк, фундаменталь хезмәтләр бастыру, дәреслекләр, төрле уку әсбаплары һәм диалектология программалары төзү өлкәсендә дә галимнең казанышлары зур. Аның күп кенә фундаменталь хезмәтләренең берничә басмасы дөнья күрә һәм бүген дә югары уку йортлары галимнәре һәм студентлары аларны яратып куллана. Аның җитәкчелегендә һәм танылган телчеләр белән берлектә югары мәктәпләр өчен берничә дәреслек язылган. Югары уку йортлары өчен диалектология буенча программа һәм дәреслекнең авторы да – академик М.Ш. Ширалиев.

Азәрбайҗан өчен дә, СССР һәм чит илләрнең күп кенә республикалары өчен дә тел белеме өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләүдә академик М.Ш. Ширалиевның роле зур. Галимнең күпсанлы шәкертләре Азәрбайҗанны аннан читтә дә уңышлы тәкъдим итәләр. Мәсәлән, азәрбайҗан теле өлкәсендә галим 10 фән докторы һәм 50 дән артык фән кандидаты әзерләгән. Болар: академик Агамус Ахундов, Тофик Гаджиев, филология фәннәре докторлары Мирза Рәхимов, Исмаил Мамедов, Газанфар Пашаев, Рәхилә Магеррамова, Муса Исламов, Газанфар Кязимов, Мусеиб Мамедов. Аның катнашында 9 үзбәк, 2 башкорт, 2 татар галиме докторлык диссертациясе яклаган. Фән кандидатлары да бар: берешәр – балкар, гагауз, каракалпак, карачай һәм казакъ.

Ул – төрки телләр буенча фәнни эшләрне чагыштырма планда язуның һәм бу өлкәдә кадрлар тәрбияләүнең инициаторы да. Академик М.Ш. Ширалиевның республикабызда фәнни кадрлар әзерләү мәсьәләләренә зур игътибар бирүе нәтиҗәсендә, азәрбайҗан-үзбәк, азәрбайҗан-төрекмән һәм азәрбайҗан-татар телләре өлкәсендә яшь галимнәр үсеп чыкты. Аның тарафдарлары бүген Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда, Казакъстанда, Молдавиядә, Карачай-Чиркәстә, Каракалпакстанда һәм элеккеге Советлар Союзының һәм БДБнең башка суверен республикаларында эшлиләр.

Фәнни кадрлар әзерләүдә актив эшләгәне өчен, академик М.Ш. Ширалиев Үзбәкстан ССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының Мактау грамотасы (1977), шулай ук 70 яшьлек юбилее уңаеннан Үзбәкстан ССР составындагы Каракалпак автономияле республикасының Мактау грамотасы (1979) белән бүләкләнде.

Шунысы куанычлы, бүген дә халыкара симпозиумнарда һәм конференцияләрдә күренекле галим М. Ширалиевның тюркология фә-

нендәге роле ассызыклана. Шул уңайдан, 2014 елның октябрендә Бакуда тюркологларның «Элгәрләр һәм дәвамчылар» дигән темага 1 нче Халыкара симпозиумы уздырылуын аерым билгеләп үтәсе килә. Бу чара күренекле фикер иясе һәм лингвист Алибәк Гусейн углы Гусейнзадәнең тууына 150 ел, дөньякүләм танылган тел белгече һәм тюрколог Мамедаги Ширали углы Ширалиевның тууына 105 ел тулуга багышлана.

Күп кенә азәрбайҗан галимнәре академик Мамедаги Ширалиевның иҗатына аерым игътибар бирә. Алар һәрвакыт аның монументаль фәнни тикшеренүләрен югары бәяләделәр. Алар арасында: академиклар Гамид Араслы, Агамус Ахундов, Тофика Гаҗиева; мөхбир әгъза Абдулазал Дамирчизадә; профессорлар: Мирза Рагимов, Газанфар Пашаев, Юсиф Сеидов, Вагиф Асланов, Рәхилә Маграмова, Максим Мәхмүдов, Айдын Нагдалиев һ. б. бар.

Әйтергә кирәк нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге өчен академик М.Ш. Ширалиев «Мактау билгесе» (1954) һәм «Халыклар дуслыгы» (1975) орденнары белән бүләкләнә.

**Әдәбият**

*Абдуллаев А.* Крупный советский тюрколог // Баку. 1969. 3 дек. С. 3.

*Атакишиев А.* История Азербайджанского Государственного Университета. Баку: Изд-во АГУ, 1989. С. 217–218.

*Болдырев Р.* «Столетие со дня рождения академика А.Е. Крымского // Советская тюркология. 1971. № 1. С. 124–127.

Выступление Президента Азербайджанской Республики на церемонии открытия министерской конференции Движения неприсоединения на тему «Поощрение международного мира и безопасности во имя устойчивого развития» // Бакинский Рабочий. 2018. 6 апр. С. 2–3.

Выступление Президента Азербайджанской Республики И. Алиева на VII Саммите сотрудничества тюркоязычных государств // Бакинский Рабочий. 2019. 16 окт. С. 2–3.

Выступление первого Президента Казахстана – Елбасы, почетного председателя Тюркского Совета г-на Нурсултана Назарбаева // Бакинский Рабочий. 2019. 15 окт.

Выступление Президента Узбекистана г-на Ш. Мирзиева // Бакинский Рабочий. 2019. 15 окт.

Выступление Премьер-министра Венгрии Виктора Орбана на VII Саммите Совета сотрудничества тюркоязычных государств // Бакинский Рабочий. 2019. 16 окт.

*Дадащзаде М.* Люди науки. Исследуя родной язык... // Бакинский Рабочий. 1969. 3 дек.

*Касимов М., Исламов М.* Люди науки. Изучая богатство языка // Бакинский Рабочий. 1979. 26 окт.

*Кононов А.* Мамедага Ширали оглы Ширалиев (к шестидесятилетию со дня рождения) // Советская тюркология. 1971. № 5. С. 124–127.

*Кононов А.* П.М. Мелиоранский и Отечественная тюркология // Советская тюркология. 1971. № 5. С. 6–23.

*Кязимов Г.* Azərbaycan dialektologiya elminin banisi Tədqiqlər. 2009. S. 9–14.

Материалы VII Саммита Тюркского Совета// Бакинский Рабочий. 2019. 15 окт. С. 1–8.

*Пашаев Г.* Türkologiyya elminin patriarxı // Azərbaycan qəzeti. 2009. 7 нояб.

*Пашаев Г.* Borcumuzdur bu ehtiram. Unudulmazlar haqqında uvertüra // Bakı. 2010. S. 18–28.

*Рагимов М.* Научная деятельность академика М.Ш. Ширалиева // Вопросы тюркологии. Баку: Элм, 1971. С. 3–14.

Распоряжение Президента Азербайджанской Республики И. Алиева «О проведении 110-летия академика Мамедаги Ширалиева» // Бакинский Рабочий. 2019. 20 июля. С. 1.

*Ширалиев М.Ш., Асадуллаев С.* Советская тюркская филология и задачи журнала «Советская тюркология» // Советская Тюркология. 1970. № 1. С. 3–15.

***Мустафаев Намазали,***
*тикшеренүче галим*
*(Баку, Азәрбайҗан Республикасы)*

# БОЛГАР-ТАТАРЛАР ТАРИХЫ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП: Георги Владимиров. Великата България на Волга през средните векове. София: Просвета, 2019. 170 с.

Казан археологлары инде узган гасырның җитмешенче елларыннан башлап ук үзләренең коллегалары – Болгария галимнәре белән тыгыз элемтәдә торып эшлиләр. Әлеге хезмәттәшлеккә безнең яктан күренекле галимебез – профессор Альфред Хәсән улы Халиков, болгарлар ягыннан профессор Димитр Димитров белән аның шәкерте Рашо Рашев нигез салдылар. Европаның Урта гасырлар чоры тарихында күренекле урын тоткан борынгы болгарлар – уртак бабаларыбыз тарихын өйрәнүдә Болгария һәм Татарстан галимнәренең бергәләп эшләргә омтылуы табигый күренеш булды. Д. Димитровның элгәреге болгарлар археологиясенә багышланган китабында аның 1976 елда Татарстанга килеп өйрәнеп киткән Олы Тархан каберлеге материаллары да киң кулланылган иде [Димитров, 1987; Халиков (рец.), 1988]. Соңрак әлеге теманы Р. Рашев тагын да тирәнрәк һәм киңрәк планда тикшерде [Хузин, 2011, с. 283–286] һәм, әйтергә кирәк, А.Х. Халиковның да теләген-үтенечен истә тотып, Болгариянең беренче башкаласы атаклы Плиска территориясендә казу эшләрен башлап җибәрде (Рашев), шул ук вакытта Биләр, Болгар истәлекләрен өйрәнүче Казан археологлары белән элемтәләрен беркайчан да өзмәде [Рашев, 1998; 2001; 2004; 2006; 2007 һ.б.].

А.Х. Халиков – гомеренең күп өлешен фин-угор археологиясенә багышлаган галим. Әмма ул болгар археологиясе өлкәсендә дә уңышлы эшләп килде, Олы Тархан, Танкеевка каберлекләрен, Биләр, борынгы Казан, Алабуга калаларын өйрәнеп, Идел болгарлары тарихын дөньякүләм танытуга зур өлеш кертте. Табигый ки, Татарстан галимнәренең болгар археологиясендәге яңа ачышлары Болгариядәге коллегаларыбызның игътибарыннан читтә калмады. А.Х. Халиковның Болгариядә чыга торган фәнни басмаларда дөнья күргән мәкаләләре [Халиков,1981; 1981а; 1982; 1983; 1988; 1988а; 1989] шул кызыксынуның бер чагылышы иде.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: нәкъ менә Альфред Хәсән улының Мәскәү галимнәре тарафыннан хупланган башлангычы белән Болгария һәм элеккеге Советлар Берлеге галимнәре катнашында болгар археологиясенә багышланган халыкара симпозиумнар, конференцияләр үткәрү традициягә әйләнде. 1976 елда Болгария Фәннәр академиясенең Шумен шәһәрендә үткән конференциядә Казаннан гына да А.Х. Халиков, Т.А. Хлебникова, Е.П. Казаков, Е.А. Халикова, П.Н. Старостин кебек олуг галимнәр катнашкан иде. Шундый конференцияләрнең тагын берсе, миңа калса, иң истәлеклесе – «Болгар цивилизациясенең чишмә башы, тарихи үсеше һәм мәдәни мирас» дип аталган IV Халыкара форум – 2012 елның октябрендә Болгариянең Варна шәһәрендә уздырылды. Әлеге форум «Bulgarica. Время и

пространство Болгарской цивилизации» дигән фундаменталь хезмәтнең киң фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителүе һәм бу чараларда Татарстанның Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев һәм Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.М. Мазһаровның да катнашуы белән фән дөньясында мөһим вакыйга буларак кабул ителде [Владимиров, Ситдиков, Хузин, 2013].

Әлеге чаралар Урта гасырлар тарихының һәм археологиясенең Дунай һәм Идел болгарлары арасындагы бәйләныш проблемаларын өйрәнүне тагын да җанландырып җибәрде. Болгариядә чыга торган фәнни журналларда, җыентыкларда В. Йотов, П. Георгиев, Б. Борисов, Г. Владимиров, Л. Дончева-Петкова кебек галимнәрнең мәкаләләре ешрак күренә башлады. Санап үтелгән галимнәр арасыннан мин Георги Владимиров хезмәтләренә аерым тукталып үтәргә телим.

Г. Владимиров Болгария мәдәният министрлыгында фән секторын җитәкли. Без исә аны күбрәк Идел һәм Дунай болгарларының Урта гасырлар тарихын чагыштырма планда өйрәнүче талантлы галим буларак беләбез. Аның күпсанлы мәкаләләрен һәм «Дунавска България през VII–XI век» (София, 2005), «Казанското ханство» (София, 2005), «Волжка България и Казанското ханство: строително изкуство и архитектура» (София, 2006) исемле китапларын республикабызның фәнни җәмәгатьчелеге, беренче чиратта, әлбәттә, археологлар, Казанның 1000 еллык юбилеена багышланган олы бүләк рәвешендә кабул итте. Г. Владимировның Идел Болгары һәм Казан ханлыгы тарихына багышланган башка китаплары да бар [Владимиров, 2007; 2011]. Шушы китаплар сериясеннән мин аның «Волжка и Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели. VII–XI век» дигән монографиясен аерым атап үтәр идем, чөнки ул Болгария һәм Татарстан галимнәре арасында урнашкан хезмәттәшлекнең яңа этабын башлап җибәрүгә этәргеч бирде [Владимиров, 2005б; Хузин (рец.), 2007].

Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты 2018 елда Г. Владимировның «Серьги в виде знака вопроса из средневековой Болгарии (XIII–XIV вв.)» исемле монографиясен бастырып чыгарды. Ниһаять, узган ел Софиянең «Просвета» нәшриятында аның тагын бер китабы дөнья күрде. Ул «Великата България на Волга през средните векове» дип атала. Миңа калса, бик үзенчәлекле китап бу, минем игътибарымны шул үзенчәлекләр җәлеп иттеләр дә инде.

Беренчедән, китап тарих белән кызыксынучы киң катлам укучыларга, иң әүвәл югары сыйныфларда укучы мәктәп балаларына һәм аларның укытучыларына, шул ук вакытта тарихчы галимнәргә, музей хезмәткәрләренә дә тәгаенләнгән. Теле – матур, шома, җөмләләре – кыска, фикерләр – тирән. Бәхәсле мәсьәләләр читләтеп үтелми, авторның үз фикере язма һәм археологик чыганаклар белән ныгытылып китерелә. Күрәсез, автор тарафыннан кыю адым ясалган – бүгенге болгарлар, бигрәк тә яшь буын, Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң,

Аспарух төркеменнән аерылып, Урта Иделгә килеп төпләнгән ерак кардәшләренең тарихын да белергә тиеш. Безнең галимнәр өчен дә үрнәк адым бу, минемчә.

Икенчедән, китап матур итеп төсле рәсемнәр, фотолар белән бизәлгән; ул рәсемнәрнең шактый өлеше нәшрият заказы белән китап өчен махсус эшләнгән, икенче өлеше исә рәссамнәрнең инде безгә мәгълүм әсәрләреннән җентекләп сайлап алынган. Моны ассызыклап әйтүемнең сәбәбе шул: бездә татар тарихыннан фәнни-популяр китаплар чыгарганда автор заказы буенча текстка, ягъни эчтәлеккә туры килерлек иллюстрацияләр ясап мәшәкатьләнмиләр, булганыннан файдаланырга туры килә. Шунлыктан Рушан Шәмсетдинов, Фиринат Халиков, Равил Заһидуллиннарның күбесенчә бер үк темага язылган рәсемнәре китаптан китапка күчеп йөри.

Өченчедән, китапның кушымталар бүлегендә (117 – 154 б.) гади укучылар өчен кызыклы һәм алдагы бүлекләрдә бирелгән факт-вакыйгаларны тагын да төплерәк итеп үзләштерүгә исәпләнгән язма чыганаклар, татар риваятьләре һәм легендалары, Идел – Дунай болгарлары тарихындагы вакыйгаларны чагыштырып карарга уңайлы хронологик таблица урнаштырылган.

Хәзер китапның эчтәлегенә күз төшерик.

Ул болгар тарихын чагылдырган язма чыганакларга, археология, нумизматика материалларына һәм Болгария галимнәренең Идел Болгары тарихын яктырткан, дөресрәге, аз гына булса да искә алып киткән хезмәтләренә күзәтү белән башланып китә (11–21 б.).

Болгарларның дәүләтчелек тарихын Г. Владимиров хаклы рәвештә Кубрат хан оештырган Бөек Болгариядән («Старата Велика България») башлап җибәрә. Барлыгы 30–40 ел чамасы гына яшәп калган бу дәүләтнең тарихы, табигый ки, һаман да әле җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, чөнки язма чыганаклар аз сакланган, археология материаллары башлыча Азов–Кара диңгез буе далаларына сибелеп урнашкан аерым каберлекләрдән генә гыйбарәт. Шулай да укучы болгарларның беренче дәүләте турында ярыйсы гына мәгълүмат ала һәм Кубрат ханны соңрак Дунайда һәм Идел буенда калкып чыккан дәүләтләрнең идарәче династияләрен нигезләүче шәхес сыйфатында кабул итә (22–27 б.).

Бүген Урта Идел бассейнында яшәүче халыкларның ерак тарихы таш, бронза, элгәреге тимер гасырларын – якынча 70 мең еллык дәверне үз эченә ала. Төбәкнең этник картасындагы кискен үзгәрешләр «Халыкларның бөек күчеше» дип аталган чор белән бәйләнгән. Г. Владимиров бу чорны хаклы рәвештә һуннардан башлап җибәрә, шул чорда барлыкка килеп, Төрки каганлык чорында үсеш алган Имәнкискә һәм Кушнаренко кабиләләренең этник йөзе турында үз фикерләре белән уртаклаша. Кушнаренко кабиләләрен галимнәр угор телле булган дип язалар, ягъни алар – борынгы венгрлар (протовенгрлар), Имәнкискә кабиләләренең этник йөзе әлегә кадәр ачыкланмаган (төркләр? славяннар? балтлар? сарматлар? готлар?). «Хәер, бу безнең

өчен артык мөһим дә түгел, – дип яза Г. Владимиров, – бу очракта безгә Урта Идел халкының әле болгарлар килгәнче үк күп милләтле булуын күрсәтеп үтәргә кирәк» (32 б.).

Элгәреге болгарларның Урта Иделгә күчеп утыруларын Г. Владимиров 660 елларда Кубрат хан дәүләтенең таркалуы белән бәйли. Элегрәк һәм кайберәүләр әле хәзер дә бу күчешне 737 елгы Гарәп-Хәзәр сугышлары нәтиҗәсе итеп кабул итәләр иде. Галим узган гасырның сиксәненче елларында хәзерге Самара һәм Ульян өлкәләрендә ачылган Новиньково тибындагы каберлекләрне төрки телле халыклар калдырган һәм алар арасында, һичшиксез, болгарлар да булган, дигән фикерне дәлилли (33 б.).

Китапның алдагы бүлекләре тулысы белән диярлек Идел Болгары тарихына багышланган. Биредә укучы Болгар дәүләтенең биләмәләре, халкы һәм аның ислам динен кабул итүе (37–44 б.), Болгар – Русь хәрби-сәяси мөнәсәбәтләре турында, нигездә, язма чыганакларга таянып бәян ителгән реаль фактлар белән таныша ала (45–53 б.). Болгар – Русь хәрби-сәяси мөнәсәбәтләрен тикшергәндә Г. Владимиров болгарлар үткәрә торган сәясәтнең үз-үзләрен саклау – оборона юнәлешендә булуына игътибар итә (50 б.). Бу уңайдан беренче рус тарихчысы В.Н. Татищев сүзләре искә төшә: «... болгаре хотя некогда с русскими воевались, однако ж видно, что немного о том прилежали и не искали чужаго преобрести, но свое паче засчисчать старались» [Татищев, 1962, с. 269].

Болгар шәһәрләре һәм шәһәр архитектурасы – галимнең яратып тикшерә торган темасы. Бу теманы яктыртканда Г. Владимиров еш кына Дунай Болгариясе шәһәрләренә дә күз ташлый һәм соңгыларының архитектурасына Византия империясенең йогынтысын ассызыклап күрсәтә. «Болгар калалары исә, нигездә, буш урында барлыкка килгәннәр һәм аларның топографик структурасында күчмәннәр традициясе, ә архитектурасында Шәрык архитектурасы йогынтысы сизелә», – дип билгеләп үтә автор (55 б.; шулай ук карагыз: [Владимиров, 2002, б. 19–21]). Үз чиратыбызда, Р. Рашев тикшеренүләренә таянып [Рашев, Дочева, 1989], Дунай болгарларының беренче башкаласы Плиска архитектурасында да күчмәннәрдән килгән традицияләрнең бик ачык чагылышын искәртеп үтәргә тиешбез.

Китапның соңгы бүлекләрендә (63–91 б.) сүз Идел болгарларының икътисадына (сүз күбрәк авыл хуҗалыгы – игенчелек һәм терлекчелек, шулай ук шәһәр һөнәрчелеге һәм сәүдә турында бара), көндәлек тормышка һәм мәдәният үсешенә караган материаллар бирелгән. Г. Владимиров Идел Болгарын икътисад һәм мәдәният үсеше ягыннан караганда күрше Киев Русе һәм рус кенәзлекләре белән бер дәрәҗәдә торган дәүләт буларак ассызыклый. Биләр каласында туып үскән һәм шунда ук монгол-татарлар явы вакытында соңгы сулышын алган Кол Гали иҗатын, төгәлрәк әйткәндә, аның «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын Урта гасырлар дөнья мәдәниятенең иң күренекле әсәрләре рәтенә куеп бәяли.

Г. Владимиров фикеренчә, болгарларның монгол-татар яуларына кадәр үк шактый югары үскән икътисады һәм мәдәнияте Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында да төшенкелек кичерми, алгарышлы үсешен дәвам итә. Болгар халкы XIII–XIV гасырларда булып узган глобаль характердагы сәяси үзгәрешләр чорында да үз йөзен, традицион яшәү рәвешен югатмый, ата-бабалар мирасын саклап, татарлар исеме белән бүгенге көннәргә кадәр килеп җитә, дип йомгаклый автор үзенең укучыларына җиткерәсе фикерен.

Әлеге китапта әлләни ачышлар да юк кебек, ул фәндә күптән билгеле тарихи чыганаклар, Россия һәм Татарстан галимнәренең совет чорында һәм соңгы елларда чыккан күпсанлы фәнни хезмәтләре нигезендә язылган. Әмма бу очракта Георги Владимировның максаты – ачыш ясау түгел, бәлки киң болгар җәмәгатьчелеген, беренче нәүбәттә мәктәп укучыларын, укытучыларны алар өчен әлегә ятрак, серлерәк, әмма бер тамырдан чыккан Идел болгарларының, ягъни безнең, татарларның, борынгы бабалары тарихы белән таныштыру. Һәм автор, һичшиксез, үз максатына ирешкән дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**

*Владимиров Г.* Столичен град в културата на Волжка България // Български векове. 2002. № 4. С. 13–21.

*Владимиров Г.* Дунавска България през VII–XI век. София, 2005.

*Владимиров Г.* Казанското ханство: история, икономика, култура. София, 2005а. 112 с.

*Владимиров Г.* Волжка и Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели. VII–XI век. София, 2005б. 158 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство: строително изкуство и архитектура. София: ТАНГРА ТанНакРаИК, 2006. 89 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство в географическите карти на Средневековиете и Новато време. София, 2007. 86 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство: предания и легенди на народите на Средна Волга. Пловдив, 2011. 78 с.

*Владимиров Г.* Серьги в виде знака вопроса из средневековой Болгарии (XIII–XIV вв.): о материальных следах куманов и Золотой Орды в культуре Второго Болгарского царства. Казань: Ин-т археологии им. А.Х. Халикова АН РТ, 2018. 139 с.

*Владимиров Г., Ситдиков А.Г., Хузин Ф.Ш.* IV Международный Болгарский форум «Истоки, историческое развитие и культурное наследие Болгарской цивилизации». (Варна, Болгария, 22–25 октября 2012 г.) // Поволжская археология. 2013. № 1 (3). С. 232–237.

*Димитров Д.* Прабългарите по Северного и Западното Черноморие. (Към въпроса за тяхното присъствие и история в днешните руски земи и ролята им при образуването на Българската държава. Варна: Изд-во «Георги Бакалов», 1987. 304 с.

*Рашев Р.* О возможности выделения самых ранних археологических памятников в степях Восточной Европы // Татарская археология. 1998. № 2. С. 65–72.

*Рашев Р.* Водные пути Дунайской Болгарии в эпоху средневековья и проблемы связей с Волжской Булгарией // Великий Волжский путь. Материалы

Круглого стола и Международ. семинара / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Мастер Лайн, 2001. С. 224–234.

*Рашев Р.* Прабългарите през V–VII век. Изд. 2-е, доп. София, 2004. 348 с.

*Рашев Р.* Великая Болгария. Первое Болгарское царство на Дунае // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: РухИЛ, 2006. С. 36–59.

*Рашев Р.* Праболгары на юго-западной окраине евразийской степи // Средневековая археология евразийских степей. Материалы Учредит. съезда Международ. конгресса. Т. 1 / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2007. С. 104–117.

*Рашев Р., Дочева В.* Юртообразен постройка в Плиска // Проблеми на прабългарската история и култура. Вып. 2. София, 1989. С. 291–313.

*Татищев В.Н.* История Российская. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1962. Т. 1. 500 с.

*Халиков А.* Към въпроса за археологическите извори на културата на прабългарите // Проблеми на културата. Кн. 4 / отгов. ред. Р. Рашев. София, 1981. С. 9–15.

*Халиков А.* Изучение археологической культуры ранних болгар на Волге // Плиска – Преслав. Кн. 2. Прабългарската култура. Материали от българо-съветската среща, Шумен, 1976 / отгов. ред. Дм. Ангелов. София: Изд-во. БАН, 1981а. С. 36–42.

*Халиков А.* Культурно-исторические связи между Дунайской и Волжской Булгариями // Международ. конгресс праболгаристики. София, 1982. С. 381–387.

*Халиков А.Х.* Семеновский клад железных изделий // Плиска – Преслав. Кн. 3 / отгов. ред. Р. Рашев. Шумен, 1983. С. 254–261.

*Халиков А.* Рец.: Дм. Димитров. Прабългарите по Северното и Западното Черноморие. (Към въпроса за тяхното присъствие и история в днешните руски земи и ролята им при образуването на Българската държава. Варна: Изд-во «Георги Бакалов», 1987 // Исторически преглед. 1988. Кн. 5. С. 85–88.

*Халиков А.Х.* Булгарская руника в Среднем Поволжье // Археология (София). 1988а. № 2. С. 36–48.

*Халиков А.Х.* Протоболгары и протовенгры в Среднем Поволжье и Нижнем Прикамье // Проблеми на прабългарската история и култура / отгов. ред. Р. Рашев. София, 1989. С. 55–65.

*Хузин Ф.* Ново за двете Българии: Волжска и Дунавска (рец. на: Г. Владимиров. Волжска и Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели (VII–XI в.). София: Изд-во «Орбел», 2005) // Исторически преглед. 2007. № 1–2. С. 232–235.

*Хузин Ф.Ш.* Выдающийся исследователь археологии и истории дунайских болгар: профессор Рашо Рашев // Хузин Ф.Ш. Исследования по булгаро-татарской археологии. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2011. С. 283–286.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты*
*баш гыйльми хезмәткәре*

# Б.К. МИҢНУЛЛИННЫҢ «XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫНЫҢ ЖАНР ҺӘМ СТИЛЬ ДИФФЕРЕНЦИЯСЕ» МОНОГРАФИЯСЕ ТУРЫНДА

*Миннуллин Б.К.* Жанрово-стилистическая дифференциация татарской газеты начала XX века / Б.К. Миннуллин. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – 220 с.

Кешелек дөньясында тел мәсьәләләре һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Җәмгыять телдән башка яши алмый. Һәр милли тел үз халкын яшәтүгә хезмәт итә, аның милли йөзен саклый. Үз теленә игътибарлы булу, аны өйрәнү һәм камилләштерә бару, матур һәм чиста тоту һәркемнең мөкатдәс бурыч-гамәлләреннән берсе булып тора. Бу юлда һәр иҗтимагый катлам үз өлешен кертә бара. Милли телләрнең үз үсеш һәм яшәеш кануннары бар. Аларны галимнәр ачыклый һәм аңлаталар. Моның өчен тел үзенчәлекләрен төрле юнәлешләрдә, аерым алганда, фәнни-тарихи нигездә дә өйрәнәләр. Тел гыйлеменең көче һәм әһәмияте аның милли тел яшәеше өлкәләренә үтеп керүенә дә, шул өлкәдәге үзенчәлекләре кагыйдәләрен ачыклавына да бәйле. Шушы яктан әһәмиятле һәм кызыклы хезмәтләрнең берсе – күптән түгел дөнья күргән китаплардан, галим Бәхтияр Ким улы Миңнуллинның «Жанрово-стилистическая дифференциация татарской газеты начала XX века» («XX гасыр башы татар газетасының жанр һәм стиль дифференциясе» Казан: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгат институты, 2019. 220 б.) монографиясе булды.

Хезмәт татар журналистикасы теле тарихына багышланган һәм гомумән дә журналистика һәм язма тел тарихлары кисешендә мәйданга куелган. Анда төп игътибар XX гасыр башы татар журналистикасында текст төзүдә тел үзенчәлекләрен файдалану юлларын барлауга юнәлтелгән.

Б.К. Миңнуллин бу юнәлештә фәнни тикшеренүләрне һәм эзләнүләрне күптәннән алып бара, табышларын фәнни җәмәгатьчелек белән гыйльми хезмәтләре аша даими таныштырып тора. XX йөз башында татар газеталарының халыкка хәбәрләрне җиткерүдә тел чараларыннан ничек файдалануларын тикшереп, ул шул еллар вакытлы матбугаты текстларында хәбәрләрне репортерларның үткән заман тойгысы белән генә түгел, хәтта фигыльләрнең дә үткән заман формаларын кулланып язуларын ачыклаган. Моның хикмәте шунда: фәндә әлегә татар газеталарының укучыларга мәгълүматларны үткән заманда, булган вакыйгалар рәвешендә җиткерүләре фактын ныклы нигездә дәлилләп аңлатып биргән хезмәт әлегә юк иде. Б.К. Миңнуллин татар журналистикасы теленең шушындый юнәлеш тотуын халыкның тормыш чынбарлыгын күзаллавына һәм аңа мөнәсәбәтенә бәйли, тел формаларында иҗтимагый аң үсеше үзенчәлекләрен күзәтә һәм билгели. Шуның белән ул әдәби тел тарихы фәнендә моңарчы урын

алган фәнни-теоретик фикерләрне тагын бер тапкыр тикшерә, тел гыйлеме офыкларын киңәйтә, эчтәлектә һәм теоретик фикерләмәләрдә карашларны алга таба үстерүгә ирешә. Тел гыйлеменең коры формаларны өйрәнүдән генә түгел, бәлки актив иҗтимагый яшәеш белән бәйле булуын татар газеталары теле материалында, мисаллар күрсәтеп дәлилләве белән дә бу хезмәт фәнни әһәмияте ягыннан югары бәяләүгә мохтаҗ. Болай дип белдерү исә монографиянең аерым мәсьәләләренә безнең яктан фикеребезне аңлатуны, фикерләмәләргә махсус күзәтүләр ясауны таләп итә. Хезмәттән күренгәнчә, аларның беренчесе тормыштагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисади шартларның кискен үсеше сәбәпле милли үзаңның үзгәрешенә бәйле постулаттан чыгып фикер йөртүгә корылган.

Б.К. Миңнуллин XX йөз башын татар милләте тарихи үсешендә «үзенчәлекле дәвер» буларак билгели. Бу дәвер татарга вакытлы матбугат биргән. Галим моны Россия тормышындагы зур яңалык дип бәяли. Матбугат, ул күрсәткәнчә, милли аң үсешенә дә, ил тормышына да көчле тәэсир ясый, татарның дөньяны күзаллавын шактый киңәйтә, аның дини карашлардан дөньяви фикерләргә күчешен, бу юнәлештә үсешен тизләтә һәм ныгыта. Б.К. Миңнуллин бу постулаттан икенчесенә килә, анысы исә тормыш һәм күзаллау үзгәрешенең милли телгә тәэсирен ачыклауга һәм бәяләүгә корылган. Аны галим газета текстларының лексик-грамматик төзелешләрендә чагылуын тел гыйлеме чаралары ярдәмендә тикшерү һәм бәяләү аша аңлатуга алына. Монографиянең кереш өлешендә үк ул бу чор газеталары текстларының структур-композицион яктан үзенчәлекле булуын белдерә. Бу исә хезмәттә вакытлы матбугат теленең аерым бер чорга хас үзенчәлекләре алынып тикшерелүен аңларга ярдәм итә. Димәк, автор мәсьәләгә тарихи яктан караган, милли аң һәм күзаллауның аерым бер тарихи чордагы үзенчәлекләрен билгеләгән булып чыга. Шулай итеп, аерым алганда, шушы ике төп постулат хезмәттә дәлилле тикшерелә һәм тел тарихы кысаларында ачык аңлатыла.

Монографиянең эчтәлеге фәнни, нигезле язылуы белән ышандыра һәм укучыны җәлеп итә. Анда әдәби тел яшәешенең гомуми теоретик мәсьәләләре кысаларында «газета теле», «публицистик стиль» проблемалары алга куеп тикшерелә, татар вакытлы матбугаты оешу һәм аның башлангыч үсеш этапларына бәйле сораулар тел җәһәтеннән чыгып күтәрелә, аларга ачык җавапларның булуы, публицистик стильнең турыдан-туры иҗтимагый-сәяси һәм икътисади үсеш шартларына бәйле икәнлеген ачыклавы авторга җитди фикерләү юнәлешен тотарга мөмкинлек бирә. Б.К. Миңнуллин татар матбугаты теленең XX йөз башы татар әдәби теле яңаруында төп рольне уйнавын да тел материалы нигезендә дәлилле итеп аңлатып бирә һәм бу чорда газета теленең җәмгыять үсешендә төп әйдәүче функцияне башкаруы һәм милли аң үсешенә хезмәт итүче, иҗтимагый доминанта ролен үтәвен дә төгәл билгели. Биредә, шушы мантыйкта өстәмә фикер йөртеп, моңа кадәр татар тормышында дини оешмаларның

төп иҗтимагый көч булганлыгын, XX йөз башында аларны вакытлы матбугат алыштыруын, бүгенге көндә социаль челтәрләрнең, ягъни онлайн-платформаның, вакытлы матбугатны алыштырып, шушы ук рольне үтәүгә омтылышын билгели алабыз. Бу фактларның барлыгын күрү исә Б.К. Миңнуллин хезмәтенең фәнни-иҗтимагый әһәмиятен тагын да ачык күзаллауга этәрә. Киләчәктә, димәк, шушы мантыйкта фикер йөртсәк, онлайн-платформа иҗтимагый яшәештә төп әйдәп баручы көчкә әверелеп, иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тормышыбызда үз ролен башкарачак, әдәби тел үсешенә дә аерым өлешен кертәчәк дип фаразлый алабыз.

Асыл фәнни постулат буларак, Б.К. Миңнуллин монографиясенең башыннан ахырынача татар журналистикасы жанрларының газета текстлары теленә, аларның төзелеш-композицион һәм лексик-стилистик төзелешенә йогынтысы мәсьәләсе үзәктә тора. Галим татар вакытлы матбугатында ул чорда аналитик жанрларның актив булуын билгели, моның мәкаләләрдә үткән заман фигыль формаларын гына түгел, үткән заман эффекты белән язуны да китереп чыгаруы сәбәпләрен тулысынча аклый. Иҗтимагый аң үсеше кысаларында тел үсеше мәсьәләләрен бәяләгәндә, татар халкында ул елларда үткәнгә мөнәсәбәт белдерү, аны аңлау һәм аңлату мәсьәләләре актуаль булган. Шушындый ачышлары белән Б.К. Миңнуллин тел тарихы материалыннан фәлсәфи-психологик нәтиҗәләр дә чыгара, аларны тел үзенчәлекләрен күзәтү өчен файдалана. Мондый тәвәккәл һәм ышанычлы аңлату юлын сайлап алуы хезмәтнең фәнни әһәмиятен тагын да үстерә.

Монографиядә татарның XX гасыр башы алдынгы милли матбугаты саналган «Борһаны-тәрәккый» (1906–1911), «Вакыт» (1906–1918), «Кояш» (1912–1918) газеталары материаллары үзәккә алып тикшерелә. Алар 1906–1918 еллар аралыгында Әстерхан, Оренбург, Казан калаларында басылып чыкканнар, татар төбәкләренең иҗтимагый, сәяси, икътисади үсешендә алдынгы рольләрне үтәгәннәр. Шушы газеталар янәшәсенә Б.К. Миңнуллин Петербург, Уфа, Уральск вакытлы матбугатын да куярга мөмкин дип саный. «Борһаны-тәрәккый» газетасына килгәндә, мәсәлән, ул аның Әстерхан губернасында рәсми татар газетасы ролен башкаруын искәртә, башка матбугат органнарыннан аермалы буларак, Төркестан мөселманнары һәм Төркия белән бәйләнеше тыгыз булганлыгын ассызыклый. «Вакыт» газетасы татарда иҗтимагый-сәяси һәм икътисади-мәдәни карашларны оештыруда һәм ныгытуда аерым роль уйнаган, аның тикшерүдән читтә калдырылуы берничек тә үзен акламас иде, билгеле. «Кояш» газетасына килгәндә, бу вакытлы матбугат органы үзен татар җәмгыятенең һәртөрле катламнарына да «яраклы» итеп күзаллатуны максат итеп куйган, һәр кулга барып ирешерлек бәясе арзан газета булу сәясәтен тоткан. Исемен дә шуның өчен һәркемгә тигез караучы, һәркайда нуры ирешүче кояшка бәйле алган.

Гарәп әлифбасы нигезендә язылган материалларны үз яңгырашларында бүгенге фәнни кысаларда дөрес итеп бирү мәсьәләсендә

галимнәр туктаусыз эзләнә. Төгәл, дөрес, аңлы принциплар фәнни югарылыкта эшләнгән, анысы. Әмма алар белән бәйле сораулар да туктаусыз тумый калмыйлар. Б. К. Миңнуллин бу мәсьәләне дә дөрес һәм уңышлы хәл иткән, мисалларны латин графикасында бирү юлын сайлаган.

Хезмәттә латин язуының татар өчен иң уңышлы, авазларны чагылдыруда уңай икәнлеген һәрдаим тоеп укыйсың. Текстларны һәм алардан мисалларны алганда галим аналитик мәкаләләр белән генә чикләнмичә, мәкалә-хәбәрләрдәге тел үзенчәлекләренә дә, әдәби текстларга да игътибарын юнәлткән. Мисаллардан ачык күренгәнчә, татар вакытлы матбугатында аналитик мәкаләләрнең активлыгы алар янәшәсендә бастырылган башка жанрдагы һәм юнәлештәге материалларның тел җәһәтеннән бирелешенә дә йогынты ясаган. Мисалга алынган әсәрләр арасында очеркларның һәм фельетоннарның өстенлек тотуы шул чорда аларның активлыгы сәбәпле икәнлеге аңлашылып тора. Әдәби текстларга тукталганда галим чәчмә әсәрләр белән генә чикләнми, тезмәләрдән мисаллар китерә. Димәк, хезмәттә әдәби телне аның публицистик һәм сәнгати-художестволы тармакларында тикшерү максат итеп куелган, аларда төрле югарылыктагы сөйләмнең чагылышы бәяләнгән.

Гомумән алганда, татар вакытлы матбугатына кадәрге дәвердә татар теле дини лексика белән сугарылган булган, әдәби телдә авыр һәм катлаулы стилистик формалар өстенлек иткән. Газеталар теле иҗтимагый аңга, аның белән бергә әдәби һәм сөйләм телләренә йогынты ясаган, халыкта аналитик фикерләү көч алган. Бу исә – халыкның аң-белемдә үсеш күрсәткече дә. Милләтнең ул чорда, хорафатчыл карашлардан китеп, реаль тормыш проблемаларын чишәргә омтылыш хисләре белән яши башлавы да шул хакта сөйли. Б.К. Миңнуллин күтәргән материаллар, аларга булган бәяләмәләр, галимнең мантыйклы фикер йомгаклары шушыларны аңлауга этәрә. Хезмәт җитди, объектив тонда язылган, аның фәнни-иҗтимагый әһәмиятен төрле яклап югары булуын инкяр итү мөмкин түгел.

Публицистика теле, язма әдәби телнең бер өлкәсе буларак, гади сөйләм теленнән әдәбилеге белән аерылып тора. Матур әдәбият теле тасвири нигезгә корылса, публицистика теле, сөйләм теленә якынаюына карамастан, әдәбилектән китми. Матур әдәбият теленнән аермалы буларак, ул сурәтле фикерләмәләр бирүдән читләшүеннән тыш, хәбәри һәм аналитик мәгънәләрне укучыга җиткерүдә фикри көче, әйдәүче характерга корылуы белән алыштыргысыз. Б.К. Миңнуллин үз хезмәтендә моны дөрес аңлап һәм ачык аңлатып эш иткән, соңгы елларда фәндә дә очрый башлаган шикле карашларга һәм хаталы күзаллауларга бирешмәгән, ахыргача объектив кала белгән. Бу хакта ул монографиянең йомгаклау өлешендә дә искәртергә кирәк тапкан. Хезмәтнең ахырында урнаштырылган чыганаклар, фәнни-теоретик хезмәтләр исемлеге дә җитәрлек дәрәҗәдә бай һәм җитди. Алар да монографиянең фәнни югарылыгы хакында сөйлиләр.

Монографияне укыганда, алга таба шушы юлда фәнни тикшеренү эшләре тагын да киңрәк планда дәвам иттерелер дигән өмет уянмый калмый. Яшь галим Б.К. Миңнуллин уңышлы методик-методологик алымнар тапкан. Алар алга таба фәнни хезмәтләрдә тагын да үстерелергә, тирәнәйтелергә һәм ныгытылырга тиеш. XX гасыр башында Россиянең төрле төбәкләрендә чыгып килгән күпсанлы татар вакытлы матбугаты органнарында шул елларга хас татар теле үзенчәлекләренең грамматик күрсәткечләре кулланылышы мәсьәләсен тикшерү, – дөресен әйтик, катлаулы һәм четрекле эшләрнең берсе, бу өлкәдә шөгыльләнүчеләрдән зур гыйлемнәр һәм киң хәбәрдарлык таләп итә. Андый хезмәтләр язылганда, шул юнәлештә фәнни тикшеренү эшләре дәвам иткән очракта, хәзерге татар газеталарының текст һәм тел төзелешенә караган мәгълүматлар да киңәер, матбугат теленә карата таләпләр дә артыр иде.

***Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

# А.Ф. ГАНИЕВАНЫҢ «ХХ ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ПРОЗАСЫ («КЕШЕ ҺӘМ ТАБИГАТЬ» МӘСЬӘЛӘСЕ)» МОНОГРАФИЯСЕНӘ РЕЦЕНЗИЯ

*Ганиева А.Ф.* XX гасырның икенче яртысы татар прозасы («кеше һәм табигать» мәсьәләсе) / А.Ф. Ганиева. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 152 б.

Әдәби мирасыбызда кешелекнең мәңгелек мәсьәләләрен үзәккә куйган әсәрләр аз түгел. Аларның озын гомерлелеге, гади укучыны да, әдәбият белгечләрен дә үзләренә җәлеп итүләренең сере дә шунда. Кеше һәм табигать мәсьәләсе дә шундыйлардан. Борынгы мифлардан алып бүгенге чор әдәбиятында да бу мәсьәлә үткенлеген югалтмый. Һәр заман аны үз төсмере белән баета, чорына хас кискенлеге белән күтәрә һәм хәл итәргә алына. Әдәби әсәрләрдә кешенең табигатькә мөнәсәбәте чагылышын өйрәнгән Айгөл Ганиеваның монографиясе әдәбиятыбыздагы бу юнәлешнең XX гасырның икенче яртысы татар прозасында хәл ителешен фәнни яссылыкта тирәнтен анализлауга корылган. Бүген – Җирнең киләчәк язмышына куркыныч елдан-ел ныграк янаган вакытта хезмәт аеруча актуаль яңгыраш таба.

Авторның әлеге мәсьәләне өйрәнүне алтмышынчы еллардан башлавының билгеле сәбәпләре бар. Бердән, бу илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыятькә мөнәсәбәттә каралса, икенчедән, фәнни-техник ярыш, илдәге кинәт үсеш алган гигант төзелешләрнең табигатькә зур зыян китерүен ныклап аңлый башлаудан килә. Башка әдәбиятлардагы кебек, татар язучылары алдына да халыкта экологик аң тәрбияләү ихтыяҗы баса. Экологик аңны халыкның табигатькә бәйле гасырлар буе формалашкан әхлакый кануннарыннан башка күз алдына китереп булмый. Билгеле, халыкның табигатькә мөнәсәбәте аның милли рухы, яшәү рәвеше һәм милли-әхлакый гореф-гадәтләре белән тыгыз бәйле. А. Ганиева әдәби әсәрләрне табигать – милләт – әхлак үремтәсе яктылыгында бәяли. Шуңа әлеге хезмәт фәнни генә түгел, иҗтимагый-әхлакый әһәмияткә дә ия.

Автор үзе өйрәнгән чорны икегә бүлеп карый. Беренче чор – 1960–1970, икенчесе 1980–2000 елларны колачлый. Әлеге бүленеш язучыларның табигатькә мөнәсәбәттә карашларының үзгәреш кичерүе белән аңлатыла. Илленче елларның ахырыннан башлап, рәсми пропаганда сәнәгать өлкәсендәге яңарышларны хуплап торса да, аерым язучылар табигатькә килгән зыян турында яза башлыйлар. А. Ганиева татар әдәбиятына экологик тематиканы нефть сәнәгате өлкәсен яктыртучылар алып килде, дип саный. Хезмәттә моңа бәйле Р. Төхфәтуллин, М. Хәбибуллин повестьлары тикшерелә. Язучыларның публицистик кискенлектән акрынлап әдәбилеккә күчүләре, игенче психологиясен ачуга әһәмият бирүләре игътибарага алына.

Иҗатының зур өлешен «кеше һәм табигать» мәсьәләсенә багышлаучы буларак, Ә. Баянов прозасына, «табигать – милләт – әхлак» мәсьәләсен киң колачта күтәргән Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романына, Х. Сарьян повестьларына монографиядә аерым игътибар бирелә. Әлеге әсәрләрне анализлау барышында табигатьнең зур әхлакый-тарихи мәгънәдә, ягъни кешелек буыннарын берләштерүче кыйммәт итеп сурәтләнүе әйтелә. «Язучылар табигать белән бәйле халыкның яшәү рәвешен, әхлакый-рухи кануннарны, үзара мөнәсәбәтләрне, үткән дәверләргә һәм ата-бабаларга, балаларга һәм киләчәккә юнәлтелгән карашларны – милләт фәлсәфәсе буларак ачалар, бигрәк тә хәзерге заманда буыннар чылбыры өзелү куркынычын кисәтәләр. Әдәби әсәрләрдә милли фәлсәфә – гомумкешелек фәлсәфәсе югарылыгына күтәрелә: шул рәвешле, җирдә тормыш дәвам итсен өчен, адәм баласының төп тереклек итү урыны булган табигатьне саклап калырга чакыру калкып чыга» (б. 54) диелә хезмәттә.

«1980–1990 еллар прозасында “кеше – табигать” темасының бирелеше» дип аталган икенче бүлектә әлеге мәсьәләне аңлауда язучылар иҗатында үсеш-үзгәреш барлыкка килүе күрсәтелә. Алда каралган әсәрләрдә фән-техника алгарышы һәм табигать арасындагы каршылыклы, катлаулы мөнәсәбәтләрне ачуга әһәмият бирсәләр, алга таба инде кешене табигать баласы итеп күрсәтүгә һәм аның хәзерге цивилизация белән конфликтка керүен ачуга басым ясала. Әлеге бүлек кешенең табигатьтән читләшүенең аянычлы нәтиҗәсе итеп җан экологиясенә, ягъни рухи тетрәнүләргә китерүен ачыклау ягыннан әһәмиятле. Ф. Бәйрәмованың «Болын», С. Шәмсинең «Соңгы юаныч», Р. Фәизовның «Тәңре хөкеме», Р. Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк», Х. Сарьянның «Җәза», Мансур Вәлиевнең «Идел яры», Н. Гыйматдинованың берничә повесте шул яссылыкта анализлана. Язучыларның табигатьне шәхеснең, милләтнең, халыкның яшәү тирәлеге итеп караулары һәм кешенең асылын саклауда аның төп фактор булуын билгеләүләре ассызыклана.

А. Ганиева татар язучыларының ат образын яратып сурәтләве турында яза һәм табигатьне гәүдәләндерүче милли образ буларак атка аерым бүлекчә багышлый. Хезмәттә Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясеннән башлап, Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек». Р. Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк», Г. Сабитовның «Туган җир туфрагы», Ф. Яруллинның «Акбәкәл», Р. Харисның «Ат иярләү», В. Имамовның «Могикан», А. Хәлимнең «Өч аяклы ат»ы кебек повесть-хикәяләре карала. Язучыларның ат образы аша үз чорының мөһим мәсьәләләрен күтәрүе, һәр әдипнең табигать – ат – кеше темасын үзенчә ачуы, моны яшәешнең, милләтнең мөһим мәсьәләләре белән бәйләп аңлатуы өйрәнелә.

А. Ганиева анализ барышында әсәрләрнең идея-проблематикасы белән бергә сәнгати якларына да игътибар итә. Шунысы да кызыклы, ул табигать турындагы прозага хас үзенчәлекләрне билгели һәм аларны аерым бүлекчәгә чыгарып өйрәнә. Монда әлеге әсәрләрнең

поэтикасындагы типологик моментларны ачуга басым ясала. Моңарчы әдәбиятта стилистик чара рәвешендә кулланылып килгән пейзажның функцияләре киңәю, фольклор мотивларыннан һәм поэтик чараларыннан иркен файдалану, халыкның үткәненә, борынгы яшәү рәвешенә еш мөрәҗәгать ителү, әлеге әсәрләрнең структурасын барлыкка китерүдә, аерым алганда, риваять һәм мифларның мөһим роль уйнавы, әхлакый хәтер, намус, вөҗдан, шәфкатьлелек, туган йорт, нигез, нәсел шәҗәрәсе кебек категорияләрнең идея-эстетик әһәмияте арту, табигатькә мөнәсәбәтле рәвештә төп герой итеп еш кына яшь кеше, үсмер бала яки хатын-кыз алынуы – язучылар еш мөрәҗәгать иткән чаралар буларак билгеләнә.

Табигатькә мөнәсәбәт мәсьәләсе бик мөһим булган хәзерге заманда бу турыда язылган әдәби әсәрләрнең әһәмияте арта. А. Ганиева табигать турындагы татар прозасының барлыкка килү алшартларын, үсеш-үзгәрешен, милли үзенчәлекләрен билгели алган.

Әлеге хезмәт XX гасырның икенче яртысы татар прозасында кеше һәм табигать мөнәсәбәтләренең бирелешен төрле яссылыкта ачып кына калмый. Ул татар халкының гасырлар дәвамында калебенә сеңеп яшәгән, аның җанын күренмәс җепләр белән табигать белән тоташтырган, яшәү чыганагы булган кендек тамырыдай рухын азыкландырган гаять зур бер көч барлыгын дәлилли. Язучыларыбыз тудырган образларны, күтәрелгәнгән мәсьәләләрне, әсәрләрнең тукымасына сеңгән фикер, идеяләрне җентекләп тикшерү кешенең табигать белән бер тамырдан булуына ышандыра. Табигатькә килгән афәт кешенең рухын гарипләндерә, яшәешебезне ярлыландыра дип раслый.

А. Ганиева, хезмәтнең фәнни ягына зыян китермәгән хәлдә, киң катлам укучыны җәлеп итәрлек, аны уйландырырлык китап тәкъдим итә.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 7.072.3

***Э.М. Галимова***

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ МУЗЫКАЛЬ МИРАСЫ ФОРМАЛАШУ ЧОРЫНДА МӘХМҮТ НИГЪМӘТҖАНОВ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Данная статья посвящена выдающемуся ученому, кандидату искусствоведения, профессору, музыковеду, этномузыкологу, заслуженному деятелю искусств, лауреату государственной премии им. Г. Тукая Махмуту Нигмедзяновичу Нигмедзянову, в связи с его 90-летием со Дня рождения. Основное внимание в работе автор уделяет специфике научной деятельности М.Н. Нигмедзянова, раскрывает его мировоззрение, анализирует научные труды М.Н. Нигмедзянова, в которых раскрыта проблематика музыкально-стилевых особенностей традиционной народной песни татар Среднего Поволжья, выявлены жанровые особенности и сделан акцент на впервые опубликованные экспедиционные образцы татарского музыкального фольклора.

**Ключевые слова:** национальное музыкальное наследие, этномузыкология, татарский музыкальный фольклор, традиционная музыкальная культура татар, этнография.

This article is dedicated to an outstanding scholar, candidate of sciences in art history, professor, musicologist, ethnomusicologist, honored art worker, laureate of the State Prize named after G. Tukay Mahmut Nigmedzyanovich Nigmedzyanov, on the occasion of his 90th birthday. The author focuses on the specifics of M.N. Nigmedzyanov's works, reveals his worldview, analyzes the scientific works of M.N. Nigmedzyanov, in which the problems of musical and stylistic features of the traditional folk song of the Tatars of the Middle Volga region are revealed, genre features are revealed and an emphasis is placed on the first published expeditionary samples of Tatar musical folklore.

**Keywords:** national musical heritage, ethnomusicology, Tatar musical folklore, traditional musical culture of Tatars, Ethnography.

Мәхмүт Нигъмәтҗан улы Нигъмәтҗанов – сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, танылган фольклорчы галим, музыка белгече, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе 2020 елда 90 яшлек юбилеен билгеләп үтте. Шул уңайдан, Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның татар мәдәнияте һәм милли музыка сәнгате өлкәсендәге саллы фәнни хезмәтләрен ассызыклап, әлеге мәкаләне аның күпкырлы иҗат эшчәнлегенә багышларга булдык. Бүгенге көндә Мәхмүт ага безнең арабызда юк инде (2020 елның 4 августында вафат булды), әмма ул туплап калдырган татар музыкаль фольклоры үрнәкләре, фәнни басмалар һәм җыр җыентыклары этномузыкология өлкәсендә яңа буын белгечләрне әзерләүдә төп чыганакларның берсе булып тора.


Мәхмүт Нигъмәтҗанов

Мәхмүт Нигъмәтҗанов 1930 елның 10 нчы маенда Татарстанның Саба районы Олы Арташ авылында туа. Мәхмүт ага әнисенең бәет, мөнәҗәтләрне көйләп әйтүен һәм этисенең халык көйләрен гармунда уйнавын балачак хатирәсенең иң матур мизгелләре буларак искә ала иде. Әйтергә кирәк, танылган галим музыка сәнгате дөньясына шактый урау юллар белән килеп керә. Бөек Ватан сугышы елларында әнисен югалта һәм шул сәбәпле Белгород балалар йортында тәрбияләнә.

Бөек Ватан сугышы барган 1943–1944 елларда хәрби заводта столяр булып эшли, Украина ССРның Кадиевка шәһәрендә һөнәр училищесында укый. Сугыш тәмамланганнан соң, Юдино тимерьюлчылар мәктәбендә, аннары Мәскәү тимерьюлчылар техникумында белем ала. Уку елларында төрле музыка уен коралларында (фортепьяно, труба, тромбон, аккордеон, балалайка, гөсләдә) уйнарга өйрәнә һәм үзешчән сәнгать түркемнәрендә катнаша. 1953 елда Мәхмүт Нигъмәтҗанов Казан дәүләт консерваториясенең теория-композиция факультетына укырга керә. Шунысын әйтергә кирәк, ул студент елларында ук киләчәк тормышының һәм эшчәнлегенең төп юнәлешен анык билгели. Каникул вакытларында мөстәкыйль рәвештә оештырылган фольклор экспедицияләрендә татар халык җырларына зур игътибар бирә, борынгы йола җырларының үзенчәлекләре, халык көйләрен җыю һәм өйрәнү тарихы белән кызыксына башлый. Бу аның татар халык җырларын эшкәртүгә багышланган диплом эшендә дә чагылыш таба. 1958 елда югары уку йортын тәмамлап, башта шунда ук, аннары СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшкә урнаша. 1967–1973 елларда Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе, 1974–1984 елларда шул ук институтта өлкән фәнни хезмәткәр вазифаларын башкаруын дәвам итә. Шул дәвердә М.Н. Нигъмәтҗанов фольклор экспедицияләренең географиясен тагын да киңәйтә, илнең татарлар яши торган һәр төбәгенә бара һәм бик күп материаллар туплый.

Тарих битләренә күз салсак, татар халык иҗатын җыю тарихы XIX гасырның беренче яртысында К. Фукс, И. Снегирев, М. Иванов һ. б. дан башлана. XIX гасырның икенче яртысында татар халык иҗатын җыю һәм өйрәнү эше белән татарлардан Каюм Насыйриның шөгыльләнүе мәгълүм. Ә инде халык моңнарын язу, нотага салу эшен бары тик XX гасырда (этнограф Рыбаковның схематик язмаларын искә алмасак) С. Габәши башлап җибәрә. Бу өлкәдә А. Ключарев, А. Эйхенвальд, М. Мозаффаров зур хезмәт куялар. Халык иҗатын җыю һәм фәнни нигездә өйрәнүгә нигез салучы – күренекле

фольклорчы Хәмит Ярми эшчәнлеге дә аерылып тора. Гомумән, татар фольклористикасы өлкәсендә халык иҗатын фәнни нигездә җыю 1940–1950 еллардан соң гына башлангыч ала.

Әйтергә кирәк, татар халкының музыкаль фольклорын туплау һәм халыкка җиткерүдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республиканың Г. Тукай бүләге лауреаты, профессор М.Н. Нигъмәтҗановның өлеше биниһая зур [Сәйфуллин, б. 114]. М. Нигъмәтҗанов беренчеләрдән булып татарларның төрле этник төркемнәренең халык авыз иҗатын тирәнтен өйрәнә. Әстерхан, Себер, Урал якларында яшәгән татарларның да, керәшен һәм мишәрләрнең дә музыкаль фольклорын барлау һәм туплау юнәлешендә армый-талмый эшли. Аның тарафыннан тупланган 4 меңнән артык халык көйләренең күбесе М. Нигмәтҗановның «Татар халык җырлары» дип исемләнгән һәм өч китаптан торган җыентыгында урын ала. Беренче җыентык 1970 елда басылып чыга. Әлеге фәнни хезмәт хакында күренекле шагыйрь Хәсән Туфан: «М.Н. Нигъмәтҗановның чиксез зур көч куеп чын мәхәббәт белән җыйналган бу гыйльми хезмәтендә биш миллионлы татар халкының йөрәге-күңеле генә түгел, аның гасырлар аша үткән зур, бай гомере дә, тарихы да чагыла. Бу әсәр татар халкының төрле шивәләре эчендәге җырларны табып алып беренче тапкыр дөньяга-мәйданга чыгаруы белән яңа ачыш булып тора», – дип, заманында җәмәгатьчелеккә үз фикерен дә җиткерә. Әлеге җыентыкта тәкъдим ителгән музыкаль фольклор үрнәкләренең географиясе шактый киң. Автор Мордовия, Пенза, Түбән Новгород, Саратов, Пермь, Волгоград, Әстерхан өлкәләрендә яшәгән татарларның стилистик яктан гаять кызыклы һәм үзенчәлекле музыкаль жанрларын йолалар белән бәйләп системалаштыра. М.Н. Нигмәтҗанов бәет жанрларын әлеге басманың аерым бер бүлегенә туплый. Аның фикеренчә, бәетнең сюжеты беренче планда тора, ә көй бары тик метроритм ягын формалаштыра. Фәнни басманың саллы бер өлешен мишәр һәм керәшен татарларының «озын көй», «салмак» һәм «такмак» җырлары тәшкил итә. Кызганычка каршы, «озын көй» җырларын җыентык авторы бер генә нота юлы белән бирә, ә кайбер җыр мисалларының куплет өлешен генә бирү белән канәгатьләнә [Сайдашева, с. 44]. Шуңа күрә мишәр җырларындагы ладо-интонация һәм метроритм белән бәйле үзгәрешләрнең үзенчәлеген билгеләү кыен, һәм каданска корылган икеюллык финал өлеше музыкаль мисалларда бирелмичә кала. 1976, 1984 елларда дөнья күргән җыентыкларның алдагы басмаларында Ласло Викар һәм Габора Берецки белән берлектә тупланган, Татарстан, Мордовия, Башкортстанда, Түмән өлкәсендә язылып алынган экспедиция материаллары урын ала. Әлеге басманың иң отышлы якларының берсе –мөнәҗәт һәм китап уку көйләре жанрларының беренче язмаларын фәнни әйләнешкә кертүдә.

Автор 1984 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән «Татар халык җырлары» җыентыгының элгәреге хезмәтләрендәге җитешсезлекләрне истә тотып эшләнүен искәртә. Әлеге басмада

җырларның классификация принциплары үзгәреш кичерә, җырның жанр һәм диалект үзенчәлекләре игътибарга алына. Шулай ук бу җыентыкка татар халкының «музыкаль эпос» жанрын кертү дә фәнни яктан үзенә бер яңалык буларак кабул ителә. Әлбәттә күп кенә үрнәкләрдә борынгы халык традицияләре чагылыш таба һәм көнчыгыш поэзиясе ритм үзенчәлекләренең йогынтысы сизелә. Мәгълүм ки, Габдулла Тукай шигырьләрен нәкъ менә әлеге музыкаль эпос жанрына караган көйләргә ияреп башкарганнар. Күп кенә татар композиторлары әлеге жанр белән ныклап кызыксына башлыйлар һәм яңа әсәрләр пәйда була. Әлеге хезмәтнең тагын бер уңай ягы нотация белән бәйле. Музыкаль үрнәкләрдә структура, диалект һәм башкару үзенчәлекләре, этнофорлар башкарганча, автор тарафыннан тәфсилләп бирелә.

Әлеге басма өч өлештән тора: беренче өлештә йола җырлары тәкъдим ителә, икенчесендә, мәгълүм булганча, яңа төр буларак музыкаль эпос үрнәкләре кертелә, өченче өлештә лирик җырлар туплап бирелә. Гомумән алганда, әлеге экспедиция үрнәкләре – *озын көйләр, салмак көйләр, авыл көйләре, кыска көйләр, уен көйләре, такмаклар һәм бию көйләре* – фәнни яктан тикшерүнүчеләр тарафыннан үтә нык кызыклы материал буларак кабул ителә.

1987 елда «Советская культура» газетасында басылып чыккан «Как выходить из тупика? дип исемләнгән мәкалә аша да Мәхмүт аганың кызыклы фикерләре белән танышып була. Дистә еллар дәвамында дөнья күргән күп кенә фәнни язмаларында һәм матбугат битләрендә аның белән үткәрелгән әңгәмәләргә корылган сәхифәләрдә, нигездә, бер үк проблемалар күтәрелә. «Бүгенге көндә белемле, зәвыклы музыка белгечләре юк дәрәҗәсендә. Музыка белгече бөтендөнья музыкасыннан киң мәгълүматлы һәм намуслы булырга тиеш», – дип ассызыклый Мәхмүт ага. «Җыр сәнгате буенча берничә махсус югары уку йортларыбыз да бар, югыйсә. Ә нигә соң ул көннән-көн артка тәгәри? Бүгенге көндә С. Сәйдәшев, Р. Яхин, А. Ключаревны алыштыра алырлык, горурланырлык композиторларыбыз нигә юк? – дип борчыла. – Югары зәвыклы милли әсәрләр яза алырлык композиторлар әзерләү өчен татар музыка мәктәпләренең дә милли рухта булуы кирәктер бәлки» [Бәйрәмова, б. 169]... Игътибар итсәк, чыннан да татар мәдәниятен һәм сәнгатен сыйфатлы итеп өйрәнү өчен музыка белеме, этномузыкология өлкәсендә белгечләребез җитәрлек түгел. Булганнарының да күбесе, кызганычка каршы, татарча музыка терминнары белми, язмаларында фикерләрен туган телдә мисаллар белән дәлилләп белдерә алмый. Мәхмүт ага да әлеге зур проблема хакында болай ди: «Чыннан да, бездә татар музыкасын өйрәтүгә тиешле игътибар бирелмәде. Чөнки чын музыка белгече әзерләү, үстерү фәкать милли мохиттә генә мөмкин. Бездә татар телендә укыту гомумән булмады, татар телендә музыка буенча хезмәтләр түгел, мәкаләләр язылганын да хәтерләмим. Киләчәктә бу юнәлештә нәтиҗәле эш башкарырга теләсәк, укыту процессын тамырдан үзгәртү зарур, бүгенге җитәкчелек бу турыда уйлансын иде».

1966–1973 елларда Мәхмүт ага Нигмәтҗанов Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясендә музыка бүлеге мөдире булып эшли. Истәлекләрендә ул әлеге елларны иҗади вакыйгаларга бай чор булды, дип бәяли. Ул татар халык җырының кыйммәтен, татар профессиональ музыкасының үзенчәлеген, Европа композиторлары иҗат иткән әсәрләрнең безнең милли сәнгатебезгә ни дәрәҗәдә кирәкле һәм әһәмиятле булуын тирәнтен аңлый. Нәкъ шул чорда филармониягә, дөресрәге, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Н. Исәнбәт, Ә. Нарыков, Ф. Гаскәров, Г. Таһиров кебек талантлы сәнгать әһелләре, М. Нигъмәтҗанов тәкъдиме белән, эшкә чакырыла һәм аларның эшчәнлеге чын мәгънәсендә фидакярлек үрнәге була.

Әйтергә кирәк, Мәхмүт Нигъмәтҗановның эшчәнлеге, әйткәнебезчә, чит илләрдә, шул исәптән, Венгрия, Германия, Финляндия һәм Монголиядә, Казакъстан, Үзбәкстан һәм башка төбәкләрдә дә киң танылды һәм хезмәттәшләренең югары бәясенә лаек булды. Шул уңайдан атаклы музыка белгече, сәнгать фәннәре докторы Е.В. Гиппиус Мәхмүт ага хакында болай дип яза: «Татар халык иҗатын өйрәнүче, бөртекләп җыючы күренекле галим Мәхмүт Нигъмәтҗановның исеме, Россиядән тыш, чит илләрдә дә яхшы таныш. Ул башкарган хезмәт фәнни нигезгә корылган. Мәхмүт Нигъмәтҗанов татар халык иҗатын өйрәнү өлкәсендә кискен борылышка иреште. Татар халык җыр сәнгатенең традицион жанрларын һәм стилен яңача өйрәнүгә нигез салды» [Ильясов].

1979 елда музыка сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен Мәхмүт Нигъмәтҗановка Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. 1985 елда ул татар халык җырларына багышланган хезмәтләре өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның «Народные песни волжских татар», «Татарские народные музыкальные инструменты», «Тукай һәм музыка», «Татар халык җырларының төзелеше» һәм башка хезмәтләре фәнни яктан яңалык алып килгән энҗе бөртегенә тиң басмалар дип әйтсәк тә ялгыш булмас.

**Әдәбият**

*Бәйрәмова Г.* Кыйммәтле хәзинә остасы // Казан утлары. № 5, 2010. Б. 166–176.

*Ильясов Р.* Олы юлның тузаны ла // Мәдәни җомга. 2015. 28 май.

*Сайдашева З.Н.* Очерки по татарской музыке. Казань: Изд-во «Халкыбыз мирасы», 2015. 260 с.

*Сәйфуллин Р. Т.* Музыка дәресләре: 5–7 нче сыйныфлар: укытучылар өчен методик кулланма. Казан: Мәгариф, 2004. 183 б.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

**2020 елның 30 сентябреннән 2 октябренә кадәр** «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау оешмаларының XIX Бөтенроссия съезды узды. Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган форум кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А. Халиков исемендәге Археология институты тарафыннан мәдәни мирас объектларын саклау проблемасына багышланган күргәзмә оештырылды.

Съездга Россиянең 70 тән артык төбәгеннән 400 гә якын делегат чакырылган иде. Чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыева, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Мәдәни мирасны дәүләт саклау департаменты директоры Р.А. Рыбало, Федераль Җыен Дәүләт Думасы Комитеты Рәисенең беренче урынбасары Е.Г. Драпеко, Россия Федерациясе Комиссиясенең ЮНЕСКО эшләре буенча Җаваплы секретаре, Россия Тышкы эшләр министрлыгының аерым йөкләмәләр буенча илчесе Г.Э. Орджоникидзе һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты.

Съезд эше барышында Бөтендөнья мирас объектларын, археологик мирас берәмлекләрен саклау һәм аларга тарихи-мәдәни экспертиза үткәрү, бу объектларны дәүләт тарафыннан саклау өлкәсенә кагылышлы башка мөһим мәсьәләләр күтәрелде.

**2020 елның 6–8 октябрендә** Ульяновск шәһәрендә «XX–XXI гасыр башында төбәкләр киңлегендә тарихи хәтерне трансформацияләү» II Халыкара тарихчылар, фәлсәфәчеләр һәм публицистлар форумы үткәрелде. Чара кысаларында В.И. Ленин исемендәге Китап сараенда (Ульяновск өлкәсе фәнни китапханәсе) Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең хезмәтләре тәкъдим ителде һәм, Институтның фәнни экспедиция эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дөнья күргән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары» китабы презентациясе оештырылды.

Очрашу барышында Ульяновск өлкәсенең стратегик тикшеренүләр үзәге һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты арасында фәнни хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Казан галимнәре Ульяновск өлкәсе фәнни китапханәсенә һәм Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясенә Институт тарафыннан соңгы елларда нәшер ителгән китапларны тапшырдылар.

**2020 елның 20 октябрендә** Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчелегендә Яр Чаллы педагогика университетында «Белем бирү эшчәнлеге контекстында мәдәниятләр диалогы» темасына Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференциядә мәктәпкәчә, урта, урта махсус, өстәмә, югары һөнәри белем бирү оешмалары белгечләре, югары уку йортлары укытучылары, фәнни хезмәткәрләр, магистрантлар һәм студентлар катнашты. Секция эшләре мастер-класслар, тренинглар, семинарлар форматында оештырылды.

**2020 елның 21 октябрендә** Казанда мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәре Форумы оештырылды. Форум 2011 елдан

башлап Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгариф фонды һәм Россия ислам институты белән берлектә үткәрелеп килә, мөселман мәгарифе һәм тәрбиясе өлкәсендәге мөһим мәсьәләләр турында фикер алышу һәм аларны хәл итү өчен мәйданчык булып тора.

Агымдагы елда әлеге форум «Хәзерге Россиянең фәнни-мәгариф киңлегендә традицион диннәр теологиясе» халыкара симпозиумы кысаларында оештырылды. Симпозиумда шулай ук мөселман мәгарифе үсешенә кагылышлы мәсьәләләр каралды. Чарада катнашучыларга Болгар ислам академиясендә магистрлар һәм докторлар әзерләү системасы, Татарстанда дини һәм дөньяви уку йортларының хезмәттәшлек итүе, башлангыч баскычта белгечләрне дини белем бирү стандартларын кулланып әзерләү, дини мәгариф оешмаларында укыту эшчәнлеген дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып алып бару, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру һ.б. белән танышу мөмкинлеге тудырылды.

**2020 елның 20–21 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Бөек җиңүнең 75 еллыгына багышланган «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы: халык батырлыгы һәм тарих дәресләре» дигән темага Халыкара фәнни онлайн-конференция үтте. Конференция программасына Россия, Беларусь, Германия, Казакъстан, Кыргызстан галимнәре, укытучылары, музей хезмәткәрләре докладлары кертелгән иде. Конференция кысаларында сугыш еллары тарихын өйрәнүнең концептуаль проблемалары турында фикер алышу оештырылды, тарихи хәтерне саклау проблемалары күтәрелде.

**2020 елның 22–25 октябрендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Шәрык һәм Гареб контекстында төрки халыкларның әдәбияты һәм сәнгате» Халыкара фәнни-гамәли онлайн-конференциясе оештырылды. Конференциядә Россия Федерациясенең төрле төбәкләреннән, Казакъстан, Азәрбайҗан, Иран, Үзбәкстан, Каракалпакстан, Кыргызстан, Таҗикстан Республикаларыннан йөздән артык галим, аспирант һәм магистрлар катнашты.

Онлайн-конференция кысаларында «Шәрык һәм Гареб: әдәбият һәм мәдәниятләренең үзара йогынтылары аспектлары», «Шәрык һәм Гареб фәлсәфи-эстетик фикере контекстында әдәби-гыйльми эзләнүләр», «Дөнья мәдәнияте контекстында төрки халыкларның фольклористикасы», «Әдәби текст: тел, стиль һәм структура» темаларына секцияләр эшләде. Аларда төрки халыкларның фәнни-гыйльми, әдәби-тарихи һәм культурологик аспектларда әдәбият һәм мәдәниятләренең актуаль проблемалары; тел гыйлеме һәм тюркологиянең көнүзәк мәсьәләләре тикшерелде.

**2020 елның 1–6 декабрендә** Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында «Һөнәр» XII Бөтенроссия яшь режиссура фестивале узды. Фестивальне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Театр әһелләре берлеге оештырды. Чараның максаты – яшь режиссерларга профессиональ мохит тудыру, аларның иҗатын киң катлам тамашачыга җиткерү, театрлар белән хезмәттәшлек итәргә булышу.

Фестивальдә Россиянең 11 шәһәреннән 23 спектакль тәкъдим ителде, алар сигез театр мәйданчы-

гында – Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театрында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Казан дәүләт яшь тамашачылар театрында, «Әкият» курчак театрында, «Угол» иҗат лабораториясендә, Казан Ратушасында һәм Werk арт киңлегендә уйналды. Фестиваль кысаларында танылган театр тәнкыйтьчеләре белән очрашу-лекцияләр циклы оештырылды.

**2020 елның 4 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «XX–XXI гасырларда милли әдәбиятларның жанр-стилистик үсеше» Халыкара фәнни-гамәли онлайн-конференциясе оештырылды. Конференция эшендә Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Россия Федерациясе республикалары (Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Мари Эл, Мордва, Чувашия республикалары) галимнәре, шулай ук югары уку йортлары укытучылары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Конференцияне ачып, анда катнашучыларны Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин сәламләделәр.

Сәламләү сүзләре һәм милли әдәбиятларның жанр-стилистик үсешенең төрле аспектларына багышланган докладлар белән конференциядә Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин, Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе вице-президенты И.А. Габбибейли, Кыргыз Республикасы Милли Фәннәр академиясе Ч. Айтматов исем. Тел һәм әдәбият институтының кыргыз әдәбияты кафедрасы мөдире Н.Т. Ыйсаева, Л.Н. Гумилев исем. Евразия милли университетының казакъ әдәбияты кафедрасы мөдире К.Р. Кеменгер, Уфа федераль тикшеренү үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институтының өлкән фәнни хезмәткәре Н.Ә. Хөббитдинова, М.Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университеты доценты А.Г. Хәлиуллина, Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институтының өлкән фәнни хезмәткәре И.Ю. Кириллова, Россия Фәннәр академиясе Урал бүлеге Удмурт федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре А.А. Арзамазов һәм башкалар чыгыш ясады. Докладларда жанр һәм стильләр теориясендә яңалыклар; әдәби жанрлар һәм стильләр үсеше һәм үзгәреше; милли әдәбиятларда жанр-стиль эзләнүләре; XXI гасыр әдәбиятында жанр үзгәрешләре; кануни һәм кануни булмаган жанрлар һәм аларның эволюциясе; XX гасыр азагы – XX йөз башы әдәбиятында автор жанр стратегияләре һ.б. проблемалар күтәрелде.

Быелгы конференция – Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Россиядә һәм якын чит илләрдәге тикшеренүчеләрне үзара берләштерү, фикердәшләр мохитен булдыру максатыннан гамәлгә ашырыла торган «Милли әдәбиятлар: тикшеренү юнәлешләре һәм аларның гамәли чагылышы» проекты кысаларында узган икенче чара. Беренчесе – «Хәзерге этапта милли әдәбиятлар: фәнни концепцияләр һәм гипотезалар» темасына түгәрәк өстәл 2019 елда оештырылган иде. Аның нәтиҗәләре буенча шул ук исемдәге фәнни мәкаләләр җыентыгы нәшер ителде – ул үз чиратында институтның милли әдәбиятлар проблемалары буенча фәнни басмалар сериясенә нигез салды.

**2020 елның 3–16 декабрендә** Татарстан Республикасы Милли музее күренекле татар композиторы, татар профессиональ музыкасына нигез салучы Салих Сәйдәшевнең 120 еллыгына багышланган декада оештырды.

Декада С. Сәйдәшевның һәйкәленә чәчәкләр куеп искә алудан башланды һәм Татарстан сәнгать осталары катнашында концертлар, «Гомерем минем моңлы бер җыр иде…» күргәзмәсе, балалар өчен мәдәни-белем бирү программасы һәм башка чаралар белән дәвам итте. Facebook, Instagram, Facebook, YouTube социаль челтәрләрендәдә онлайн форматта «Салих Сәйдәшев чорына кайту» дигән махсус проект тормышка ашырылды һәм С. Сәйдәшевкә багышланган флешмоб оештырылды. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында һәм С. Сәйдәшев музеенда «Сәйдәш. Йокысызлык» дип исемләнгән спектакль-лабиринт тәкъдим ителде.

**2020 елның 14 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Төрки халыкларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Абай иҗаты» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли онлайн-конференция үткәрелде. Конференция күренекле казакъ шагыйре, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Абай Кунанбаевның тууына 175 ел тулуга багышланды. Әлеге чараның төп оештыручылары – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казакъстан Республикасының Казандагы Генераль консуллыгы, Л. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты (Нур-Солтан, Казакъстан).

Конференциягә түбәндәге юнәлешләр буенча 60 тан артык фәнни доклад кабул ителде: төрки халыклар мәдәниятендә мәгърифәтчелек парадигмасы формалашу; төрки әдәбиятларда мәгърифәтчелек тенденцияләре: типологик бергәлек һәм милли үзенчәлек; төрки телле милли әдәбиятларны үстерүдә җәдитчелекнең роле; төрки халыкларда мәгърифәтчелек идеяләрен таратуда кульязма һәм басма китапның әһәмияте; төрки халыкларда мәгърифәтчелекне үстерүдә Казан университеты һәм татар мәдрәсәләренең роле; төрки әдәби багланышлар контекстында Абай иҗаты; төрки телле әдәби тәрҗемәләрдә Абай; төрки телле халыклар әдәбиятында һәм тәнкыйтендә Абай образы.

Чарада Татарстан Республикасы һәм Казакъстан Республикасы дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалары, Азәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстаннан һәм Татарстан, Башкортстан, Мордовия, Удмуртия, Чувашия республикаларыннан галимнәр, югары уку йортлары укытучылары, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, вакытлы матбугат басмалары вәкилләре катнашты. Конференция материаллары фәнни җыентыкта урын алды.

**2020 елның 18 декабрендә** Казан Кремлендә ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты, Татарстан Республикасында 2021 елда Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетының, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр советының уртак утырышы узды. Утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәи-

се Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, шулай ук Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Игорь Паньшин, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Михаил Мишин, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү комиссиясе рәисе Владимир Зорин катнашты.

Утырыш барышында ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә йомгак ясалды, Татарстан Республикасында этномәдәни үсеш һәм телләр сәясәте, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү мәсьәләләре каралды.

**2020 елның 21 декабрендә** Шамил Закиров исемендәге XX юбилей төбәкара «Идел-йорт 2020» конкурсына йомгак ясалды. Быелгы фестиваль ТАССР төзелүнең 100 еллыгы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы кысаларында 2020 елның октябрь-декабрь айларында өч этапта уздырылды, чарада Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе төбәкләренең иң яхшы үзешчән театр коллективлары катнашты.

Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә узды. Гран-прига Актаныш районының Киров авылы халык театры һәм Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районы Стәрлебаш авылының «Эстәрле» халык театры лаек булды.

**2020 елның 25 декабрендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институтында «Тюркологиянең актуаль проблемалары: Россия һәм төрки-мөселман дөньясы» темасына X Халыкара тюркологик онлайн-конференция узды. Әлеге чара Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты белән берлектә үткәрелде. Конференциядә Россия, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Казакъстан, Грузия, Төркмәнстан, Украинадан ике йөзгә якын галим катнашты. Конференциядә «Хәзерге төрки тел гыйлеменең актуаль проблемалары», «Төрки халыкларның топонимикасы һәм ономастикасы», «Төрки халыклар әдәбияты», «Төрки халыкларның фольклоры», «Лингвокультурология һәм тәрҗемә проблемалары», «Төрки телләрне һәм әдәбиятны укытуда белем алу һәм инновацияләр» һәм башка секцияләр эше оештырылды.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме
– аннотация (рус һәм инглиз телендә)
– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2020. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 30.12.2020. Басылды: 14.01.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла